**Қара көл.** Озеро. Топоним образован от общетюркского слово қара ‘чёрный; чернила < гом. төрки қара, тув., хак., як. хара, чув. хора > хура кара; явыз һ.б’ [Тэтимол, т.1, 2015, 366 стр.] (Черное озеро).

**Қойош кол.** Озеро. Русские назвали озеро Кривым (Кривое озеро). Мы считаем, что слово *қойош* фонетический вариант слова *қыйыш* ‘кривой’ [БДСТЯ, 2009, 439 стр.] о чем подтверждает и русский вариант топонима. Название дано по форме географического объекта.

**Қоро Ор, Курья.** Речка. Курья — река в России, протекает в Новосибирской области. Приток Вьюна. Река с таким же названием есть и в Алтайском крае. Под таким названием есть и озеро Большая Курья в Колыванском районе Новосибирской области. Топоним образован от слов *коры* ‘сухой’ и *оро* ‘канава,

яма, рытвина' [Большой диалектологический словарь татарского языка. Казань, Татарское книжное издательство, 2009, 505 стр.]. Правда, здесь остаются подозрения, что топоним мансийского происхождения. У манси река обозначается словом *я*: *Атымья, Волья, Толья, Орья, Пелья, Турья, Калья*. И.А. Воробьева пишет [Язык земли. О местных географических названиях Западной Сибири. Западно-Сибирское книжное издательство, Новосибирск, 1973, с.19], что топоним *Курья* это - 'залив, уходящий в луга или болота, озеро, протока' и происходит от диалектного слова *курья*. Правда, не уточняет, диалект какого это языка.

Мы считаем, что *Қоро Ор* это не фонетический вариант топонима Курья, а самостоятельное название, данное татарами за физические качества этого озера. В этом случае, *Қоро Ор* и Курья это названия одной и той же реки на разных языках.

**Көч$^{т}$ү Йалбақ кол.** Озеро. См. Оло Йалбақ кол.

**Көч$^{т}$ү Киндер көле.** От татарского слова *киндер* '(растение, а также его семена) конопля (культурная), конопель' [ТР, т.1, 2007, 572 стр.]. *Көч$^{т}$ү/кече* – 'младший, меньший, малый' [Тэтимол, т.1, 2015, 408 стр.] (Малое Конопляное озеро). Со словом *киндер* образован еще один топоним: *Оло Киндер көле* (Большое конопляное озеро). Возможно около этих озер выращивали коноплю в хозяйственных целях.

**Көч$^{т}$ү Қамыштау көле.** Озеро. От общетюркских слов *камыш* 'камыш, тростник' [ТР, т.1, 2007, 524 стр.] и тау 'гора; сопка' [ТР, т.2, 2007, 327 стр.].

**Көч$^{т}$ү Сарғатану коле.** Озеро. Русские называют озеро Зимник.

**Оло Йалбақ кол.** Озеро. От слова сибирскотатарского диалекта **йалбақ** – 'плоский, широкий' [Тумашева Д.Г. Словарь диалектов сибирских татар. Казань, 1992, 66 стр.]. Назван по форме озера.

**Оло Киндер көле.** От татарского слова *киндер* '(растение, а также его семена) конопля (культурная), конопель' [ТР, 2007]. *Оло/олы* – ' старший; большой, великий; важный' [Тэтимол, т.2, 2015, 77 стр.] (Большое Конопляное озеро). Со словом *киндер* образован еще один топоним: *Көч$^{т}$ү Киндер көле* (Малое коно-

пляное озеро). Возможно около этих озер выращивали коноплю в хозяйственных целях.

**Оло Қамыштау көле.** Озеро. От общетюркских слов *камыш* ‘камыш, тростник’ [ТР, т.1, 2007, 524 стр.] и *тау* ‘гора; сопка’ [ТР, т.2, 2007, 327 стр.].

**Отрачᵀ кол.** Озеро. Зимник. От антропонима *Әтрәч*.

**Өйен, Ийән, Уень, Вьюн.** Река Уень-Вьюн в Новосибирской области – небольшая речушка, которая протекает в болотистой местности Колыванского района. Протока Оби. Русло извилистое, несколькими протоками впадает в Обь. Ближайшие населенные пункты – деревни Красный Яр, Черный Мыс.

В разных районах Сибири топоним «вьюн» имеет разное происхождение. В Барабинском районе (река) – русское название, указывающее на извилистость течения. В Колыванском районе (река) – видоизмененное *уень*, где в начальное появилось под влиянием местного диалекта: Вуень-Уень. Топоним происходит, скорее всего, от тюркского *уен* – ‘игра’. По названию речки Вьюн Колыванского района получило свое название деревня Вьюны.

Существует и народная этимология топонима. Жители деревни Акбалык утверждают, что топоним *Уень* образован от слов «өй яны» (около дома или рядом с домом). Река протекала рядом с домами и поэтому получила такое название.

**Сай кол.** Озеро. Гидроним образован от слова *сай* ‘мель, мелкий’ [Тэтимол, т.2, 2015, 130 стр.]. Озеро очень мелкое.

**Сайет кол.** Озеро. Гидроним образован от антропонима *Сәет* ‘сеид, потомок пророка Мухаммеда; духовный глава татар’ [Тэтимол, т.2, 2015, 151 стр.].

**Сәптәннәк кол.** Озеро.

**Терәшкәй.** Название переправы.

**Томотоқ.** Маленький пруд.

**Умар суы.** Чаты реку Обь называют Умаром. По-алтайски название реки было Ах-Умар. Фонетический вариант этого названия встречается в названиях реки Умара (правый приток реки Бохапча) и озера Умар (Мурманская область). В алтайском языке слово «умар» означает «большая река» [Словарь алтайского и аладанского наречий тюркского языка. Изд. 2-е, Горно-Алтайск, 2005,

стр.404]. У алтайцев встречаются также названия *Умар, Ак Умар, Умар-ыймар, Уймар-јумар* [Словарь алтайского и аладанского наречий тюркского языка. Изд. 2-е, Горно-Алтайск, 2005, стр.404].

Топоним Обь распространен только среди русских, живущие на ее берегах малые народы называют ее по-другому: ханты – Ас, тюрки – Умар, кеты – Ю, Чу, манси – Сос. Топоним Обь это, скорее всего, зырянское название, которое происходит от зырянского составного слова «обва», где «об» это «снежная вода», а «ва» это «река».

Обь (Обва, Ах-Умар) – крупнейшая река в Западной Сибири, самая протяженная река в России (5410 км) и вторая по протяженности в Азии. Река образуется на Алтае слиянием рек Бия и Катунь. Обь также является третьей по водоносности рекой России (после Енисея и Лены).

Основные притоки: Чарыш, Томь, Чулым, Кеть, Иртыш. Также впадает: Большой Юган (впадает в Юганскую протоку). Питание реки преимущественно снеговое.

Вместо термина *елга* (река) чаты используют термин *су*. Это явление свойственно не только для чатов, но и для других сибирских татар. Термин *елга* практически не используется.

**Чᵀат тамагы.** Место слияния двух рек. От татарских слов *чат* ‘развилина, перекрёсток; место соединения рек и пространство между реками поблизости их слияния’ [Тумашева Д.Г., Словарь диалектов сибирских татар. Казань, 1992, 161 стр.] и *тамак* ‘горло; устье (реки)’ [Тэтимол, т.2, 2015, 208 стр.]. Именно от этого топонима, скорее всего, чаты и получили свой этноним.

**Чаус.** Река. Чаус (в водном реестре *Чаусс*, старое название *Чауса*, иногда *Чеус*) — река в Новосибирской области России. Левый приток Оби. Образуется слиянием рек Чик и Оёш недалеко от деревни Малый Оёш. Длина реки составляет 18 км, площадь водосборного бассейна 4760 км$^2$.

Находится в районе староречья Оби и иногда рассматривается как часть системы протоков, рек и озёр Чик – Чаус – Вьюна – Уень.

На реке ранее стоял Чаусовский (или Чаусский) острог (сегодня Колывань).

Есть отдельные, ради справедливости нужно заметить, не проверенные до конца, сведения, что, история названия реки Чаус уходит корнями в далекое прошлое, когда послом от крымского хана в Речи Посполитой стал некто Мирза Чаус. Следовательно, антропоним имеет тюркское происхождение и топоним образован от антропонима.

**Ч$^{т}$уманка.** Болото. От слова *чума, бата* ‘утонуть, погружаться’ [ТР, т.2, 2007, 586 стр.].

**Оронимы**

**Айлама.** Местность, где часто люди плутают. От сибирско-татарского слова *айлану* ‘кружиться, вертеться, обходить вокруг ч.-л.’ [Тумашева Д.Г. Словарь диалектов сибирских татар. Казань, 1992, 19 стр.]. То есть место, где люди плутают и кружатся и ходят в одном месте не находя выхода.

**Бөтәйәк эче бөк.** Пастбище. См. Бөтәйәк кол.

**Изан эче бөк.** Пастбище. См. Қоро Ор эче бөк.

**Йаwлу.** Местность в лесу. Там растет очень много ягод. Но в это место не рекомендовалось ходить.

**Қаштам.** Название бора. Русские его называют «Кашламский бор».

**Каш бажы.** Место, где начинается холм. Сибирские татары небольшие горы, холмы, возвышенности называют словом *каш* [Тумашева Д.Г. Словарь диалектов сибирских татар. Казань, 1992, 125 стр.]. Бажы в татарском литературном языке *башы* ‘голова, вверх, начало’ [ТРА, 2014].

**Қоро Ор эче бөк.** Термином *бөк* сибирские татары называют пастбища. В данном случае имеется в виду пастбище рядом с речкой Курья. См. Қоро Ор, Курья.

**Молла ч$^{т}$ығыны.** Местность. Скрытое место выхода из тупикового места в лесу. Образован от слов *молла, мулла* ‘глава прихода и мечети’ [Тэтимол, т.2, 2015, 52 стр.] и *ч$^{т}$ығыны,* который в литературном татарском языке *чыгу* ‘выходить/выйти’ [ТР, т.2, 2007, 591 стр.].

**Поскорок.** Остров на реки Обь. Русское название – Зелененкий.

**Сарғатану.** Название бора. От слова *сарғатан* ‘карась’. Бор находится рядом с озером Сарғатану.

**Ч$^{т}$етер.** Место внутри леса. Трудно проходимое, заросшее место. От татарского слова *чытыр* (фонетический вариант *четер*, в татарском литературном языке *чытырманлык*) ‘густая чащоба, заросли, густой кустарник’ [Тэтимол, т.2, 2015, 473 стр.].

**Ч$^{т}$егэн йолы.** Цыганская дорога. Здесь постоянно останавливался табор цыган.

**Ч$^{т}$ич$^{т}$канак.** Заводь. Место, где запирали лошадей. Информанты утверждают, что топоним образован от слова *чичкан, чычкан, чышкан, сычкан, тычкан* ‘мышь’ [Тэтимол, т.2, 2015, 336 стр.]. Место маленькое как мышь.

**Шайтан тауы.** Гора. Место где встречается всякая нечисть. Табуированное для посещения место. Ороним образован от слов *шайтан* ‘бес, сатан, шайтан’ [Тэтимол, т.2, 2015, 476 стр.] и *тау* ‘гора’ [Тэтимол, т.2, 2015, 232 стр.].

**Эзенкей.** Остров на реки Обь. Русское название – Абрашкина.

**Черномысские юрты, Черномыс айыл, деревня Черный Мыс** (на правом берегу реки Уени, притока Оби). В 2017 году Новосибирская область, Колыванский район, Новотроицкое сельское поселение. Количество жителей в 2010 году по данным переписи – 19 человек. Чаты. В 2017 году деревня уже не существует.

В 1897 г. – Томская губерния, Томский округ, Мало-Корюковская инородная управа. Число хозяйств – 33+2. Население: мужчины – 99, женщины – 80. Коренные тюрки: мужчины – 66, женщины – 58. Татары: мужчины – 1. Русские – мужчины – 32, женщины – 22 [Патканов, с. 148].

Жители деревни в XVII веке были крещены.

### Микротопонимия деревни Черномыс

**Минзәлә кол. Озеро Минзелинское. Минзәлә күле.** Озеро. Русское название озера – Мензелинское. Есть два озера со словом *минзәлә* – Малый Мензелинск, Большой Мензелинск. В Татарстане – название реки и города на ней. Слово *мәнзил, мәнзилә* арабского происхождения и означает ‘место остановки каравана,

почта, расстояние между двумя остановками', а также имел смысл 'времени года' [Тэтимол, т.2, 2015, 41 стр.].

**Чатск, Мурзинск.** До прихода русских в Западную Сибирь чаты жили на западе Барабинской степи в бассейне верхней Оби. Есть сведения, что там у них были городки Чатск и Мурзинск. Чатский городок находился на берегу Оби, около современной деревни Юрт-Оры.

На сегодняшний день городки не существуют.

## Заключение

У жителей обоих населенных пунктов (Юрты Акбалык и Юрт-Оры) активно употребляются следующие топонимические термины: *сай* ' брод или мелкое место', *бөк* ' пастбище', *қайынлық* 'березовая роща', *қарағайлық* 'сосновый бор', *орман* 'лес', *көл, кол* 'озеро', *йол* 'дорога', *айыл* 'деревня', *ором* 'улица', *су* 'река', *ор* 'рытвина, балка, сухая канава, яма', *йыш* используется в значении 'тайга', *төп* 'место (луг), предназначенное для косьбы травы, закуток в долине реки, сенокосное угодье', *бөк* 'низменность, долина реки', *буйы* 'орономический термин *буй/буйы* 'в сочет. с геогр. названиями (при-, по-)'.

Большинство топонимов (58 единиц или 64,4 % от общего количества изученных топонимов) образованы от слов, которые и сегодня активно используются как в татарском литературном языке, так и в диалектах татарского языка. Это такие топонимы как *Түш буйы, Урта бөк, Усақлы төп, Аю батқан кол, Оло Киндер көле, Сай кол, Шайтан тауы, Аққош күле, Буылды күле, Вәли күле, Ғобәй күле, Минзәлә күле, Акбалык, Абыстай йырғанағы, Ғобәй күле* и др. Большинство этих названий пришли в татарский язык из древнетюркского языка (например, Урта бөк, Сай кол, Акбалык, Алтын күбе, Кызыл Яр, Қара көл, Көч$^{т}$ү Қамыштау көле, Оло Қамыштау көле, Йар күле и др.) и сегодня с теми или иными фонетическими вариациями используются и в других тюркских языках.

Под влиянием сибирскотатарского диалекта некоторые топонимы подверглись незначительным фонетическим изменениям.

Таких топонимов мы зафиксировали 23 единиц (Көч$^{т}$ү Киндер көле, Йағынақ көл, Қойош кол, Сайет кол, Ч$^{т}$ат тамагы, Шағалай төбе, Каш бажы, Молла ч$^{т}$ығыны, Ч$^{т}$етер, Ч$^{т}$ич$^{т}$канак, Пәсәх речкасы,Ч$^{т}$уманка и др.). Это 25,5 % от общего количества изученных топонимов.

24 топонимов (это 26 % от общего количества изученных топонимов) образованы от слов сибирскотатарского диалекта, а именно от чатского говора томского диалекта. Многие из них сегодня активно употребляются и в других диалектах сибирских татар. Это такие гидронимы как *Айорлу кол, Бөтәйәк кол, Зур Сарғатану коле, Йағынақ кол, Қойош кол, Қоро Ор, Көч$^{т}$ү Йалбақ кол, Көч$^{т}$ү Сарғатану коле, Оло Йалбақ кол, Айлама (местность), Бөтәйәк эче бөк, Каш бажы (начало холма), Қоро Ор эче бөк, Сарғатану (бор), Ч$^{т}$етер (местность), Ч$^{т}$ич$^{т}$канак (заводь), Ечек күле, Йалбақ күл, Қамақ күл, Майғанақ күле, Қылтыма күл* и др.

Для части топонимов, на данный момент, трудно найти этимологию слов. Их мы насчитали 16 единиц. Это 19 % от общего количества исследуемых топонимов. Они остаются с затемненной семантикой. Это такие гидронимы, как *Қаным кол, Йозан коле, Сәптәннәк кол, Терәшкәй кич$^{т}$ү, река Чаус, Изан эче бөк, Йаwлу, Қаштам, Посқороқ, Эзенкей* и др. Эти топонимы могут быть образованными как собственно от чатских слов, так и с других языков.

Абсолютное большинство топонимов образовано от апеллятивной лексики. Микротопонимы еще не совсем оторвались от аппеллятивной лексики и только находятся на пути вхождения в состав полноценных топонимов. Семантически они в большинстве случаев понятны. Хронологические они новее, ближе к сегодняшнему дню и поэтому прозрачны. Но и сфера их употребления локальна, они известны лишь ограниченному количеству людей. А вот к наиболее старым топонимам, с затемненной семантикой относятся гидронимы и, в основном названия больших рек. В нашем случае это такие гидронимы как Умар, Обь, Уен.

Те из микротопонимов, которые образованы от онимов, в основном, антропотопонимы. Их мы насчитали 16 единиц: *Сайет*

*кол, Әҗәм күл, Вәли күле, Ғобәй күле, Пәсәх речкасы, Пәсәх күле, Алтын күбе, Йакуп төбе, Мәүлетов йаланы, Пәсәх речкасы, Пәсәх күле, Йакуп төбе, Мәүлетов йаланы, Рахматулла төбе, Сәлах төбе, Шағалай төбе, Шамғун төбе*. Из приведенных топонимов один образован от прозвища (*Алтын күб*е), один от фамилии (*Мәүлетов йаланы*). Два топонима образованы от одного антропонима (*Пәсәх речкасы, Пәсәх күле*). В основном все эти топонимы получили свои названия от имен владельцев участков, где производились различные сельскохозяйственные работы этими людьми. Необходимо отметить, что антропонимы фонетически слегка видоизменены под воздействием чатского говора.

Все приведенные микротопонимы в основном общетюркского и татарского происхождения. Субстратных топонимов мы не обнаружили. Это свидетельствует с одной стороны, что чаты живут здесь давно и являются аборигенным населением. С другой стороны мы еще раз получаем подтверждение того, что микротопонимы еще не совсем оторвались от аппеллятивной лексики и только находятся на пути вхождения в состав полноценных топонимов.

## Список литературы

Бахрушин С.В. Енисейский киргизы в XVII в. // Бахрушин С.В. Научные труды. М., 1955. Т. 3. Ч. 2.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. I том (А– Л) – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. II том (М– Я) – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015.

Бахрушин С.В. Сибирские служилые татары в XVII в. // Научные труды. Т. 3, ч. 2. М., 1955.

Большой диалектологический словарь татарского языка. Казань, Татарское книжное издательство, 2009.

Галиуллина Г.Р. Татарские личные имена в XX веке. Казань, 2000.

Дульзон А.П. Диалекты татар-аборигенов Томи // Ученые записки ТГПИ. Т. 15. Томск, 1956.

Иванов П.Г. Томские татары (материалы по обследованию Томских Карагасов летом 1927 г. Отдельный оттиск из «Трудов Общества Изучения Томского края». Вып.1. Томск, 1927.

Малиновский В.Г., Томилов Н.А. Томские татары и чулымские тюрки в первой четверти XVIII века: хозяйство и культура. Т. 3. Новосибирск, 1999.

Миллер Г.Ф. История Сибири. Т. 1. М.; Л., 1937.

Патканов С.К. Статистические данные, показывающие племенной состав Сибири, язык и роды инородцев. Т. 2. Тобольская, Томская и Енисейская губернии. СПб., 1911.

Постановление администрации Новосибирской области. г.Новосибирск. «О постановке на госохрану местного значения памятного места с.Юрт-Оры Колыванского района, от 29.11.94 г.). http://www.mtss.ru/?page=%2Ff_ bajram%2Fcat.

Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре сүзлеге. Казань, 1981.

Словарь алтайского и аладанского наречий тюркского языка. Изд. 2-е Горно-Алтайск, 2005.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / баш ред. проф. Ф.Ә. Ганиев. Казан: Матбугат йорты, 2005. – 832 б.

Томилов Н.А. Очерки этнографии тюркского населения Томского Приобья. Томск, 1983.

Томилов Н.А. Тюркоязычное население Западно-Сибирской равнины в конце XVI – первой четверти XIX в. Томск, 1981.

Томилов Н.А. Этнография тюркоязычного населения Томского Приобья. Томск, 1980.

Татарско-русский словарь : В 2-х т. Т. 1 (А – Л). Казань: Магариф, 2007.

Татарско-русский словарь : В 2-х т. Т. 2 (М – Я). Казань: Магариф, 2007.

Русско-татарский словарь актуальной лексики / [авт.-сост. Р.Р. Абдуллина и др.]. – Казан: Татар. кн. изд.-во, 2014.

Тумашева Д.Г. Словарь диалектов сибирских татар. Казань, 1992.

Тумашева Д.Г. Язык сибирских татар. Казань, 1968.

Уманский А.П. Телеуты и сибирские татары в XVII веке (очерк внешнеполитических отношений) / А.П. Уманский // Ученые записки БГПИ. Барнаул, 1972. Том 18.

Храмова В.В. Западносибирские татары // Народы Сибири. Из серии «Народы мира». М.; Л., 1956.

Чернобай Л.Н. Малые реки левобережья Оби. – Новосибирск, 2011.

# НОВОСИБИРСК ӨЛКӘСЕ ТАТАРЛАРЫ

*Олег Хисамов*
*Илсөяр Закирова*

Новосибирск өлкәсендә яшәүче татарларның рухи мирасын өйрәнү дәвам итә. 2017 елда Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан биредә яшәгән татарларның рухи һәм мәдәни дөньясын өйрәнү максаты белән оештырган комплекслы фәнни экспедиция Новосибирск өлкәсенең Колыван һәм Каргат районнарында эшләде. Бу мәкаләдә сүз шушы ерак Новосибирскида яшәүче милләттәшләребез, биредәге татар авыллары, халыкның тарихы, көнкүреше, халык иҗаты турында. Новосибирск өлкәсенең бу авыллары турында тулырак мәгълүмат бирү максатыннан Институтның Новосибирск өлкәсенә 1940 һәм 1967 елларда оештырылган фольклор экспедицияләре материалларын да мәкалә әзерләгәндә кулланабыз. Әлеге материаллар Институтның архивында саклана һәм укучыга беренче тапкыр тәкъдим ителә.

## Колыван районы

Колыван районындагы иң зур татар авылы – **Умар авыл. Авылның икенче исеме** – **Юрт-Оры.** Бу территорияләрдә татарлар VIII гасырдан яшәгән. Аларның биредә күп гасырлар яшәгәнлеген авылдан берничә генә километр ераклыктагы борынгы кала урыны да раслап тора.

Умар авыл Обь елгасы янында урнашкан. Авылның исеме дә елга атамасыннан алынган, авыл халкы Обь елгасын хәзер дә татарча «Умар» дип атый. Авылда хәзерге вакытта 120 ләп хуҗалык бар. Кайбер йортлар җәйге дачалар гына булып калган. Умар авыл, берара юкка чыгуга йөз тоткан булса да, хәзерге вакытта яңадан җанланып киткән, яңару юлына баскан. Бу күренеш авылда Навил Шиһабетдинов инициативасы һәм аның җитәкчелегендә яңа мәчет төзелү белән бәйле. Мәчет төзү эшендә бөтен авыл халкы катнашырга тырышкан. Кемдер финанс ягына үзеннән өлеш кертергә ашыкса, икенчеләре мәчет төзелешендә эшләгән. Бу эш авыл халкын уятып җибәргән, яңадан берләшергә ярдәм иткән. Алар авылны яшәртү, җанландыру турында киләчәккә матур планнар корып яшиләр. Мәсәлән, нәселле маллар үрчетү, каз-үрдәк, атлар тоту турындагы планнары әкренләп чынга аша да бара.

Бу авылның тагын бер күркәм эше – «Чат татары йорты» этнографик музей комплексы сафка басып килә.

Хәзерге вакытта да Умар авылда татар халкының чат татарлары буларак билгеле этнографик төркеме яши. Алар төрле чорларда Идел буеннан күчеп киткән татарлар белән аралашкан. Авыл халкы татар теленең әдәби вариантында да, аралашканда чат сөйләшендә дә узара аңлаша. Кызганычка каршы, хәзерге вакытта чат татарларының сөйләше әкренләп югала бара. Яшьләр рус теленә күчә бара. Тел һәм телгә бәйле рәвештә халыкның яшәү рәвеше, ата-бабалардан мирас булып күчкән әкиятләр, җырлар, хикәятләр онытыла бара.

Биредә ярты гасыр гына элек оста әкиятчеләр яшәгән. Умар авылда язып алынган әкиятләр «Татар халык иҗаты» күптомлыгында басылган. Мәсәлән, 1967 елда фольклорчы Халидә Гатина биредә әкиятче Кәрим Кусовтан «Патша малае», «Алтын башлы, көмеш беләкле» әкиятләренең вариантларын язып алган. Информантларыбыз 60–70 нче еллардагы «юмакчы» Рөстәм, Миңнеәхмәт бабайларны искә алдылар. Алар, балалар бөре җыйганда, кызыгып эшләсеннәр дип, әкият сөйләп торалар иде дип сөйлиләр.

2017 елгы экспедиция вакытында күләмле әсәрләр табылмаса да, информантларыбыз Сәфәргалиева Рәйсә Хәбибулла кызы, Шиһабетдинова Гөлҗиһан Зөлкарнәй кызы, Вәлиева Гөлбәзер Таштимер кызы, Нурисламова Галия Зәйдулла кызы һәм Җиһаншина Рәйхана Гарифулла кызыннан халык иҗаты әсәрләренең матур үрнәкләре теркәлде. Биредә мифологик хикәятләр, кыска җырлар, им-том текстлары, тыюлар, ышанулар язып алынды. Информантлар биргән мәгълүматлардан күренгәнчә, Умар авылда халык бик дус яши. Авылның күркәм традицияләренең берсе буларак, һәр гаиләнең елга берничә тапкыр Коръән мәҗлесләре уздыруын күрсәтергә була. Рәйсә апа Сәфәргалиева сөйләве буенча, кайбер гаиләләр елга 7–8 тапкыр өйдә Коръән укыта. Бер үк кеше бары Рамазан аенда гына өчәр тапкыр авыз ачтыра. Бу авыл халкының бердәм булуын, дус яшәвен күрсәтә ди Рәйсә апа.

Рәйсә ападан Коръән мәҗлесләрендә укыла торган мөнәҗәтләр, салаватлар, Коръән укыганнан соң әйтелә торган багышлау текстлары һәм башка дини эчтәлекле фольклор әсәрләре язып алдык.

Умар авылда ислам дине белән параллель рәвештә озак еллар курчак культы да яшәп килгән. Шәһәбетдинова Гөлҗиһан апа курчакларның «Капка өсте» дип аталган тирәклектә тотуларын сөйләде. Информантлар биргән мәгълүмат буенча, курчакларның өйдә торганы да, тирәклектә торганы да булганлыгы аңлашыла. Шуны да әйтергә мөмкин: чат татарлары Томск өлкәсендә дә яши, курчак культы эзләре Омск һәм Томск өлкәләрендә узган экспедиция вакытларында да язып алынды. Мәсәлән, Омск өлкәсендә курчакларны язгы ташу вакытында бозларга куеп җибәрү йоласы булган. Иртешкә агызганда, бу курчаклар авыру-хасталарны алып киткәннәр дип ышанганнар. Курчакларга яки коңгырчакларга табыну турында язып алынган материаллардан күренгәнчә, Томск өлкәсенең чат татарлары яшәгән авылларда «курчак уйнату» узган гасырның 50–60 нчы елларына кадәр дәвам иткән. Курчакларны чүпрәктән ясаганнар, бәйрәмнәрдә сыйлаганнар. Алар белән

сөйләшкәннәр, ярдәм сораганнар. Курчакларга табыну телеут халкында да булган.

### ***Курчаклар***

*Курчаклар ясап, тирәкләр янына утыртканнар. Әни сөйли торган иде. Бәйрәм булса, әнә тегендә, Капка өсте дип әйтәләр иде ул җирне, анда тирәкләр булган бик күп. Һәркемнең тирәге булган. Ул тирәктә курчагы булган һәркемнең. Курчакларны күлмәк кидереп алып барып утырта торган булганнар. Бәйрәмнәрдә ашаган әйберне аларга да алып барып утырта торган булганнар. Хәзер андый әйбер юк инде.* (Умар, Шәһәбетдинова Гөлҗиһан Зөлкарнәй кызы, 1928 елгы).

*Менә боларның пародысы (фотодан күрсәтеп сөйли) уйнаганнар чердак башында курчаклар белән. Курчаклылар дип әйткәннәр аларны. Менә мин ишеткән идем карт кешеләрдән. Балалар ничек инде уйныйлар курчаклар белән, болар да шулай ашатып,эчертеп, киендереп матур гына итеп утыртып куялар икән.*(Умар авыл,Нурисламова Галия Зәйдулла кызы, 1941 елгы.)

Умар авылда язып алган материаллар арасында төрле йолаларга караган материаллар да шактый. Мәсәлән, язын «Боз озату» йоласын авылда бәйрәм кебек көтеп торганнар. Боз карарга бөтен авыл халкы чыккан. Матур киемнәрен киеп, бәйрәмгә барган кебек барганнар су буена.

Елгаларда боз китү ел фасылларының алышынуын, кышның тәмамлануын, китүен белдерә. Боз китү, табигать уяну вакыты, табигатьтәге хаос кеше тормышына да йогынты ясый ала, аның аеруча сизгер һәм көчле вакыты санала. Умар авылда бу йола ислам дине белән керешеп киткән. Боз киткәннән соң, һәр гаилә Коръән укыта.

### ***Боз озату***

*Боз киткәндә балчык алып, баш аша әйләндереп, бозга ташлыйлар. Авырган авырулар булмасын дип ташлыйсың.* (Умар, Шәһәбетдинова Гөлҗиһан Зөлкарнәй кызы.)

*Убтан (Обь) боз кузгалгач, Коръән укыталар. Ике-өч көн боз китә иде авылда. Хәзер кайчан киткәнен белгән дә юк. Йома көн*

*китә иде. Ровно бер атнадан,икенче йомганы, әзерләнеп Коръән укыталар иде.* (Умар авыл, Сәфәргалиева Рәйсә Хәбибулла кызы.)

***«Ташу»***

*Баштан әйләндереп атасың песок – авыруларны, кайгыларны алып кит, миңа кайгы калдырма, дип ташлыйсың.* (Умар авыл, Вәлиева Гөлбәзәр Таштимер кызы, 1941 елгы.)

Умар авыл апалары шактый гына кыска җырлар да җырлап күрсәттеләр.

Йыр йырлавын харам диләр
Мөхәммәт өммәтенә.
Харам булса да йырлыймын
Дусларым хөрмәтенә.

Умар белән Акбалыкның
Алтмыш чакрым арасы.
Ике алтмыш – йөз егерме,
Ничек итеп барасы.

Умар юллары пиала,
Таш булса таймас иде.
Минем йөрәккәйем яна,
Сез булса янмас иде.

Умар авылда төрле риваятьләргә дә юлыктык. Тарихи вакыйгаларны, гаилә тарихларын бәян иткән риваятьләрне, сөйләкләрне, истәлекләрне һәр гаилә кадерләп саклый, буыннан-буынга тапшыра. Шундый риваятьләрнең берсендә бу якларга Бөгелмә ягыннан килгән бертуган егетләр турында сүз бара.

***Мәүлетовлар нәселе турында***

*Бөгелмә яктан, ачлыктан качып, өч егет килгән. Ул якта, Казан якларында, ашарга-эчәргә булмаган бер нәрсә дә, болар килгәннәр Акбалыкка.*

*Өч егет, өч брат. Биик матур булганнар. Аннары өйләнгәннәр. Аларның гел генә ир балалары туып торган. Шулай нәселләре бик таралган. Ул ир балаларның токымнары менә хәзер*

*таралды. Бер братның бер улы – минем әти, ул 1904 елгы иде. Менә минем әтиемнең генә малае тумады. Гел кызлар гына туа. Әтиемнең әтисе Зәйнулла булган. Фамилияләре Мәүлүтов булган. Бик эшчән булганнар бу егетләр, эшләгәннәр бик. Атта бик яхшы чапканнар.*(Умар авыл, Нурисламова Галия Зәйдулла кызы, 1941 елгы.)

Умар авылында язып алынган төрле ышанулар да кеше белән әйләнә-тирә мохитнең бәйләнешен күрсәтә. Элек заманнарда табигатькә булган сак караш агачлар белән бәйле тыюларда чагыла. Борынгылар һәр җан иясен, шул рәттән агач-үсемлекләрне дә аяганнар, аларның яшәү теләген хөрмәт иткәннәр. Вакытлы-вакытсыз агач кисү зур гөнаһ саналган. Кеше бу гамәле белән үзенә агачның рәнҗешен алудан курыккан.

*Тик торганнан ярамый гөрләп, яшәреп утырган агачларны кисәргә. Утырткан агачы үскән кешенең күңеле яхшы икән дип әйтәләр.* (Умар авыл,Нурисламова Галия Зәйдулла кызы.)

*Элек бабайлар белгән нинди агачны нинди көндә кисәргә яраганын. Агач вакытсыз киселсә яки дөрес киселмәсә, өй тыныч булмый. Музейдагы өй дә шулай диләр. Сайра мама өе. Агачны дөрес алмаганнар.Кояш баеганнан соң, агач эше эшләргә ярамый.* (Умар авыл, Җиһаншина Рәйхана Гарифулла кызы. 1950 елгы. Акбалыкта туган. Соңрак Умарга күчкәннәр.)

**Акбалык һәм Казанка авыллары.** Акбалык авылы – Колыван районындагы икенче зур татар авылы. Авылда 270 кеше яши, урта мәктәп һәм медицина ярдәме күрсәтү пункты бар. Акбалык авылы Өян елгасы буенда урнашкан. Авыл борынгы, аның янында урта гасырларга караган Паш-Тура кала урыны бар. Елга янында урнашкан булу сәбәпле, авыл халкының төп шөгыльләренең берсе – балыкчылык. Шулай ук аучылык та озак вакытлар хуҗалык алып баруның бер чыганагы булган. Хәзерге вакытта да авыл халкы терлек тотып, җитешле тормыш белән яши. Һәр хуҗалыкның җиләк-җимеш, яшелчә үстерә торган бакчасы бар.

Биредә дә элегрәк чорларда чат татарлары яшәгән. Тора-бара Казан ягыннан Идел буе татарлары да килеп кушылган. Җирле халык белән Казан яктан килгән татарлар күпмедер вакыт үзара

кушылып китә алмыйча яшәсәләр дә, бераздан аралашып китәләр. Хәзерге вакытта һәр гаиләнең ике яктан да килгән тарихы бар. Шул ук вакытта татар теленең чат сөйләше биредә юкка чыгып бара. Авыл халкы әдәби телдә сөйләшә.

Акбалык авылының тарихы турында 1967 елгы экспедиция вакытында Хәмит Ярми шактый мәгълүмат туплаган.

**_Акбалык авылының тарихына карата_**

*12/VI – 1967*

*Акбалык авылы Обь елгасының бер ярында, дөресрәге Обьның сул як ярында, бу елгадан 4 км ераклыкта утыра. Обь елгасына Оян/Өян елгасы кушыла. Акбалык авылына Обь елгасының Батурино пристаненнан Өян елгасы буйлап килеп була. Ул 5–6 чакрым ераклыкта. Без Батуринга төнге 3 сәгатьтә килеп төштек. Сургутка хәтле бара торган «Омск» пароходы иде.*

*Акбалык авылы – Себернең шактый борынгы авылларының берсе. Шушы авыл кешесе Имаметдин Шәмгун углы Баһауетдиновның (1901 елда шушы Акбалык авылында туган) әйтүенә караганда, бу авылга, аның оешып яши башлавына 1000 еллар булырга тиеш дип уйлана. Бу тирәләрдә Новосибирск галимнәре археологик тикшерү-казынулар (раскопки) үткәргәннәр. Алар бу тирәләрдә бик күп каберлекләрдә борынгы кешеләр сөякләрен тапканнар. Имаметдин абзый шул материаллар, археологлар сөйләвенә таянып, бу авыл бик борынгы авыл, ди. Бу авылдан 1 км җирдә «Баш тора» дигән бер урын бар икән. Шул урында борынгы халыкларның башкаласы, баш шәһәре (Тора – шәһәр) булган. Шул баш кеше торганга, ул җирне (яки авылны) Баштора дип атаганнар. (Мин ул урынны үзем барып караячакмын.)*

*Обь елгасына коя торган Өян елгасы Обь елгасы белән янәшә агып килә. Бу елганың озынлыгы... км чамасы булыр. Бу Акбалык авылы шул елганың сул як ярына, бик матур бер урынга утырган. Хәзерге көндә бу авылда 124 хуҗалык бар. 1930 елда бу авылда колхоз оеша, ә 1952 елдан монда Новотроицк совхозының бүлекчәсе (3 нче ферма) ачыла.*

*Бу авылның исеме турында түбәндәге легенда бар:*

*Борын заманда бер кеше, Өян елгасында балыкчылап, йөргәндә, бер ап-пак балык тотып ала. Бу хәл шушы авыл турысында була. Шуннан соң бу кеше, шушы урынга чыгып, авыл корып тора башлый. Шуннан соң бу авылга «Акбалык» исеме бирелә һәм ул шуннан соң Акбалык авылы дип аталып йөртелә.*

*Имаметдин абзый сөйләвенә караганда, бу авыл элекке заманда җиргә бик тә бай булган. Бу авылның җире бер ягы 80 км, икенче ягы 20 км булган. Бу хәтле зур территория, бу хәтле күп җир Акбалык авылы белән Умар/Умар, русча Оры авылы кулында була. Бу ике татар авылы бер волостьта торалар. Волость Умар авылында була. Бу ике авылга шулхәтле күп җир бирелү нидән килгән? Имаметдин абзый сөйләвенә караганда, Ермак Себерне яуларга килгәндә, бу ике авыл кешеләре (татарлар) мондагы мәҗүсилектә яшәгән халыкларны патша (Ермак) тәртипләренә буйсындыруда аңа (рус гаскәрләренә) булышканнар. Бу авыл кешеләре рус дәүләте ягыннан торып, мондагы, элек инородецлар дигән халыкларга каршы Ермак ягыннан торып сугышканнар. Себер рус дәүләте кулына кергәч, бу халыкларга, ягъни Акбалык һәм Умар авылы татарларына бик күп итеп җир биргәннәр. Ул җирнең күпме булуы һәм бу ике авыл татарларына ярдәмнәре турында грамота да язылган иде. Ул грамота зур һәм яхшы кәгазьгә алтын хәрефләр белән язылган. 1911 елларга хәтле безнең авыл татарларына бирелгән җир тулысынча халык кулында була. Патша түрәләренең моңа эче поша. Бу җирләрне бүлеп алмакчы булалар. Бу авылга патша түрәләре берсе артыннан берсе килә. Ләкин халык: «Җирне бирмибез! Ул безгә патша хәзрәтләре тарафыннан бирелгән, менә аның язуы», – диләр. Каты тора халык. Түрәләр дә үзләренең басымнарын көчәйтәләр. Көннәрдән бер көнне бу авылга бер исправник (урядник) килеп төшә. Халыкны җыйнап: «Сезнең җирегез бик күп, без аның бер өлешен казнага алабыз. Ә сезгә тиешенчә генә калдырабыз», – ди. Халык каршы төшә. Гауга кыза. Җир мәсьәләсе бит! Алай да булмый, халык, кызып китеп, патша түрәсен дөмбәсләп ташлый. Исправник көчкә качып котыла.*

*Бер-ике айдан соң бу авылга бер рус кешесе килеп, авыл халкы белән бик җылы, бик якын күреп сөйләшә башлый. «Җирне бирми яхшы иткәнсез, исправникны куып җибәреп бик дөрес эшләгәнсез», – ди. Халыкның шул җир эшләре артыннан йөргән кешеләре бу кешегә үзләренең серләрен сөйләп бирәләр. Теге бик кызыксынып тыңлап тора. Акбалык кешеләре арасыннан берсе: «Менә мин ул исправникка үзем башлап суктым. Аны кыйнауда фәлән катнашты, фәлән шулай итеп сукты», – дип, барысын сөйләп бирә. Болардан сүз алгач, теге кеше өстендәге киемнәрен салып ыргыта. Ул киемнәр астыннан кораллы урәтник килеп чыга. Бу урәтник теге кешеләрнең сөйләве буенча список төзи. Исправникны кыйнауда катнашкан кешеләрне арестовать итеп алып китә. Шуннан соң аларга суд була. Шул вакытларны патша тарафыннан бирелгән җир турындагы алтын белән язылган документларны да тартып алалар. Менә шуннан соң Акбалык, Умар халыкларының җирләре тартып алына, аларга берникадәр җир калдыралар да калганын русларга һәм башка переселенецларга бирәләр. Бу җирләргә берничә рус авылы килеп утыра. Акбалык һәм Умар авылларына патша тарафыннан күпме җир бирелүе һәм аның ни өчен бирелүе турындагы документ Облзем отделда я архивта булырга мөмкин. Мин исә ул җирләрнең бу татарларның нинди батырлыклары, патшага (яки Ермакка) нинди көч бирүләре турында әйтә алмыйм.*

Казанка авылына 1926 елда Казан ягыннан, Идел буеннан килгән татарлар нигез сала. Алар үзләренең авылларына, чыгышларын искә төшереп торсын өчен, *Казан* исеме бирәләр. Гасырга якын вакыт үтүгә карамастан, хәзергә кадәр Казанка халкы үзләренең кайсы яклардан килүләрен, чыгышларын хәтерли. Мәсәлән, Сабирова Фәризә апа халыкның бирегә Идел буендагы 1921 елгы ачлыктан качып килүләрен сөйләде. Аның кайнана-кайнаталары Саба районының Кибәхуҗа авылыннан күчеп килгәннәр. *«Беренче булып монда Минһаҗ бабай килгән. Хәзер аларның нәселенең фамилияләре Минһаҗетдинов. Белмим ничә кеше булганнарын, күпме килгәннәрен. Күп булганнар алар. Безнең әби килгән инде. Килгәндә, бик азапланып килгәннәр. Ачлык бул-*

*ган. Әбинең ире үлгән, 4 кызы үлгән ачлыктан. Малае үлгән монда килгәндә. Бик авырлык күреп килгәннәр»*, – дип сөйли Фәризә апа. Шәйхетдинова Галия апа да әби-бабаларының Казан ягыннан килүләрен сөйләде: «*Казаннан килгән кешеләр монда бөтенесе дә Кибәхуҗадан килгәннәр. 21 елда. Ачлыктан качып килгәннәр. Башта алты ел Барнаулда торганнар. Анда шундый әйбәт булган. Аннары монда килгәннәр*». Информантларыбыз сөйләгәннәр 1967 елгы экспедиция вакытында Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Казанка авылында яшәүче Нургали бабай Мөхәммәтҗановтан авыл турында язып алган мәгълүматлар белән туры килә:

***Яңа Казанка авылы***

*Новосибирск өлкәсенең Колыван районына керүче бу авыл, чыннан да, яңа әле. Ул 1926 елда гына салынган. Халык Татарстаннан күчеп килгән. Кибәхуҗа авылы кешеләре бигрәк тә күп. Күчеп килүнең сәбәбе – 1921 елгы ачлык. Алар башта Барнаул янына күчеп киләләр. Анда бер биш ел торгач, бирегә күчәләр. Ул вакытта бу урында урманлык була. Башта, землянкалар казып, шунда торалар.*

*Хәзер авылны күрүчеләр биредә кайчандыр кечкенә землянкалар булгандыр дип башларына да китермәсләр иде. Авыл бик төзек. Йортлар барысы да зур, дүртәр бүлмәле, яңа. Авылда барлыгы 120 хуҗалык. Сигезьеллык мәктәп, клуб, медпункт бар.*

*Халык урманчылык белән шөгыльләнә. Биредә Колыван лесхозының ширпотреб цехы урнашкан. Эшчеләр урман кисәләр, төзү материаллары хәзерлиләр, шулай ук яңа урманнар утырталар. Моннан тыш, бочкалар, ящиклар, чаналар, тәрәзә рамнары ясау цехлары бар. Шулай ук сумала, скипидар, күмер, дегет, лак әзерләнә.*

*Административ яктан Яңа Казанка авылы 7 чакрымда урнашкан Акбалык авыл советы карамагына керә.*

Авыл халкының төп шөгыле урман белән бәйле булган. Авыл халкы белән аралашкан вакытта, күбесе биредә агач эшкәртү цехында эшләп пенсиягә чыгуларын әйтәләр. Халык бердәм-дус яшәгән, бәйрәмнәрне матур итеп, күмәклəп уздырган. Ураза, корбан гаетләрендә азан әйткәннәр. Авылның мәчете булмаса да,

һәр гаеттә, берәр йортка җыелып, намаз укыганнар. Информантлар элегрәк авылның бик матур булганын сөйләделәр. Хәзер агач эшкәртү цехы ябылган, эш беткән. Шул сәбәпле яшьләр авылда калмый. Элегрәк исә яшьләр тавышыннан авыл гөрләп торган. Яшьләр, кичләрен болынга чыгып, «Круг» һәм «Наза уеннары уйнаганнар.

1967 елгы экспедиция вакытында авылның гөрләп торган чагы була. Акбалык һәм Казанка авылларында әкиятләр, җырлар, уен һәм йола җырлары язып алына. Шул экспедиция вакытында язып алынган тагын бер җыр «Зиндан моңнары дип атала. Бу әсәрне Акбалыкта яшәгән 1908 елгы Минневәлиева Өммегөлсем әбинең дәфтәреннән фольклорчы Халидә Гатина табып, аны зур галим, үзе дә Себер тумасы Хәмит Ярми күчереп алган. Хәмит Ярми, җырны күчереп алганнан соң, түбәндәге искәрмәне язып куйган: «*Эчтәлегенә караганда бу җыр Колчак вакытында чыгарылган булырга тиеш. Гражданнар сугышы чоры. Ул телдән-телгә күчкән һәм язмага кереп китү аркасында шулай сакланып калган. Бу соңгы дәфтәргә 1950 елларда күчерелгән булырга тиеш( дәфтәре Новосибирскида чыккан*)». Бу җырга аерым тукталуыбыз очраклы түгел. 2017 елгы экспедиция барышында без бу җырга яңадан юлыктык. Һәм шунысы кызык: ул тагын кульязмада, Казанка авылында яшәүче Солодовникова Хәкимә апада сакланган. Хәкимә апа озак еллар Ташкентта яшәп, ялга чыккач кына, кире туган ягына әйләнеп кайткан. Ул гарәп язулы китапларны, кульязмаларны, нинди язмалар булуын белмәсә дә, һәрвакыт саклап тоткан. Шул китаплар арасында гарәп язуы белән язылган ике битле кульязма килеп чыкты. Бу язма, Хәкимә апаның сүзенә караганда, аның әтисеннән калган. Әтисен Колчак гаскәре алып киткән, ул – шул чорда төрмәләрдә булган кеше. Җырда да шул чор, аның Иркутск төрмәсендә утырган вакыты турында сүз бара диде информантыбыз. Күргәнебезчә, ике язма да бер үк чорга караган вакыйгаларга барып тоташа. Хәмит Ярми бу җырның «Яңа Ай былбылым» яки «Ай былбылым» көенә башкарылуын да искәрткән. Акбалык авылында табылган текст белән Казанка авылында табылган ике текст та, нигездә, туры килә. 2017 елда табылган текст белән сезне дә таныштырабыз.

**_Зиндан моңнары_**

Ангараның буйларында
Иркут салган каласын.
Ризык дигән кайда кертми
Без тик адәм баласын.
*куш.:* Ай былбылым, вай былбылым
Ангараның агышы.
Ике битем тиң саргая,
Бар да – зиндан сагышы.
Ангараның суы тирән
Агып Байкалдан килгән.
Явыз Колчак шомлыклары
Безнең башларга җиткән.
Ангараны чыккан чакта
Күрәм суда ташларын.
Төрмә саен өстерәлде
Минем газиз башларым.
Иркутск төрмәсендә
Йозагы бүлмә бүлмәсендә.
Без күргәннәр гыйбрәт булсын
Башкаларга күрмәсенгә.

(Казанка авылы. Кульязманың кемнеке булуын ахыргача ачыклый алмадык. Язулар арасында Сатышев Мөхәмәтша дигән исем дә телгә алына. Ул 1959 елда 3 февральдә 76 яшендә вафат булган. Мулла булып йөргән. Информантыбыз Хәкимә апа бабасын Хәмәтдин дип тә искә ала.)

Акбалык һәм Казанка авылларында язып алынган риваятьләрдә, истәлекләрдә авылның төрле еллардагы тормышы, халыкның уй-хыяллары, ышанулары, йола, гореф-гадәтләре чагыла.

Информантлар авыр сугыш елларын искә төшерделәр. Күңелле йола-бәйрәмнәрне барладылар. Мәсәлән, бу авылның үзенең күркәм йоласы булган. Яз җитүне бөтен авыл белән Өян елгасында көймәләрдә йөреп бәйрәм иткәннәр.

## *Авыл тарихы*

*Әби сөйләгән иде. Монда килгәннәр дә – кертмәгәннәр, кире туган җирләренә кайтып киткәннәр. Анда кайткач көлгәннәр инде алардан. Тегендә-монда йөрисез дип. Яңадан килгәннәр. Монда тагын кертмәгәч, елларын белмим мин, монда ерак түгел, Воробьянино дигән авыл, анда барып торганнар. Аннары, кертә башлагач, монда яңадан килгәннәр.*

*Монда «себерәкләр» дигәннәр инде борынгылар, шулар торган. Безнең авыл бик төпле-тамырлы авыл булган. Суы-урманы бар. Ачтан үлә торган түгел. Умар белән бер сөйләм монда. Монда килгәннәр беренче урам салганнар. Менә монда, аннары зират ягында тагын бер урам. Ике коренной урам булган. Бу коренной халык авылы булган. Анда аннары Мәүлетовлар килгән. Без – килгән халык, килмешәкләр инде. Монда чат татарлары, чатские татары яши.*

*Авылда мәчет булган. Мәүлетдиннең яңа өе бар бит, шунда булган, урамга чыгып торган ул. Колхоз башланган заманнарга кадәр эшләгән. Беренче мәктәп мәчет бинасында була. Бала-чага күп булгач, библиотекада да мәктәп булды. Без анда укый башладык. Тагын бер школа булды сазда. 192 бала булган ул вакытта.*

*Әбием Рәсәйдән килгән. Бик укыган булган. Мишәрчә ычкындырып куя иде. Мишәр булган әбием.*

*Халык бездә денен ташламады. Коръән укыталар. Өчен, җидесен укыталар һәрвакыт. Коръән мәҗлесендә әбиләр аерым бер бүлмәдә, бабайлар аерым, башка бүлмәдә утыралар иде. Хәзер кеше аз булгач, барысы бергә инде. Мәетләр өчен дип, Ходай ризалыгы өчен, бәйрәм хакы дип сәдәка бирәләр.*

## *Черномысь*

*Сез кая булган? Черномысьта булганмы, ди. Сез нәрсә күргән? Черномысь йөргән, Черномысь күргән, диләр. Черномысьта йөргән кеше күпне күргән була инде. Черномысьта да татарлар булган. Ул 30 чакрымда. Аларны курчакчылар диләр инде. Килгән халык аларга воле бирмәделәр.*

### *Өян*

*Обь 2 чакырым авылдан напрямую. Безнең үзебезнең Өян бар. Исеме нәрсә аңлатканын белмибез. Шул бирегә яшәгән халыктан калган исем. Өян Обьтан керә, аннары яңадан Обька кушыла. Су чиста иде. Бала-чага шунда коена иде, балык тота иде. Су инәсен күргән юк, сөйлиләр генә. Сөйлиләр иде, суга сикерә дә, суны ярып җибәрә диләр иде.*

*Без, Акбалык халкы, болай дип җырлыйбыз:*

*Акбалыкта ак балык,*
*Без үзебез вак булсак та,*
*Безне ярата халык.*

### *Көймәләрдә йөрү*

*Язын карлар бетеп, суда бозлар киткәннән соң, су буена чыкканнар. Озын көймәләрдә йөри иделәр егетләр-кызлар. Бу май аенда була инде.Су арткан вакытта. Гармуннар белән чыкканнар. Егетләр күбесе гармун уйный торган иде. Кайсы тотмасын гармун, бер-ике җыр көен уйнап бирә инде. Шулай көймәләрдә йөри торган булганнар. Һәр көймәдә гармуннар уйнаганнар, җырлашканнар. Бу вакыт бик күңелле булып, гармун, җыр тавышыннан бөтен авыл гөр килеп торган. Җырларны Казаннан килгән пластинкалардан да өйрәнгәннәр. «Каз канаты»н җырлый идек. Бу Казан яктан килгән җыр. Ата-бабалар китергән җыр инде.*

### *Тәмәке өмәсе*

*Сугыш заманасында тәмәке өмәсе ясыйлар иде. Акча кирәк булгачтын инде, семьяга яшәргә, бала-чаганы үстерергә кирәк булгач, тәмәке үстерәләр иде бездә, самасат диләр иде үзләренчә. Авыл халкы тәмәке үстерәләр иде. Төпчекләр ясыйлар иде, түгәрчекләр (букән). Балта белән ясыйлар иде. Менә шундый төпчекләр, аның уртасы тишегрәк була. Шунда тәмәкене чабалар да иләк белән илиләр. Специальный иләкләре була торган. Городка алып китәләр иде сатырга. Шуннан инде бала-чаганың өстенә дигәндәй, ризык алып кайталар иде. Сугыш заманасында халык шуның белән заниматься иткән.*

### *Сугыш турында*

*Авылдан сугышка 40 тан артык кеше китте, төгәле 48 түгелме икән? Шуның 32 ләп кеше кире кайтмады. Шуларның 16 сы өйләнмәгән малайлар иде. Халык сугыш каты сугыш дип уйламады, куркыныч түгел дип уйлады. Аннан алда бит финнар белән сугышып алды. Беркемне дә алмадылар авылдан. Тиз генә җиңеп кайтырлар, бу да шулай булыр дигән идек. Вот шундый гына булыр дип уйладылар да инде. Менә әтием китеп бара, ә олы браты башын гына селкеп калды. Әтием кайтканнан соң сиз-де инде, нәрсә ни икәнен, икенче киткәндә уже монда кунып, аны озатып куйды.*

### *Сугыш еллары турында*

*Җәй көне менә су арта торган, су төшкәннән соң юа дигән үлән бар иде. Калын. Шуны җыеп тозлыйлар да иде инде. Аннары каядыр витаминник дип, бочкалар белән алып та китәләр иде. Халык инде шуның белән дә торган. Сөтле аш ашаганнар. Сыерлар инде бар иде бар кешедә. Һәрберсенеке булган. Сөт белән, бәрәңге белән инде. Бәрәңгенең дә җәйгә хәтле калмаганнары булган. Булган бер төрле киемнәрне чит авылга, рус авылында нигәдер практичныйрак булган халык татар авылына караганда, алып барып бәрәңгегә алыштырып кайта торган булганнар. Аннан инде 50 – 51 елларда адәм инде аякка баса башлаган иде. Сугыш вакытында авыр булды инде. Булганын хөкүмәткә бирә торган иде. Сауган сөтне сдавать итә идек. Тавык салган күкәйне тоже тапшыра идек. Сарыкка да сөт тапшырырга иде. Андый да бар иде, сарык сөте бирә торган идек, сыер сөтен. Сугыш заманасында бездә, авылда шулай иде.* (Акбалык авылы, Зәйнуллин Әбүзәр Абдрахман улы, 1932 елгы. Бабалары Арча ягыннан килгән. Әнисе 1908 елда, бирегә килгәч туган.)

### *Авыл турында*

*Безнең инәләребез килгәннәр, бабаларыбыз килгәннәр. Без монда туган инде. Әби Яңавылдан, Томск яктан, бабай барып алган. Шәрифә әбиләребез Казаннан килгән булганнар. Безне «киштем» диләр. Акбалыклар киштем диләр. Болай Умарларны киштем диләр. Алар монда туган булганнар, элек борынгыдан монда*

*алар. Умарларны кытайлардан калган дип әйтәләр, киштемнәр дип әйтәләр. Алар кара тәнле, күзләре кысык күзле, аерылып торалар. Безнекеләр әйтәләр иде. Безне килгәч бик обижать итәләр, безне «килгән килмешәкләр» дип сүгәләр, артыбыздан теләсә нәрсә әйтеп калалар. Трубкага самосад тутырып, тәмәке тартып утыралар иде, дип сөйлиләр иде.*

### ***Мәүлетовлар нәселе***

*Бирегә ике кызы һәм биш малае, карчыгы белән Вәли бабай Татариядән килгән. Патша подъемный биргән. Башта кертмәгәннәр ул заманда килгәннәрне. Местныйлар землянкаларда яшәгәннәр, охотник-рыбаклар булган алар. Вәли бабай хәйләкәррәк булган. Или бер кеше өйрәткәнме икән. Бер чиләк аракы алып килгән, сыйлаган халыкны. Шуннан аны керткәннәр. Теге якта тау башында торганнар аннары алар. Шунда бүрәнәдән йорт салганнар алар. Шулардан Мәүлетовлар нәселе киткән. Алар – Хәйрулла, Гайфулла, Миргатулла, Мотыйгулла, Зәйнулла. Бер кызы Хәбби булган. Балалары 1870 елларда туганнар. Атам биредә 1905 елда туган.*

### ***Табигать турында***

*Элекке картлар кайчан нәрсә эшләргә кирәклеген белгәннәр. Алар бервакытта да икра чәчкән вакытта балык тотмый. Рыбнадзор кирәкмәгән иде. Кешеләр үзләре беләләр нәрсә яраганын, нәрсә ярамаганын. Агачларны, алар йокыга киткәч, ноябрь аенда гына кискәннәр. Ике атна гына кискәннәр. Кедраны кисәргә ярамый. Хәзер круглый год кисәләр.* (Акбалык авылы, Мәүлетов Рафик Шәфикович, 1938 елгы. Механизатор һәм егерь. Әниләре, 1921 елгы ачлыктан качып, Алтайга киләләр. Гайни әби белән Минһаҗетдин бабай Саба районы Кибәхуҗа авылыннан булганнар, аннан бирегә күченгәннәр.)

### ***Агач цехы***

*Авыл кырыенда урман. Авыл халкының эше дә агач белән бәйле. Биредә Агач эше, цех бар иде. Мин 1963 тән агач эшендә. Без туктагач, пенсиягә чыккач яптылар. Яшьләр эшләмәс булды,*

*ахырысы, анда. Балта сабы ясадык. Шомаклап бирә идек, шоп-шома итеп. Алты тәңкә иде берсе. Агач кирә иде. Аны кисәбез. Аннары аны станокка үткәрәбез. Балта сабына яраклы, әйбәт җирен сайлап алабыз. Аннары, икенче станокка барып, балта сабы ясыйбыз.*

*Мин үзем генә түгел, күбәү идек без. Ике смена эшли идек. Эшләгән чаклар сагындырып тора иде.*

*Цехта дегет тә ясадык. 1966 елда. Урманда каен карьясы ап-кайтып бирәләр иде. Аларны казанга тутыра идек. Аның юллары бар иде. Шуннан ага иде. Су белән бергә. Шуннан өстән дегетен генә җыялар инде. Шуннан хозяин бутылкалар китерә иде. Бу-тылканы үзебез юып, үзебез хәзерли идек. Акчаны дегет кайнат-кан өчен генә түләделәр.*

***Авыл тарихы***

*Халык монда Казаннан килгән җыелышып бөтен әти-бабайлар. Шуңа Казанка булгандыр инде авыл. Өчәр-дүртәр бала белән килгәннәр. Башта Акбалыкта торганнар. Кайнана-кайна-талар сөйли иде. Дүрт бала белән килгәннәр. Аны сөйлиләр иде алар. Сәетбаттал абый булган, Салихә апай, Һаҗәр апай, тагын кем булгандыр. Алар 1921 елда килгәннәр.*

*Кайнанә булган Кибәхуҗадан. Бабайлар булган Сабинский районныкы. Әни 1914 елгы иде. Безне өч бала белән үстерде берүзе.* (Казанка авылы, Сабирова Фәризә Габделхак кызы, 1933 елгы.)

Халык бүгенге көнгә кадәр телен, гореф-гадәтләрен саклап яши. Акбалык авылы мәктәп директоры Мәүлетов Вильлюр Рәфыйк улы мәктәптә авыл тарихына караган документларны туп-ларга омтыла. Яшь буынга авыл тарихына, халыкның үткәненә мәхәббәт тәрбияләргә тырыша. Сүз уңаеннан, озак еллар Акбалык мәктәбе татар мәктәбе булган, ягъни бөтен фәннәр татар телендә укытылган.

## Каргат районы

2017 елгы экспедиция вакытында Каргат районының Муса, Форпост, Җәйләү һәм Кышлау авылларында да материал тупланды. Биредә бараба татарлары һәм Казаннан килгән татарлар яши. Авыллар күп чакрымнарга сузылып киткән сазлыклар арасында урнашкан. Новосибирск өлкәсенең зурлыгы буенча икенче урында торган Уба күле дә шушы район территориясенә керә. Бу күлдән кайчандыр дистәгә якын төр балык тотканнар. Ул күл якын-тирә авылларны ризык белән тәэмин итеп торган, халык тормышында мөһим роль уйнаган. Хәзерге вакытта 37 км озынлыктагы һәм 17 км киңлектәге күлнең тирәнлеге бер метрдан артмый. Күлнең саегуы аның экосистемасының бозылуына да китергән. Күлдән бигрәк сазлыкка охшап калган Убада бары вак кәрәкә балыгы гына калган.

Халык сөйләвенә караганда, Каргат районының исеме карагат, ягъни *карлыган* сүзеннән килеп чыккан. Биредә карлыган күп үсә, шуннан исеме килеп чыккан дип сөйлиләр. Елга исеменнән. Елга буенда карагат үскән!

**Муса авылының** исеме татарча булса да, биредә татарлар гына түгел, руслар да, башка халыклар да яши. Авыл исеме кеше исеменнән алынган. Риваятьләр бу исемне авылга нигез салган кеше исеме белән бәйли. Информантыбыз Зөфәр абый Сөләйманов авыл исеменең килеп чыгуын болай дип аңлатты: «*Бер бабай килгән Россиядән. Монда Хөснетдин Мифтахов бабайның Муса исемле улы үлгән. Шуны беренче итеп җирләгәннәр. Авыл исеме шуннан*».

Зөфәр абый сөйләве буенча, Муса авылына 1921 елгы ачлыктан качып килгән халык нигез салган. Халык Идел буеннан килгән. Оренбург өлкәсенең Габдрахман авылыннан килгәннәр дә булган. Алар башта Җәйләүгә килгәннәр. Җәйләү – бу яклардагы иң борынгы татар авылы. Җәйләүдән Сарыкамышка күчеп өч ел яшәгәннәр. Аннары бирегә күченгәннәр. Муса авылы төзеләчәк урында хутор кебек булып өч-дүрт йорт урнашкан була.

Муса авылы халкы һәрвакыт Сабан туйларын үткәреп, матур итеп кунакка йөрешеп яшәгән.

китабында татар теленең көнчыгыш диалекты сөйләмнәрен тулы чагылдырган фәнни транскрипциядә бирә. Фәрит Йосыпов, Флера Сәйфуллина, Олег Хисамов һәм Илһәм Гомәров төзегән «Бараба татарлары. Рухи культура сәхифәләре»[10] исемле коллектив хезмәттә Новосибирск өлкәсендә яшәүче бараба татарларының халык иҗаты үрнәкләре, халыкның тарихын, этнографиясен яктыртуга багышланган хезмәтләр тупланган. Җыентыкта авторларның экспедицияләр вакытында үзләре җыйган материаллар да, башка галимнәр туплаган, аларның хезмәтләреннән алынган текстларда бар.

Дөрия Рамазанованың «Татар диалектларыннан сөйләү үрнәкләре»[11] исемле җыентыгында да Новосибирск татарлары фольклорына да урын бирелгән. Флера Баязитованың «Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы»[12] исемле җыентыгында да Новосибирск татарларының фольклоры киң яктыртыла.

Л.В. Дмитриеваның «Язык барабинских татар» хезмәтендә дә Новосибирск өлкәсендә яшәүче барабалыларның төрле жанрга караган фольклорын табарга мөмкин.

Новосибирск өлкәсендә яшәүче татарларның рухи мирасын өйрәнү дәвам итә. 2017 елда Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан биредә яшәгән татарларның рухи һәм мәдәни дөньясын өйрәнү максаты белән оештырган фәнни экспедиция Новосибирск өлкәсенең Колыван һәм Каргат районнарында эшләде.

Колыван районында хәзерга вакытта татарлар Умар, Акбалык һәм Казанка авылларында яши.

---

[10] Юсупов Ф.Ю., Сайфуллина Ф.С., Хисамов О.Р., Гумеров И.Г. Барабинские татары. Страницы духовной культуры. Казань, Издательство Казанско го университета, 2013, 665 с.

[11] Рамазанова Д.Б. Татар диалектларыннан сөйләү үрнәкләре: хрестоматия. Казан: Татар.кит. нәшр., 2011. 565 б.

[12] Баязитова Ф.С. Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы» (йола һәм мифология текстлары яссылыгында). Казан, 2009. 736 б.

Умар авыл халкы фольклорны да яхшы белгән. 1967 елгы экспедиция барышында фольклорчылар Умар авылында бай фольклор материаллары туплаган. Бу авылда әкиятче Кәрим Кусовтан «Патша малае», «Алтын башлы, көмеш беләкле» әкиятләре язып алынган. Хәзерге вакытта авылда әкиятчеләрне табып булмый. Информантлар биргән мәгълүмат буенча, әкиятчелек традициясе 60–70 нче елларга кадәр дәвам иткән. Авыл халкы балаларга әкият сөйләгән «юмакчы» Рәстәм һәм Миңнеәхмәт бабайларны искә алдылар. Авылда халык җырларга да яраткан, халык репертуарында кыска җырлар да, озын көйләр дә булган. Фольклорчылар экспедицияләр вакытында Умар авылда җырлар да, мөнәҗәтләр дә язып алганнар.

Мөхәммәт Мәһдиев Умар һәм Акбалык авылларында язып алган җырлар турында болай дип язып куйган: Акбалык һәм Йорт-Умар авылы (Новосибирск өлкәсе) татарларының бөтен көнкүреше Өян, Обь суларына бәйле. Шуңа, ахрысы, аларның җырларында бу елгаларның исемнәре телгә еш алына. Себер татарларының җыр хәзинәсе бетмәс-төкәнмәс».[13] Әлегә җырлар белән укучыларны да таныштырабыз.

**Умар авыл татарлары җыры**

Казаннарга барам еле,
Обь сулары ачылма.
Уф йөрәгем димәм әле,
Янулары басылса.
    Чәчләремне тарыйм әле
    Уфа кызлары кебек.
    Айкала күңелем, чайкала
    Өян бозлары кебек.
Обь суларын карап торып
Агып китәрдәй булам.
Агып китеп, барып җитеп
Алып китәрдәй булам.

---

[13] Шунда ук, Б. 129.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр дилбегә.
Ямьле Умар буйларында
Тавышым калсын билгегә.

Омскидан Томскига,
Томскидан Самарга.
Санаулы көн түгел иде,
Калды инде санарга.

Әнә кинә автомобиль,
Төягәннәр әрдәнә,
Ялынып ятлар сөяргә
Безнең башлар гарьләнә.

Байкал күле, Байкал күле,
Байкал күле күбекле.
Күп эзләдем, табалмадым,
Дуслар, сезнең кебекне.

Байкал күле төпләреннән
Таптым ал кашлы йөзек,
Байкал күленә батсаң да,
Тартып алырмын йөзеп.

Байкал бит ул, байтак бит ул,
Ат белән әйләнсәң дә.
Кимсетмәгез, кимсенмәмен,
Кемнәргә бәйләнсәм дә.

Өян буе, Өян буе,
Өян сулары тәмле.
Өян суы эчкән кызлар
Нәзкәй билле, ак тәнле.

Биек тауның башларында
Усман байның тураты.
Берегез алма, берегез чия,
Берегез винограды.

Галим, авыл, халкының теленә игътибар итеп, болай дип язган: «Йорт-Умар – Обь елгасы ярына урнашкан Себер татарла-

ры авылы. Телләре безнең Казан татарлары теленнән бик нык аерыла, алар үзара сөйләшкәндә, без берни дә аңлый алмадык. Ләкин җырлаганда безнең җырлардагыча җырлыйлар»[14]. Хәзерге вакытта авыл халкы бараба сөйләшен белсә дә, безнең белән сөйләшкәндә, әдәби телгә күчәләр.

2017 елгы экспедиция вакытында Умар авылында халык иҗаты әсәрләренең матур үрнәкләре теркәлде.

Беренче информантыбыз Сәфәргалиева Рәйсә апа дини эчтәлекле фольклорны яхшы белә, аларның ишеткән берен дәфтәренә дә теркәп бара. Рәйсә ападан Коръән укыганнан соң укыла торган багышлау һәм башка дини эчтәлекле текстлар да язып алдык. Бу текстлар белән укучыларыбызны да таныштырып китәбез.

***Коръән багышлау***

*Я Раббым Аллаһ, ошбу укыган Коръәнемне үз фазыл-рәхмәтең белән кабул кылсаң иде, укуымда булган кимчелек-хаталарны гафу итсәң иде. Коръән укуымда булган әҗер-савапларны галәмгә рәхмәт итеп күндереп, хак рәсүлең Мөхәммәд салаллаһу галәйһи вәссәлләмнең рух шәрифләренә ирештереп, рухын шат кылсаң иде. Шулай ук әҗер-савапларын Пәйгамбәребезнең әһле гаиләсенә, сахабәләренә, барча булган әнбия һәм мөрсәлләргә, бездән дога өмет итеп яткан мәрхүм-мәрхүмә мөселман кардәшләребезнең рухларына ирештереп, рухларын шат әйләсәң иде.*

*Мәрхүм-мәрхүмә әти-әниләребезгә, әби-бабаларыбыз, якын кардәшләребезнең рухына ирештерсәң иде. Бәндәчелек белән кылган гөнаһларын, кимчелек-хаталарын гафу итсәң иде. Әҗер-савапларын арттырсаң иде. Иманнарын юлдаш кылып, үз рәхмәтеңә алып, ахыр урыннарын җәннәттә кылсаң иде.*

*Һәммәбезне бәла-казалардан, афәтләрдән имин кылып, калган гомерләребез Хак юлында, ислам динендә булып, Коръән тыйганнардан тыелып яшәүләребезне насыйп итсәң иде. Әҗәл вакытла-*

[14] Мәһдиев М.С. Себер татарлары иҗаты // Казан утлары. 1968. № 10. Б. 131–132.

*ры җитеп якты дөньядан ахирәткә күчкәндә, ахыргы сүзләребез «Лә иләһә иллаллаһ, Мөхәммәдүр-рәсүлуллаһ» булып, яхшы сүз белән мөселман булып, тулы иманыбыз белән үз каршыңа кайтып, вәгъдә кылган җәннәтләреңә, рәхмәтләреңә, ризалыгыңа ирешергә һәммәбезгә насыйп итсәң иде.*

### *Садакаларга дога кылу*

*И Раббым! Үзеңнең ризалыгыңны өмет итеп, Пәйгамбәребезнең шәфәгате өчен, ислам диненең алга баруын өмет итеп биргән бу бәндәләрнең хәер-садакаларын үзеңнең киң рәхмәтең белән кабул итсәң иде. Аллаһ ризалыгы өчен биргән садакаларыгыз кабул булып, Аллаһ Сөбханә Тәгалә уйламаган җирдән киң ризыклар, хәләл маллар ирештерсә иде. Аллаһ ризалыгы өчен биргән садакаларыгыз кабул булып, сездән өмет иткән җәмигы әрвахларыгызның рухы шат булса иде. Ошбу садака бирүчеләрне афәтләрдән саклагыл, Раббым. Аларның гөнаһларын гафу кыл, иманнарын куәтле кылгыл.*

*Безне сораусыз җәннәтеңә кертсәң иде һәм үзеңне пәрдәсез күрергә насыйп итсәң иде, Раббым. Газап кылма безне үлгәннән соң, җиңгел кыл үлем хәлләрен, Раббым! Амин.*

Рәйсә ападан мөнәҗәт һәм салават текстлары да язып алдык. Мөнәҗәтләр, – нигездә, дини эчтәлекле әсәрләр. *Мөнәҗәт* сүзе гарәп теленнән кергән, ул Аллаһыга ялвару, мактау сүзләре әйтү[15] дигәнне аңлата. Кеше, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп, күңелендәге моң-зарларын сөйли, яшәеш һәм мәңгелек, эш-гамәлләре турында уйлана. Аллаһы Тәгаләгә мәдхия укыган, Коръән турындагы мөнәҗәтләр дә еш очрый. Рамазан аена багышланган, ураза тотуның савабын сөйләгән мөнәҗәтләр дә шактый. Кайбер мөнәҗәтләрдә кеше үлем турында уйлана. Бу дөньяның вакытлы булуын, яхшылык, изге гамәлләр кылып яшәргә кирәген искәртә.

Рәйсә ападан язып алган беренче мөнәҗәттә ураза тотуның савабы турында бәян ителә.

---

[15] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. Б. 379.

**Мөнәҗәт**

*Сәхәрләргә тораек,*
*Сәхәр торып, аяк бассак,*
*Адымнары саен савап,*
*Сәхәр торып намаз кылсак,*
*Насыйп булыр безгә савап.*
*Салаватны күп әйтиек,*
*Сәхәр чәйләрен эчкәндә.*
*Фәрештәләр каршы алыр,*
*Сират күперен кичкәндә.*
*Сәхәргә торучыларга,*
*Гыйбадәт кылучыларга*
*Дөнья-ахирәт сәгадәтен*
*Ирештерсен үзе Аллаһ.*
*Сәхәр торып намаз кылсаң,*
*Җиңел кылыр үзе Аллаһ.*
*Сәхәр торып тәһәрәт ал,*
*Укы сәхәр намазыңны.*
*Салаватны күп әйтегез,*
*Сәхәргә һәм торыгыз,*
*Тәмуг утларын күрмәссез,*
*Уразаларны тотсагыз.*
*Салаватны күп әйтегез,*
*Сәхәр чәйләрен эчкәндә.*
*Фәрештәләр каршы алыр,*
*Сират күперен кичкәндә.*

Татар халкында эчтәлекләре белән мөнәҗәтләргә якын торган салаватлар да әйткәннәр. Салават – Мөхәммәт пәйгамбәргә багышланган, көйләп башкарыла торган текстлар.

**Салават**

Унсигез мең галимнәргә җавап биргән Мөхәммәд.

Аллаһүммә салли галә сәйидинә Мөхәммәдин вә галә әли Мөхәммәд

Ятимнәргә, гарипләргә шәфкатьле ул Мөхәммәд.

Аллаһүммә салли галә сәйидинә Мөхәммәдин вә галә әли Мөхәммәд.

Ураза тоткан өммәтенә шәфкатьле ул Мөхәммәд.

Аллаһүммә салли галә сәйидинә Мөхәммәдин вә галә әли Мөхәммәд

Коръән укыган өммәтенә шәфкатьле ул Мөхәммәд.

Аллаһүммә салли галә сәйидинә Мөхәммәдин вә галә әли Мөхәммәд

Әбүҗәһелгә шәфкатьле ул Мөхәммәд.

Аллаһүммә салли галә сәйидинә Мөхәммәдин вә галә әли Мөхәммәд

Салават әйтүчеләргә шәфкатьле ул Мөхәммәд.

Коръән мәҗлесләрендә башкарыла торган мөнәҗәтләрдә йорт хуҗаларына рәхмәт әйтәләр, Коръән укытуның савабын искә төшерәләр. Коръән мәҗлесләрендә көйләп мөнәҗәт әйтү традициясе татарлар яшәгән күп төбәкләрдә мәгълүм.

***Мөнәҗәт***

*Килеп кердем өегезгә,*
*Дога кылдым түрегездә.*
*И Ходаем, иман нуры*
*Балкып торсын йөзегездә.*

*Мәҗлесегез күркәм булсын,*
*Өегезгә нурлар тулсын,*
*Догалары кабул булсын,*
*Әрвахлары сөенеп торсын.*

*Килеп кердек өегезгә,*
*Тәсбих күрдек түрегездә.*
*Тәсбих әҗерләрен бирсен*
*Бер Ходаем үзегезгә.*

*Килеп кердем өегезгә,*
*Тәсбих нуры йөзегездә.*
*Тәсбих әҗерләрен бирсен*
*Бер Раббым үзегезгә.*

*Ошбу өйнең хуҗасына,*
*Дәхи балаларына,*
*Дәхи ата-анасына*
*Рәхмәтен бирсен Аллаһ.*

*Сагынып килдем үзегезне,*
*Дәхи күрдем йөзегезне,*
*Безне каршы алган кебек*
*Хурлар каршы алсын сезне.*

*Әй туганнар, сыйладыгыз*
*Татлы нигъмәтләр белән.*
*Ходаем сыйласын сезне*
*Җәннәт алмалары белән.*

*Ничә төрле тәгам җыйдым*
*Бу хуҗаның түрләрендә.*
*Кыямәт көне булганда,*
*Нур уйнасын йөзләрендә.*

*Ничә төрле аш әзерләп,*
*Безләрне монда өндәде.*
*Гөнаһларын гафу кылып,*
*Җәннәтле ит бу бәндәне.*

*Өстәлләрдә төрле нигъмәт,*
*Төрлесендә төрле ләззәт.*
*Боларны әзерләүчегә*
*Ходай үзе бирсен җәннәт.*

*Остазлар булган мәҗлестә*
*Була тәгамнәре тәмле.*
*Аларның йөзләре нурлы*
*Һәм сүзләре нәзәкатьле.*

*Бу мәҗлеснең кадерен белик,*
*Ходайга күп зекер кылыйк.*
*Дин исламда булган өчен,*
*Шатланышып шөкер кыйлыйк.*

*Ходайның рәхмәтен тотып,*
*Коръән укытса бер кеше,*
*Гүзәл егет сурәтендә*
*Килер икән олуг Коръән.*

*Ходай каләмедер Коръән,*
*Безгә дигән олуг китап.*
*Коръән белән гамәл кылсак,*
*Ходай кылыр җиңгел хисаб.*

*Мәхшәр көндә, каты көндә*
*Сәлам бирер икән Коръән.*
*Коръән укыткан бәндәләрне*
*Җәннәтләргә илтә Коръән.*

*И туганнар, сыйладыгыз*
*Җәннәт нигъмәтләре белән.*
*Безне хөрмәтләгән өчен*
*Хурлар каршы алсын сезне.*

*И Ходаем-ходаем,*
*Син яраттың үзең безне.*
*Сигез оҗмах суы белән*
*Югыл безнең йөзебезне.*

*Сәхрәләрдә бер агач бар,*
*Тәсбих әйтә кошлар кунгач.*
*Җәннәтеңдә өметем бар,*
*Мөхәммәт өммәте булгач.*

*Минем бүләгем юк сезгә,*
*Теләк бүләкләрем сезгә.*
*Аллаһ биргән бүләгем бар*
*Хәер-дога кылам сезгә.*

*Раббым гомерләрне бирсә,*
*Тагын да бер күрешербез.*
*Иманыбыз камил булса,*
*Җәннәтләрдә күрешербез.*

*Укы, дисәгез, укырмын,*
*Күңелләрегез ачылсын.*
*Сигез җәннәт эчләренә*
*Ризыкларыгыз чәчелсен.*

*Әй дусларым, беләсезме,*
*Гомер үтә, сизәсезме?!*
*Бу гомерләр үткәннән соң,*
*Ниләр булыр, беләсезме?!*

*Бу дөньядан китәрбезләр,*
*Әҗәл суын эчәрбезләр.*
*Бер гамәлсез үләр булсак,*
*Кыяматтә нишләрбезләр?*

(Умар авыл, Сәфәргалиева Рәйсә Хәбибулла кызы, 1934 елгы. Акбалык авылында туган. Умар авыл егетенә кияүгә чыгып күчеп килгән. Хәзер Новосибирск шәһәрендә яши. Умарда туган.)

Умар авылда календарь йолалар турында да мәгълүмат тупланды. Умарда «Боз озату» йоласы популяр булган. Себер татарларында булган «Карга боткасы» яки «Карабакчар туе» (сыерчык туе) уздыру бу якларда сакланмаган. Бары кошлар кайтканда аларның кайтканын күреп, алар белән исәнләшәләр, хәлләрен сорашалар. Язын кошлар кайту бәйрәме дә – җирнең уянуын, тормышның яңаруын бәйрәм итү. Бәйрәмнең асылында кара каргаларның яки сыерчыкларның җиргә яз, җылы алып кайтуларына ышану ята. Борынгылар җирнең салкын кардан арынуын, кыш бетеп яз башлануын язын җылы яклардан кошлар кайта башлау белән бәйләнештә караган. Көзен иң соңгы кошлар, җылы якларга киткәндә, җирнең җанын да үзләре белән алып китә, алар китү белән, җир «йокыга тала». Халык кошлар кайтуын көтеп яшәгән. Кара каргалар яки сыерчыклар яз көне җирнең җанын кире алып кайта, алар кайткач, җир «уяна» дип ышанганнар.

### ***Карабакчи***

*Сыерчыкларны күргәч, карабакчи дип әйтәбез аларны, сәлам әйтәбез аларга. «Исән-сау кайттыгызмы?» – дибез.*

(Умар, Шәһәбетдинова Гөлҗиһан Зөлкарнәй кызы.)

*Карабакчилар килгәч, аларга ашарга салабыз.*

(Умар авыл, Вәлиева Гөлбәзәр Таштимер кызы.)

*Карабакчилар килсә, быел күрдек, киләсе елларда да тагын күрергә язсын дип әйтәбез.*

(Умар авыл, Нурисламова Галия Зәйдулла кызы.)

Татар халкы яшәгән барлык төбәкләрдә таралган «Яңгыр боткасы» яки «Яңгыр туе» йоласы биредә дә мәгълүм. Яңгыр боткасы корылык булганда, озак яңгыр яумый торганда уздырыла. Ул – бик борынгы заманнарда, мәҗүсилек чорында барлыкка килгән йола, Су иясенә корбан бирүнең бер төре булган. Мәҗүсилек чорында Су ияләренә корбан суеп, корылык җибәрмәвен яки яңгыр сораганнар. Су иясе кара төстәге терлекләрне ярата дип ышанганнар. Шуңа күрә тегермәнчеләр дә бары кара төстәге терлек кенә

асраган. Корбанга да кара төстәге терлек суелган. Әлеге йоланың эзләре балалар фольклорында, эндәшләрдә сакланган:

*Яңгыр, яу, яу!*
*Кара сарык суярмын,*
*Ботын сиңа куярмын.*

Шулай ук балалар, су коенып чыкканда:

*Исәнлегем – саулыгым,*
*Тазалыгым-байлыгым.*
*Сиңа яулык,*
*Миңа саулык, –*

дип чыгалар. Бу да су анасына бүләк бирүне аңлата.

Кагыйдә буларак, авыл халкы, озак яңгыр булмаганда, йорт саен яңгыр боткасы өчен ризык, мәсәлән, төрле ярмалар, май, йомырка җыеп, су буена барган. Анда яңгыр боткасы өчен авыл халкы алган сарык суелган. Догалар укыганнар, яңгыр сораганнар.

***Яңгыр сорау***

*Коръән укый торган бер карт бар иде. Бер елны озак яңгыр яумады. Авылда сөйләшеп, бер сарык алып, ерак түгел күл буена барып, шул сарыкны суеп, Коръән укып, яңгыр теләгән идек. Шул сарык итеннән аш пешереп анда.*

*Соңыннан яңгыр яуган иде.*

(Умар, Шәһәбетдинова Гөлҗиһан Зөлкарнәй кызы.)

Язын кар эреп, боз киткәннән соң, яшьләр, җыелып, круг уенына чыкканнар. «Йөзек салыш» уйнаганнар. Шушы уеннар вакытында яшьләр үзара аралашкан, танышкан, табышкан. Шулай ук «Наза», «Как та йөгер» уеннарын уйнаганнар.

*Элек яз җитүгә, тау башына чыга идек. Какты-йөгерде уйный идек. Төрле уеннар уйный идек.Торасың ике рәт булып, кара-каршы. Бер якта малайлар торалар, бер якта кызлар торалар. Бер яктан килгән егет икенче яктагы кызга кага да йөгерә. Ул кыз аның артыннан йөгерә. Тотса, кире әйләнеп килеп, кыз*

*ягына басалар. Тотмаса, һәркайсы үз урынына кире баса. Аннан, киресенчә, кыз ягыннан чыгып кагып йөгерә.*

(Умар, Шәһәбетдинова Гөлҗиһан Зөлкарнәй кызы.)

Караңгы төшә башласа, мәсәлән, йөргән йегетем бармы минем, мин аны, или ул мине кага да китеп калабыз качып. Менә как та йөгер була, кагасың да йөгереп китәсең.

Төрле җырлар җырлый идек.Уйнаган җирне Каш башы дип атый идек. Мин киттем Каш башына дип сөйләшә идек.

(Умар авыл, Сәфәргалиева Рәйсә Хәбибулла кызы.)

*Тотынып, круг уйный торган идек. Анда җырлыйсың инде. Парлап-парлап чыгаралар иде егет белән кызны. Круг әйләнеп җырлап аласың да, аннан соң мин сайлыймын үз урыныма башка кешене, икенче кеше дә шулай.*

(Умар авыл, Сәфәргалиева Рәйсә Хәбибулла кызы.)

Умар апалары шактый гына кыска җырлар да җырлап күрсәттеләр. Дүрт юлдан торган җырлар татар халык иҗатының зур өлешен алып тора. Бу җырлар бүгенге көнгә кадәр татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә популяр. Шулай да бу әсәрләрнең гаять зур миссиясе бар. Алар, безнең кайда яшәвебезгә карамастан, бер халык булуыбызны исбатлап торалар. Бу кадерле мирас әби-бабайдан, ата-анадан балага күчә бара. Халык тормышының иң әһәмиятле борылышларында, бәйрәмнәрендә туган телендә җырлый. Шул рәвешле, үзенең тамырлары белән, туганнары белән бәйләнешне ныгыта. Шушы җырлар аша киләчәгенең бәхетле булуына тәэсир итәргә омтыла. Әби-бабалар җырлаган җырларны җырлау кешегә буыннар бәйләнешен тоярга да ярдәм итә. Шул җырлар аша еракта калган әби-бабаларыбызның рухын тоябыз.

Һәр сүзе урынлы кулланылган, энҗе кебек төзелгән, эчтәлегенең һәм строфа төзелешенең камиллеге сокландырган дүрт юллык бу җырларда кешенең эчке кичерешләре бәян ителә. Кеше үзенең сагыш-моңы, сагынуы, юксынуы, яратуы,

сөенеч-шатлыклары белән уртаклаша. Телдән әйтеп бирә алмаган хисләрен җыр белән белдерә. Әлеге җырларның тематик төркемнәре дә шактый. Алар арасында туган илне ярату, сагыну яки туган җирдән аерылу турындагы җырлар әһәмиятле урынны алып тора. Туган ил образы туган авыл, кызлар су ала торган чишмә, елга-күлләр, урман-тугайлар аша сурәтләнә. Туган илгә багышланган җырларның күпчелегендә лирик геройның сагыну хисе гәүдәләнә.

Шулай да мәхәббәт җырлары – әлеге җырлар арасында сан ягыннан иң күп әсәрләр. Мәхәббәт җырлары төрле яшьләр уеннары вакытында да, бәйрәмнәрдә дә башкарылган. Аларда яшьләрнең хисләре, өметләре, ышанычлары яки аерылу-сагышлары бәян ителә. Әлбәттә, экспедиция вакытында язып алынган җырларның иң зур күпчелеге мәхәббәт турында.

*Әй дусларым, сезнең белән*
*Шат минем күңелләрем.*
*Тагы да шулай шатлык белән*
*Үтсәйде гомерләрем.*

*Айларга карасам да,*
*Йолдызлар санасам да.*
*«Сез бәхетле» дигән кебек,*
*Кемнәргә карасам да.*

*Ак чәчкә ата гөлем,*
*Күк чәчкә ата гөлем.*
*Сандугачтай сайрар идем,*
*Белсәм сандугач телен.*

*Алма ал була икән,*
*Эче бал була микән?*
*Җырласам янмый йөрәгем,*
*Әллә ял була микән?*

*Аллы-гөлле чәчәк атты*
*Өй артында бакчада.*
*Узган гомер кире килми,*
*Сулар кире акса да.*

*Алма бакчасында үзем,*
*Гөл бакчасында күзем.*
*Сагынам үзем, юлда күзем,*
*Саргайды нурлы йөзем.*

*Әй дусларым-дусларым,*
*Дусларым дус-ишләрем.*
*Сез дуслардан аерылсам,*
*Ялгыз башым нишләрмен?*

*Бөдрә таллар сыгылмый ул,*
*Сандугач тезелсә дә.*
*Бер аерылгач түзәм инде,*
*Йөрәгем өзелсә дә.*

*Базарларда лимон саталар*
*Яшел яшнеге (ящигы) белән.*
*Сөймәгән дә булыр идем,*
*Сөйдем яшьлегем белән.*

*Үтә айлар, үтә еллар,*
*Үтә санаусыз көннәр.*
*Бер үткәчтен кире кайтмый*
*Минут түгел секундлар.*

*Агыйдел буйлары ямьле*
*Аккошлар уйнаганга.*
*Яшь гомерләр бик тиз үтә,*
*Гел уйлар уйлаганга.*

*Җыр җырласаң акрын җырла,*
*Тавышың каралмасын.*
*Сүнгән йөрәк сүнсен инде,*
*Ул тагын яңармасын.*

*Сезне былбыл дияр идем,*
*Алмагачка кунсагыз.*
*Күкрәгемә кадар идем,*
*Алсу сачәк булсагыз.*

(Умар авыл, Шәһәбетдинова Гөлҗиһан Зөлкарнәй кызы, Сәфәргалиева Рәйсә Хәбибулла кызы.)

Хәзерге вакытта иң популяр жанрларның берсе – мифологик хикәятләр. Мифологик хикәятләр дигәндә, төрле мифик затлар белән очрашуны, аларны күрүне бәян иткән хикәятләрне күз алдында тотабыз. Бер төрләрендә информант әлеге затларны үз күзе белән күрүен сөйли, икенчеләрендә аларны берәр танышының яки танышының танышы күрүен бәян итә. Бу вакыйгалар һәрвакыт реаль шаһитларның исеме, төгәл урыны күрсәтелү белән дә чынбарлыкка дәгъва итә. Һәр очракта сөйләнгән хикәят булган хәл буларак сөйләнә һәм тыңлаучылар тарафыннан да чынбарлыкта булган хәл буларак кабул ителә. Ышаныргамы, юкмы икәнен һәр кеше үзе хәл итә. Бер кеше өчен ул чынбарлыкның бер күренеше булса, икенче кеше өчен күңел ачканда сөйләнә торган хикәя генә булып тора.

Мифологик хикәятләрнең иң популярларында Су анасы яки Су иясе, Йорт иясе һәм Абзар хуҗасы, Урман хуҗасы, Убыр белән очрашулар, аларның функцияләре һәм кылган гамәлләре турында сүз бара.

Умар авыл зур елга – Обь янында урнашкан булганга, биредә Су анасы турында мифологик хикәятләр дә күп. Су анасы – татар мифологиясендә иң популяр су иясе. Татар халкының мифологик хикәятләре буенча, ул елга-күлләрдә яши. Татар халкында «Иясез су юк» дигән ышану да бар. Кагыйдә буларак, мифларда Су анасы матур яки киресенчә куркыныч хатын-кыз итеп тасвирлана.

Су анасын халыкның күзаллавы Габдулла Тукайның «Су анасы» әкият-поэмасындагы сурәтенә туры килә. Гадәттә, аның су буенда чәч тарап утырганын күрәләр:

Бервакыт китәм дигәндә төште күзем басмага;
Карасам: бер куркыныч хатын утырган басмада.
Көнгә каршы ялтырый кулындагы алтын тарак;
Шул тарак берлән утыра тузгыган сачен тарап.
Тын да алмыйча торам, куркып кына, тешне кысып,
Шунда яр буендагы куе агачларга посып.
Сачләрен үргәч тарап, сикерде төште суга ул;
Чумды да китте, тәмам юк булды күздән шунда ул.

Халык Су анасын үзе күрүе турында да сөйли, башкалар сүзенә таянып, аларны шаһит итеп сөйләнгән хикәятләр дә бар. Бер яктан, мифологик хикәятләрдә классик Су анасы образы гәүдәләнсә, икенче яктан, һәр сулыкның иясе булып, аның төрле хайван, җәнлек кебек күзгә күренүе бәян ителә. Су анасы яки Су ияләре турындагы хикәятләрнең нигезендә табигатькә, туган якка мәхәббәт, табигатьне саклау ята. Аларда теләсә кайчан су коенырга ярамау, ягъни сулыкларның тынычлыгын саклау, сулыкларны чиста тоту мәсьәләләре күтәрелә. Кичен, кояш баеганнан соң, су коенырга ярамый. Кояш баеганнан соңгы вакыт төрле ияләрнең вакыты булып санала дип сөйлиләр. Ышанулар буенча кеше өчен иң куркыныч вакыт – параллель дөнья вәкилләре бигрәк тә активлашып китә торган кояш баеган чак. Бу вакытта су буена бармыйлар, тәрәзәдән карамыйлар, мунча кермиләр. Мәсәлән, ышану буенча, кич белән тынычлыгын бозып йөрсәң, мунча пәрие ташларны җимерә. Кеше, вакытка да карамастан кайда гына керсә дә, җиде адым кала тамак кырырга тиеш. Ул вакыт эчендә качасы зат качып өлгерә дип ышаналар.

### *Акбалык һәм Казанка*

Акбалык һәм Казанка авыллары – үзара аралашып яши торган күрше авыллар. Акбалык авылы Өян елгасы буена урнашкан, хәзерге вакытта биредә җирле һәм килгән халык үзара катнашып беткән. Һәр нәселнең, һәр гаиләнең ике яктан килгән бабалары турында истәлекләре бар.

Акбалык та, Казанка да – матур, чиста авыллар, урамнар төз. Дөрес, ике авылда да яшьләр аз. Алар, эш булмау сәбәпле, шәһәрләргә китә. Авыл халкы татарча сөйләшә. Кунакка кайткан яшьләр телне онытa бара, күбесе русчалы-татарчалы аралаша. Шәһәрдән кунакка кайткан яшь информантлар, русча сөйләшә-сөйләшә, әби-бабаларыннан ишеткән фольклор үрнәкләрен татар телендә яздырдылар. Әби-бабалары турында сөйләшкәндә, татарчага күчәргә тырышалар. Туган телне саклар өчен, ата-ана гына түгел, әби-бабай тәрбиясе дә кирәк икән. Нәселдән-нәселгә күчә торган рухи кыйммәтләрне нәкъ менә әби-бабайлар бирә ала. Информантларыбыз белән аралашканда, «Боларны әбием сөйләде», «боларны бабам сөйләде» дип, горурланып әйтәләр. Алар өйрәткәннәргә, алардан ишеткәннәргә зур ихтирам сизелә.

Акбалык һәм Казанка авылларында Институтның 1967 елгы экспедициясе вакытында бай материал тупланган, биредә әкиятләр, җырлар, уен һәм йола җырлары язып алынган. Бу текстлар «Татар халык иҗаты» күптомлыгында да урын алган. Мәсәлән, шушы күптомлыкның «Йола һәм уен җырлары» китабында Халидә Гатина тарафыннан Акбалык авылында 1908 елда туган Нәфисә әби Әмировадан язып алынган «Кабыр-кабыр камчылы» уен җыры һәм уен тәртибе урнаштырылган. Шушы ук китапка кергән икенче җырны фольклорчы Хуҗиәхмәт Мәхмүтов җәйләүдәге сыер савучы кызлардан язып алган. Алар «Наза» уенын уйнап, җырларын җырлап күрсәткәннәр. Х.Ш. Мәхмүтов бу уенның яшьләр арасында бик таралган булуын искәртә. Өстәп шуны да әйтергә мөмкин: «Наза» җырлы уены, «Сарман буйлары» җыры кебек үк, татарлар яшәгән барлык регионнарда мәгълүм һәм популяр, халыкның бер булуын күрсәткән рухи маркеры булып тора.

Шул ук экспедиция вакытында Казанка авылында яшәүче Вәлиуллина Әкълимә ападан «Агым су», «Нечкә бил, сөясеңме?» җырлары, Миннаһудина Гөлмиҗиһан ападан «Бибисара җырлары» язып алынган.

Акбалык авылында да, Казанка авылында да җыр-моңга гашыйк халык яшәгән.

Мөхәммәт Мәһдиев Акбалык авылында язып алган кыска җырларны «Акбалык авылы татарлары җырлары» дигән баш астында «Казан утлары» журналында бастыра. Бу җырларга кадәр язучы түбәндәге искәрмәне язып куйган: «Акбалык — тайга эчендәге борынгы Себер авылы. Ләкин соңгы гасырда бу авыл янына Теләче, Саба, Арча якларыннан күчеп килгән кешеләр Казанка исемле бер авыл төзегәннәр. Акбалык татарларына безнең җырларга охшаш җырлар шул Казанка аркылы кергән булырга тиеш. Югыйсә йөз чакрымнар тирәсендә монда башка бер генә татар авылы да юк».

Минем чапкан покосымны
Дусларым үлчәтмәсен.
Су астында җан бирүне
Ходаем күрсәтмәсен.

Ике җирән, ике кашка
Басып киләләр ташка.
Ашый да алмыйм, эчә дә алмыйм
Сез туганнардан башка.

Әнә килә пароход,
Обь суларын таратып.
Ерак юлны якын итеп
Килдем сезне яратып.

Борылып менгән, сызылып төшкән
Безнең артта су юлы.
Исән килдеңме, җаный, дип
Суырып үпте бу юлы.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нәгыймә.
Кар йомарлап, карлар тотам
Әрнегән йөрәгемә.

2018 елгы экспедиция вакытында биредә элегрәк бәетләрнең дә популяр булганлыгы билгеле булды. Әмма хәзерге вакытта бәетләр онытылып бара. Бертуган Нәсыйхә һәм Мәйсәрвәр апаларның дәфтәрендә «Сак-Сок» бәетенең бер варианты сакла-

на. Бу бәет татар халкында киң тарылган булып, аның дистәләгән вариантлары мәгълүм. Акбалык авылында язып алынган вариант белән укучыларны да таныштырып китәргә телибез. Бу вариантта нигездә башка вариантларда да булган строфалар белән әлегә кадәр очрамаганнары да бар.

***Сак-Сук***

Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
Сак белән Сукның бәетен иштәсе.
Мәдрәсәләрдә пияла ишек,
Сак белән Сукның бәетен ишет.
Әнкәй каргады тимер ук өчен,
Әнкәй каргады бигрәк юк өчен.
Җимнәр ташыйдыр кошлар басудан,
Әнкәй каргады безне ачудан.
Самавар куйды, чәйләр эчерде,
Эчеп бетергәч, каргап очырды.
Яңа тунымны ботак ерткандыр,
Гомерем беткәнгә җаным тарткандыр.
Әткәй калдырды, өйдә торсын, дип,
Әнкәй каргады, Сак-Сук булсын, дип.
Кыйбла ягыннан җилләр исәдер,
Безнең ризыкны әнкәй кисәдер.
Бардык урманга, җыйдык карлыган,
Без ятимнәрне әнкәй каргаган.
Төшкәндер безгә әнкәй каргышы,
Үзебез туганчы тәкъдир язмышы.
Әнкәй каргагач, Сак-Сук булдык без,
Бу дөньяларга гыйбрәт булдык без.
Су буйларында бик күп йөрдек без,
Сак-Сук булгачтын, дөнья гиздек без.
Кистем пар нарат яңа ызбага,
Ике күземнән канлы яшь ага.
Су буйларында бала үрдәкләр,
Искә төшкәндә өзелә үзәкләр.

Аклы күлмәкне туя кимәдем,
Газиз әнкәмне туя күрмәдем.
Бер ел тулганчы кайтам дип йөрдем,
Бер ел тулгачтын өметне өздем.
    Урныбыз – урман, икебез туган.
    Кавышу юк безгә, әнкәй каргаган.
    Өйгән кибәнне җилләр тарата,
    Кавышабыз дигәч, хәзер таң ата.
Кояш чыкканда кан тула күзгә,
Кыямәт көнсез кавышу юк безгә.
Бардым урманга, кистем пар каен,
Газиз әнкәмне сагынам көн саен.
    Мамык эшләпәм алып кайтыгыз,
    Әнкәмне күргәч сәлам әйтегез.
    Мамык эшләпәм җилгә очырдым,
    Ике баламны каргап очырдым.
Җәйгән җәймәмнең калды яртысы,
Ике баламның калмады берсе.
Моңлы моңлансын, зарлы саргайсын,
Балаң очырдың, кемгә еларсың?
    Идел буенда диңгез камышы,
    Кара урманда Сак-Сук тавышы.
    Яңгыр явадыр әнкәй башыма,
    Егълап килдек без әнкәй каршыңа.
Әнкәй елыйдыр, ник каргадым дип,
Сак-Сук йөридер харап булдык дип.
Бардык урманга җиләкләр пешкәч,
Әнкәй елыйдыр исенә төшкәч.
    Кара карлыгач, сары сандугач,
    Әнкәй, елама, үзең каргагач.
    Болай булдык без, әнкәй каргышы,
    Елама, әткәй, Ходай язмышы.
Калган киемне алып куярсың,
Исеңә төшкәч, алып иснәрсең.
Китап укырсың, гыйбрәт алырсың,
Кошлар очканда карап калырсың.

Имезгән сөткә, әнкәй, рәнҗемә,
Кыямәт көнсез күрешү юк безгә.
Газиз әнкәем, бер сүз әйтәем,
Бәхиллек бирсәң, өйгә кайтаем.
Сары күлмәгем һәч тә кимәдем,
Өйдән чыкканда, сау бул, димәдем.
Якты дөньяны күрми калабыз,
Каргады безне газиз анабыз.
Йокыга киткәч, бер төш күрдек без,
Кара урманда очып йөрдек без.
Су буйларында балалы үрдәк,
Искә төшкәндә өзелә үзәк.
Алты яшькәчә бергә йөрдек без,
Җиде яшьләрдә Сак-Сук идек без.
Әнкәй токмачны үзең күп иттең,
Әткәй кайтканчы безне юк иттең.
Әткәбез калды безнең мәчеттә,
Без тилмерәбез икебез читтә.
Әнкәй, кер юдың Идел буенда,
Сак-Сук булыр дип юктыр уеңда.
Бардым урманга, бастым баланга,
Балаң елыйдыр кара урманда.
Алдагы көнне икәү уйнадык,
Әнкәй каргар дип без уйламадык.
Әнкәй каргады, әткәй белдеңме,
Турыңнан уздык, әткәй күрдеңме?
Ишегалдымда имән дугасы,
Әткәй елама, әнкәй догасы.

(Акбалык авылы, Ризванова Нәсыйхә Әбүбәкер кызы, 1934 елгы. Батуринда туган, алты яшендә Акбалыкка күчкәннәр; Хасанова Мәйсәрвәр Әбүбәкер кызы, 1946 елгы.)

Акбалыкта язып алынган истәлекләрдә халык тормышының төрле ягы чагылыш таба. Халык борынгы йолаларын, ышануларын да хәтерли. Информантлар күмәк эш, бәйрәмнәр дә турында да теләп искә төшерәләр.

### ***Курчаклар турында***

*Авылның түбән очның бу ягын «курчаклылар» диләр иде. Ширманыста да курчаклылар булган. Алар мөселман түгел. Урыслар яшәгән анда. Татарлар да булган.*

### ***Йорт өмәсе***

*Әле бик күптән вакыт та түгел, әле илленче елларда өмә белән өй салганнар, йортлар салганнар. Менә бу йорт та – өмә белән салган йорт. Пумыщ белән диләр инде. Безнең йортыбыз да шулай ук салынган. В основном харендәш-туганы җыела ул вакытта. Күрәсең, алдан шулай үзара сөйләшеп куя торганнардыр. Туганнар арасында, иптәшләр арасында. Специально чакырып йөргәнне мин белмимен. Ашатмыйча җибәрмәгәннәр инде. Мәҗлес аракы белән бетә торган иде. Ашаусыз булмаган инде, ашатканнар канешны. Кайтып йөрмәгәннәр өйләргә. Өй туе дигән әйбер юк иде. Коръән укыткannardыр инде яңа өйгә, ә болай өй туе дигән сүз юк.*

### ***Сабантуй***

*Сабантуйда йомырка буяп уйныйлар инде. Йөгертә торганнар иде. Йөгерешәләр иде. Сугыштан соң бер-ике тапкыр булды ул, булгалады. Ат чабыштыралар иде. Суны, чиләккә тутырып, түкмичә генә китереп җиткерү. Бабалар бүләк җыеп йөриләр Сабантуйга. Музыка алалар. Чүпрәкләр булса инде бәйлиләр иде бер шестька. Таякка бәйләп куялар чүпрәкләрне. Кем нәрсә бирә инде анда. Тегеннән шулай килгән ул. Кычкыралар:«Ура, ура», – дип, чыгарып бирәләр дә бүләк, дальше китәләр.*

### ***Туй, никах, кыз урлау турында***

*Менә безнең яшьлек заманасында кызны урлыйлар иде. Сөйләшеп куялар да барып алып кайталар. Ат белән дә урлап кайталар иде инде. Умар авылыннан Акбалык авылына да кыз китерә торган мода булган. Сөйләшеп, конечно, әйтмичә түгел. Ата-аналары белән барып сөйләшәләр инде аннары соң. Никахны шул ук көнне кайткач та укыталар.*

*Туйны башта кыз якта ясыйлар инде, соратып кайткан булса, аннан егет якта. Урлап кайткан булса, башта егет якта. Аннан кыз якта. Ике якта да ясыйлар иде. Кайда бер көн ясый, кайда икешәр көн була. Кайда ничек. Кемнең нинди мөмкинлеге бар. Бөтен карендәш-туганны җыеп ясыйлар инде. Утызар-утыз бишәр кеше була каждый яктан, даже кырыгар кеше була. Бөтен раднясы җыела бит.*

### Сугыш турында

*Менә Гариф акам ул вакытта инде ул олы булган. Эш кешесе булган. Сугыш башында Гариф акама ничә яшь булган. Унтугызмы? 1923 елгы ул. Газет укый торган иде. Әнием әйтә, газетны укый да башын салып, менә шулай уйланып утыра дия торган иде. Ул бер төрле чамалаган инде сугышны. 17 яшь булган аңа. Ике сугышта булды. Германиядә башта, аннары Востокта. Ә моңардан олысы эшли иде ул вакытта изба-читальня диләр иде инде библиотеканы. Шунда эшли иде. Алар укыганнар инде. Алар бертөрле аңлаганнар. Олысын алып киттеләр. (Хәтимә апаны.)*

(Акбалык авылы, Зәйнуллин Әбүзәр Абдрахман улы, 1932 елгы. Бабалары Арча ягыннан килгән. Әнисе 1908 елда, бирегә килгәч туган. Механизатор һәм «Новотроицк» совхозының управляющие булган; Гиниятуллина Хәтимә Нәбиулла кызы, 1932 елгы, пенсиядәге укытучы.)

### Репрессия еллары турында

*Репрессия елларында монда да җәбер-золым күп булган. Кирәкмәгән кешеләрне озатканнар. Берәүләр бик кешегә зыян салганнар. Корбан бабай булган. Шул әйткән: «Крестьянны бетерделәр», – дигән. Икенче көнне алып киткәннәр.*

(Акбалык авылы, Мәүлетов Рафик Шәфикович, 1938 елгы. Механизатор һәм егерь. Әниләре, 1921 ачлыктан качып, Алтайга киләләр. Гайни әби белән Минһаҗетдин бабай Саба районы Кибәхуҗа авылыннан булганнар, аннан бирегә күченгәннәр).

### *Яңгыр боткасы*

*Бик кызу булып яңгыр булмаганда, авыл башында ботка пешерделәр. Тегермән белән тарталар иде бодайны. Шуннан пешерәләр иде. Догаларын мулла бабайлар укый иде.*

(Казанка авылы, Зәләлетдинова Саимә Кыям кызы, 1936 елгы.)

Хәзерге вакытта фольклорның иң актив жанрларының берсе булып мифологик хикәятләрне атарга була. Акбалык белән Казанка авылларында да Су анасы, ияләр, җеннәр турында шактый материал тупланды.

### *Су анасы*

*Инәм әйтә, карасам, ди, су инәсе елап утыра, чәче озын, ди. Тарап утыра чәчен, ди. Елый үзе, ди. Аннан кеше ала инде. Аннары кеше бата, ди. Или Казанкада баталар иде, или Умарда, или Батуринода. Менә шулай.*

### *Йеннәр*

*Йеннәр дә күп иде. Каршыбызга чыкты. Котыбызны алган иде. Казанкада кибетләрдә дефицит иде, онга киттек. Кайтып килсәк, артыбыздан ут килә, фара кебек. Атыбыз да бармый, куабыз куабыз – бармый. Атыбыз туктап да куйды, бармый. Этебез бар иде, өч көн кайтмады куркып. Ут машина килгән кебек, фара килгән кебек, тәгәрәп килә, калышмый, артыбыздан калмый. Эт курыккандыр инде. Ут тәгәрәп килә, авылга җиткәч калды. Күп күрдек андыйны.*

### *Өй иясе*

*Өй иясе диләр, чакырасың яңа өйгә күчкәндә. Әйдә минем белән, дип чакырасың. Әйдә, безнең белән бергә яшик. Менә шулай итеп чакырсаң, бергә күчә аннан. Чакырмасаң, покой бирми инде ул. Шылтырый, савытларны шылтыр-шылтыр вата. Әпәй, тоз куясың өйгә, диләр. Кайсы кеше эт ата икән, песи ата икән яңа өйгә. Ул юк сүз. Наоборот, песиләр, этләр кебек талашалар аннары.*

(Акбалык авылы, Ризванова Нәсыйхә Әбүбәкер кызы, 1934 елгы. Хасанова Мәйсәрвәр Әбүбәкер кызы, 1946 елгы).

***Су анасы***

*Су анасын күргәнебез юк. Сөйлиләр иде. Чәчегезне юешләтмәгез. Су буенда чәч тарасагыз, Су анасы тарагыгызны алып китәр дип сөйлиләр иде.*

***Мал иясе***

*Мал хуҗасы, мал иясе күренеп китә диләр иде. Нәрсә булгандыр инде ул. Тамак кырып кермәсәң, үзеңә дә күренеп китә. Йорт иясе дә бар. Мунчада шайтан бар, диләр. Эш вакытында кич белән дә, төнлә дә керәбез инде.*

(Казанка авылы, Зәләлетдинова Саимә Кыям кызы. 1936 елгы.)

Им-томнарны икенче төрле «дәва ырымнары» дип атыйлар. Алар төрле авыруларны сүзнең магик көче һәм шул текст белән ярашкан эш-гамәл ярдәмендә дәвалауга корылган. Халык күз тиюне хәзер дә имләп дәвалый. Татарлар яшәгән төрле регионнарда күз тиюдән дәвалауның күп төрле ырымнары бар. Хәзергә кадәр күзгә чыккан арпаны, бүсерне, баш авыртуларын, куркуны ырымнар белән дәвалыйлар. Күп авылларда баш кагучы, бүсер сылаучы имчеләр бар.

Курыкканга кургаш кою – элегрәк популяр булган ырымнарның берсе. Кеше каты курыкканнан соң, аның баш өстендә эреткән кургаш койганнар. Имчеләр салкын суга төшкән кургаш ясаган сурәтне карап, кешенең нәрсәдән курыкканын, нинди им итәргә кирәген әйткәннәр.

***Им-томнар турында***

*Кургаш коялар. Кеше курыкса, кургаш белән коялар иде. Башларын ябындырып имлиләр.*

*Имләгәч, минем кулым түгел, Гайшә-Фатималар кулы дисең.*

*Баланың аркадагы җонын сөтең белән, имчәк сөтең белән уып утырасың. Уып утыралар. Мунчада уалар.*

(Акбалык авылы, Ризванова Нәсыйхә Әбүбәкер кызы, 1934 елгы; Хасанова Мәйсәрвәр Әбүбәкер кызы, 1946 елгы.)

Акбалыкта язып алган им-том текстларының берсе – очан имләү. *Очан* сүзен хәзерге кеше аңламый да. Ул – балаларда була

торган эч авырту, баланың эче күбү, метеоризмны аңлата. Очан булганны баланың аягын тартып-тартып елаганнан белгәннәр. Очан имләргә махсус имчеләргә бармаганнар, гадәттә, баланың әбисе яки әнисе имләгән.

### *Очан имләү*

*Очан имләгәндә, анда уклау гына түгел, кайчы да, носки да кирәк. Оекбашны икенче якка әйләндерәсең. Миңа әби өйрәтеп калдырган иде. Баланы йаткызалар. Башта сорыйлар, кемне имлисең, дип. Фәләнгә очан булган, очан имлим, дисең. Исеме белән имлисең. Очан булса, эчләре кабарып китә, күз тигән була балага. Имләгәч, сразу туктый бала.*

*Уклауны тотып, сәгать теле уңаена баланың эченә төртеп саныйлар.*

*Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, тугызда тузып кит. Аннан соң җидене шулай ясыйсың, бишне. Аннан уклауны әбием ыргытып бәрә иде дә бу сүзләрне әйтә иде:*

*Минем яшем кайткан,*<br>
*Ай да кайта, көн дә кайта,*<br>
*Син дә кайт.*<br>
*Мин имләмәдем, Гайшә-Фатыйма разыйаллаһу имләде.*<br>
*Имләгәнем шул булсын!*

*Шулай дип төкереп-төкереп, өшкереп-нитеп ала иде әби. Аннан ала иде кайчы. аннан кайчы белән шулай ук эшли. Шуннан носки белән. И барсын шулай атып бәрә. Носкины бармакка киеп ала да шулай баланың эченә төртеп имли. Текст тулысы белән болай була:*

*Нәрсә имлисең?*

*Фәлән кызы фәләнгә очан булган, очан имлим.*

*Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, тугызда тузып кит.*

*Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, җидедә җилгә оч.*<br>
*Бер, ике, өч, дүрт, биш, биштә бизеп кит.*<br>
*Бер, ике, өч, өчтә очып кит.*<br>
*Бер бердән кайт.*<br>
*Минем яшем кайткан,*

*Ай да кайта, көн дә кайта,*
*Син дә кайт.*
*Мин имләмәдем, Гайшә-Фатыйма разыйаллаһу имләде.*
*Имләгәнем шул булсын! Тьфү-тьфү-тьфү!*

***Күз тигәнне имләү***

*Кемне имлисең?*
*Фәлән кызы фәләнне имлимен. (Исеме белән әйтәсең.)*
*Алтмыш алты ала күз,*
*Кырык җиде кара күз,*
*Утыз җиде зәңгәр күз,*
*Бер ир, бер хатын, бер бала (өч тапкыр кабатлана),*
*Хруще фара.*
*мин имләмәдем, Гайшә-Фатималар имләде.*
*Тьфү тьфү тьфү.*

(Акбалык авылы, Гаврилова Әлфия Сәгыйть кызы, 1975 елгы. Шәфкать туташы.)

2017 елгы экспедиция эшләгән икенче район, Каргат районы. Хәзерге вакытта татарлар Каргат районының Муса, Форпост, Җәйләү һәм Кышлау (русча атамасы – Шибаки) авылларында яши. Дөресрәге, ике генә авыл калып бара, Муса һәм Җәйләү авылларында халык матур гына яшәп ятса, Форпост белән Кышлауда берничә генә йорт, санаулы кеше калып бара.

В.В. Радлов материал туплаган Тәрәнә авылы хәзерге вакытта «Җәйләү» дип атала. «Тәрәнә» исеме авылның рус телендәге «Теренино» атамасында гына сакланып калган. Тәрәнә – бараба татарлары авылы. Дөрес, Казан татарлары бирегә дә шактый килгән. Халык бик тиз үзара аралашып китеп, дус яшәгән.

В.В. Радлов Тәрәнә авылында сигез исемдәге күләмле текстлар язып алган. Хәзерге вакытта, әлбәттә, андый күләмле текстлар, бигрәк тә әкиятләр, дастаннар сакланмый. Шулай да халык белгәне белән теләп уртаклаша. Шунысын да искәртү урынлы: алар бу материалларның китапка кертеләсен, киләчәк буыннарга каласын белеп, теләп ярдәм итәләр.

Тәрәнә авылы халкы – ачык йөзле, бик кунакчыл халык. Алар халыкның йолаларын, бәйрәмнәрне дә искә төшерделәр, авыл тарихы белән бәйле истәлекләрне, хәтерләрендә төрле вакыйгаларны, яшь чакларын барладылар.

Хәзерге вакытта авыл халкы барабалыларның бетеп баруын әйтә. Казан татарлары белән кушылу нәтиҗәсендә, барабалылар ассимиляцияләшкән. Авылның татарча исеме Тәрәнә булуын авыл халкы хәтерләми. Бүгенге көндә ул Җәйләү буларак кына йөри.

Тәрәнә авылы информантларыбыз Кунгулова Заһирә (Зайра) Закир кызы (1940 елгы, Җәйләүдә туган, Кышлауга кияүгә чыккан) белән Сәйфуллина Земфира Әделхан кызы (1940 елгы) авыл тарихы, йолалар, гореф-гадәтләр буенча кызыклы мәгълүматлар бирделәр, җырлап күрсәттеләр, кунак каршылау традицияләре белән таныштырдылар.

*Монда Җәйләү кушканнар, тегендә Кышлау кушканнар. Җәйләүдә җәйлиләр, Кышлауда кышлыйлар. Җәйләүләрдән Кышлауларга җәяү килә Җәмилә дип йөри идек. Җыры бар, җыр ул хәтердә калмаган. Әниләр җырлар иде шулай.*

*Белмим инде, Теренино дип нәрсәгә аталды икән ул? Русча Җәйләү димәгәннәр инде алар, Теренино дип әйткәннәр инде. Магазин бар инде. Мәчет хәзер юк. Авылда бер урам гына бар. Исеме юк инде.*

*Авыл башында мәчет булган. Чамал (Җамал), Хәннән бабайлар мулла булганнар. Авылда Корбан гаетен зурлап бәйрәм иткәннәр. Корбанга ит суйганнар. Кышлаудан бер бот ит китергәннәр муллага.*

*Хәзер дә Корбан аенда корбан суябыз, Рамазан аенда авыз ачтырабыз.*

*Бездә монда Каргат елгасы бар. Каргат речкасы дип әйтәбез. Кышлауда Каргат күле бар.*

*Бездә монда барабалар юк инде хәзер,алар калмады.Бараба бездә юк инде. Шибакида да беттеләр инде алар. Бабайлар бар иде, «бараба» диялләр иде. Хәзер аларның балалары, оныклары бар инде.*

*Барабалар балык тотканнар, охотага йөргәннәр. Иван-чәй, төче тамырны чәй итеп эчкәннәр.*

*Элек ашлык та чәчмәгәннәр, бәрәңге дә утыртмаганнар. Карлыган күп булган, как койганнар, балык киптергәннәр, тысяча лет тому назад булган.*

Бараба сөйләме хәзерге вакытта онытыла барса да, халык фольклордан аерым өзекләрне искә төшерә, бараба сөйләме белән бәйле мәзәкләрне хәтерли. Мәсәлән, бараба сөйләшендә «самаварны утырт», ягъни самавар куй дигән «утыз самаварны» булып яңгырый икән. *Казан яктан килгән киленгә, кунакларга чәй куярга кушып, «Утыз самаварны!» – диләр икән. «Нинди утыз самавар? Самаварыгыз бер генә бит!» – ди икән килен. Икенче киленгә, ишекне бикләргә кушып, «Ишекне сула!» – диләр икән. «Сулау» бараба сөйләшендә бикләүне аңлаткан. Бу килен дә аптырап калмаган, бер чиләк суны алып килеп ишеккә сипкән, ди.*

Җәйләү-Тәрәнә апалары барабалыларның борынгы бишек җырын да җырлап күрсәттеләр:

*Әлли-бәлли әлкәчәк,*
*Әлли-бәлли кошкачак,*
*Карт инәсен яшь итеп*
*Кияүгә биргән кошкачак.*

Бу җырны информантыбыз Кунгулова Заһирә апа җырлап бирде. Бараба сөйләшендәге әлкәчәк – бәби, кошкачак – чыпчык дигән сүз.

Бишек җырының икенче вариантын да җырлыйлар биредә:

*Әлли итәр бу бала,*
*Бәлли итәр бу бала.*
*Әткәсенә-әнкәсенә*
*Хезмәт итәр бу бала.*

Апаларыбыз шактый гына бараба сүзләрен искә төшерделәр: *чүмеч – чаңкау, кашык – шәбәлә, инү – керү, йөлтек – ялкау, кәбец – аяк киеме, кәрсәү – акыллы* һ.б.

«Каргат» атамасының килеп чыгуын информантлар *каргыш* сүзе белән бәйләп аңлаталар. Бу топонимик характердагы риваятьнең берничә варианты бар.

*Бер бай гаилә су буена туктаганар. Күлдән карась тоталар, шул балыкны пешерәләр. Балыкны ашаганда, балага кылчык кадала. Атасы шуннан соң бу күлне каргаган.*

*Тик торганда, тигез җирдә шушы күл буенда башта баласы үлгән. Аннары атасы үлгән. Атасы үлгәндә каргаган. «Каргат» – от слова каргаган.*

Информантлар Җәйләүнең йола-бәйрәмнәреннән Яңгыр боткасы, Садака бәйрәмен, Сабан туйларын искә төшерделәр. Алар хәзерге вакытта хәтердә генә яшиләр. Дөрес, халык дини бәйрәмнәрне хәзер дә зурлап бәйрәм итә.

### ***Ияләр***

*Сүлиләр иде Су анасы бар дип. Ну миңа күренмәде». Чәчегезне юешләтмәгез. Тарагыгызны алып китә дип сүлиләр иде.*

*Су коена торган җирдә су тегермәне бар иде. Су кырыенда иде ул. Әйтәләр иде мал хуҗасы, иясе күренеп китә, дип. Тамак кырып керергә кирәк мал кырына дип сүлиләр иде. Мал иясе бар. Тоже тамак кырып йөрергә кирәк. Әпәй белән тоз мал хуҗасына куялар дип әйтәләр иде.*

*Йорт иясе дә бар. Болай ул күренми. Элек әйтәләр иде мунчада шайтан бар дип. Хәзер белмим.*

### ***Сәдәка бәйрәме***

*Сәдәка бәйрәмендә өйдә һәркем үзе пешерә дә инде, чәй эчә торганнар иде. Баурсаклар, ашлар шулай пешерәләр иде. Йомырка буйый идек. Нәүрүзгә шул баурсак инде. Кыстыбый пешерә идек. Кош телләре пешерәбез.*

### ***Яңгыр боткасы***

*Ботка җыелышып пешерәләр. Бер елны яңгыр булмады озак. Ботка пешерделәр авыл башына җыелып.*

*Элек бодайны киптерәләр иде дә кул тегермәне белән тарталар иде. Шуннан ярма була иде. Догалары бар иде. Мулла бабайлар укыйлар иде. Су сибешеп уйныйлар иде. Әле дә бар ул, әле дә уйныйлар.*

**Сабан туе**

*Сабан туен былтыр гына үткәрмәдек әле. Элек көрәштә җиңгән кешегә тәкә бирәләр. Өскә, колга башына, ел саен нәрсәдер куялар инде. Аны менеп алалар.*

Җәйләү авылы информантлары белән аралашканда, алар, үзләре дә гаҗәпләнә-гаҗәпләнә, яшь вакытларында ишеткән җырларын искә төшерделәр, биредә дә бәет әйткәннәр, кич утырып әкиятләр, дастаннар сөйләгәннәр. Әкиятләрне, дастаннарны сөйли алучы табылмаса да, татар халкының иң киң таралган «Сак-Сок» бәетен дә апалар яхшы гына хәтерлиләр. Бер-берсенең исенә төшерә-төшерә, бәетнең шактый гына юллары яңартылды:

*Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,*
*Сак белән Сукның таушын ишетәсе.*
*Мәдрәсәләрдә пыяла ишек,*
*Сак белән Сукның тавышын ишет.*

Бәет, нигездә, безгә мәгълүм вариантлар белән тәңгәл килә. Информантлар, «Сак белән Сок» димиләр, «Сак белән Сук» дип сөйлиләр. «Сук» варианты борынгырак булып, Идел буенда да аның Сокка әйләнүе соңгы гасырларга гына карамый микән.

Каргат районында да туган телдә укыла торган догаларны, дини эчтәлекле текстларны яхшы беләләр. Аларны әби-бабалар оныкларына өйрәтә. Алар кайсын кайчан әйтергә кирәклеген аңлата, Аллаһы Тәгаләгә туган телендә мөрәҗәгать итәргә мөмкин булу балага кече яшьтән сеңдерелә.

*Яттым, я Аллаһ,*
*Торырмын – Иншаллаһ,*
*Бу ятудан тора алмасам,*
*Иман бирсен бер Аллаһ.*
*Иман белән үтәем,*
*Ислам белән китәем.*
*Хәтәр-хәтәр кичләрдә*
*Суңым уңга әйләнсен,*
*Телемә иман бәйләнсен.*
*«Аллаһ, Аллаһ» дигәндә,*

*Караңгы гүрем яктырсын,*
*«Сөбханаллаһ» дигәндә,*
*Оҗмах ишеге ачылсын.*
*Ай күрдем аман белән,*
*Авызым тулсын иман белән.*
*Шушы айларда вафат булсам*
*Үткәр, Ходам, иман белән.*
*Хәерле эшкә хәрәкәт бир,*
*Ашыбызга бәрәкәт бир.*
*Җаныбызга тынычлык бир,*
*Малыбызга өлеш бир.*
*Бездән борын үткәннәр,*
*Бездән өмет иткәннәр,*
*Өч Әлхәм, өч Колхуалла*
*Савабын бирсен бер Аллаһ.*
*Яттым тыныч,*
*Ястыгым – кирпеч,*
*Динем – ислам,*
*Теләгәнем – иман.*
*Хөрәеш атлы еланга миннән сәлам.*

Җәйләү авылында татар мифологиясенең әлегә кадәр аз өйрәнелгән, дөресрәге, бик азларга гына мәгълүм булган персонажы белән таныштык. Бу Хөрәеш елан – дини мифология буенча оҗмах ишеге төбендә торучы елан. Халык ышанулары буенча, *«Хөрәеш еланга сәлам әйтеп торсаң, ул миңа гел сәлам әйтте, дип, сәлам әйткән кешегә каты бәрелми, шәфкатьле була икән».*

Җәйләүдә шактый гына тыюлар, ышанулар да язып алдык. Әлеге текстлар, нигездә, татар халкында киң таралган. Кайберләре белән сезне дә таныштырып китәбез.

### ***Тырнакларны җыеп йөрү***

*Тырнакны, кыямәт көнендә җавап бирәсе дип, күбрәк пичкә ягабыз. Яки кушалар тәрәз төбенә күмәргә дип. Имештер, кыямәт көнне ул тырнаклар, чәчәк булып үсеп чыгып, безне каплап торырлар дип сөйлиләр иде. Ну хәзер күбрәк пичкә йагыла.*

**Чәчне җыеп йөрү**

*Менә бит хәзер кашны йолкалар. Аларның берсен дә ярамый йолкырга дияләр иде. Керфекне даже безнең әни, алып, башыма салып куя иде. Ярамый аларны ташларга. Хәзер әнә кашларын йолкалар.*

*Чәчне кош алып китсә, баш авырта, диләр. Любой кош алып китә менә. Соң алар бит оя ясый алып китеп. Карап торсаң менә, алар чүпли шуны. Шуңа ярамый дияләр.*

**Гүр садакасына тавык бирү**

*Гүр садакасына тавык бирәләр. Тавыкны бирәләр ни өчен? Менә без тырнаклар кисәбез бит, кайчан как папало да киселә, сибелә ул. Вот шул тавык шул тырнакларны җыйсын өчен бирәләр икән. Дөрес микән?*

**Күк күкрәгәндә аунау**

*Беренче тапкыр күк күкрәгәндә, бил авыртмасын өчен ауныйбыз. Язын беренче тапкыр күк күкрәгәнне ишеткәндә «Бисмиллараханирахим» диям дә ятам да ауныйм. Барыбер авырта инде ул авырткан.*

*Мин боз яуса кучарка, соскы һәм себерке чыгарып ыргытамын. Тизрәк туктасын дип. Туктый. Беркөнне мисләрне дә чыгарып аткан идем.*

*Күлмәкнең эчке йагын тышка кисәң, куанычка булсын, диябез. Аяк- кулларың сызлаусыз булсын. Йөргән җиреңдә Хозыр ильяс юлдаш булып йөрсен, диябез. Исәнлек-саулык телибез.*

**Бала коендыру, имләү**

*Яшь баланы коендырганда, «Бисмил-ләәһир-рахмәәнир-рахиим» дип укыйбыз да инде. Бәхетле, тәүфыйкле, акыллы бала бул, дип әйтеп, теләк теләп коендырабыз.*

*Күз тисә, бала елый ул, күз төбе күгәреп китә. Өшкерәбез инде үзебезчә шунда. Су аласың да «Бисмил-ләәһир-рахмәәнир-рахиим» дип, тәрәзләрне сөртәсең, өстәл өсләрен, аннары шул су белән битләрен сөртәсең, әз генә авызына сөртеп куясың. Аннан әйләндереп-әйләндереп түгәсең.*

*Утын күмере булса, утын күмере саласың суга. Биш кашык, пычак куясың. Күз тисә, күмер төшеп китә аска. Күз тимәсә, өстә йөри ул.*

*Очан булса, Хәмдия әби табаны белән, үкчә белән, аягы белән имли иде. Басасың шулай. Басып чыгасың, өч яки җиде.*

*Бала курыкса, йөрәген召 кактыра идек әбиләрдән. «Утыр, йөрәк, урыныңа утыр, йөрәк, курыкма» дип укыштырасың инде бисмилла әйтеп. Менә балага әйбәт булып китә шикелле.*

### *Эч сылау*

*Эч төшкәндә, болай имлим. Бармагымны куям да кендегенә карыйм. Кендекнең тамыры сукмаса, эч төшкән була. Аннан инде аны күтәртәм дә шулай аягын сылыймын да, бәйләп куям. Бер сәгать ята да йөгереп тә китә.*

Җәйләү авылында яшәүче һәм авылга ялга кайткан Шкидина Эльвира Сагидовна (1971 елгы, Җәйләү авылы клубы мөдире), Сәйфуллина Лилия Гомәровна (1965 елгы, укытучы), Ибраһимова Ләлә Солтановна (1969 елгы), Рамазанова Найлә Барыевна (1960 елгы) да авыл белән бәйле истәлекләрне хәтерләрендә яңартты. Информант апаларыбыз җырларына алар да кушылды.

*Гармун уйный, гармун уйный,*
*Гармун уйный бер малай.*
*Биючегә, җырлаучыга*
*Без кызыкмыйбыз алай.*
*Дустым, дустым бушамый,*
*Чәчен тарый бушамый.*
*Кая барсам, дуслар табам,*
*Сез дусларга охшамый.*
*Уфа юллары пыяла,*
*Таш булса таймас иде.*
*Минем йөрәккәем яна,*
*Син булсаң янмас иде.*
*Уфа дисең дә карыйсың,*
*Уфа күренә мәллә?*
*Аерым яшәүне телисең,*
*Күңел сүрелә мәллә?*

Агыйделгә төшә яздым,
Тотмадың беләгемнән.
Тамыр җәйгән гөлләр кебек
Китмисең йөрәгемнән.

Агыйделгә төшәр идем,
Дулкынлап йөзәр идем.
Алда бәхетләрем булса,
Хәзергә түзәр идем.

Алмалары-хөрмәләре
Кызарып пешәр әле,
Әле исеңә төшмәсә,
Соңрак төшәр әле.

Ак яулыгымның очына
Алма тимәгән иде.
Нәфел уразасы тотып,
Бәхет теләгән идем.

Агыйделнең аръягында
Калмасам ярар иде.
Я бәхетсез, я гомерсез
Булмасам ярар иде.

Сабын салдык, нигә кирәк,
Сабын салырга кирәк.
Сагынсаң да, саргайсаң да
Сабыр итәргә кирәк.

Уфаларга барам әле,
Уфа юлы ачылса.
«Уф йөрәгем» димәм әле,
Янулары басылса.

Уфа кайда, Уфа кайда?
Уфа су буйларында.
Утлар яна, сулар кайный
Яшь кенә йөрәгемдә.

Чәй эчсәк тә, җырлап эчик,
Бал эчәләр дисеннәр.
Бер оя каз бәбкәсе кебек
Бертуганнар дисеннәр.

Каргат районының Муса авылы – чагыштырмача яңа авыл. 1921 елда татарлар Идел буендагы ачлыктан качып, авыр тормыштан качып, Оренбург өлкәсенең Габдрахман авылыннан килгәннәр. Килүче халык башта Җәйләүдә, аннары Сарыкамыш авылында торганнар. Соңрак Муса авылына күченгәннәр. Муса авылында татарлар руслар белән аралашып яши.

Информантларыбыз Сөләйманов Зөфәр Нури улы (1931 елгы) белән Сөләйманова Рәхимә Хәким кызы (1937 елгы) икесе дә Мусада туып үскән. Рәхимә апаның әнисе Оренбург ягыннан килгән. Яңа туган булган монда килгәндә. Атасы үлгән булган, әнисе белән килгәннәр. Рәхимә апа белән Зөфәр абый авыл тарихына бәйле истәлекләрне яңарттылар, Сабан туйларын, авылның кунак йолаларын искә төшерделәр. Биредә дә халык ауга йөргән, балык тоткан, җиләк-җимеш җыйган, мал асраган. Төрле йолаларны үтәп яшәгәннәр. Яңгыр яумаса, яңгыр сорап дога кылганнар. Каргат авылына Рамазан уразасы көнне туры килдек. Биредә дә гает укылып беткән вакытка гает коймагы пешереп торалар. Бәйрәм өстәленә тәмле ризыклар әзерләнә. Соңгы вакытта халык дини бәйрәмнәрне генә билгеләп үтә башлаган. Кызганычка каршы, халыкның милли бәйрәмнәре – Сабан туйлары, Әмәл, Садака бәйрәмнәре онытыла бара. Яшьләрнең күбесе алар турында белми. Бәйрәмнәр, йолалар, шушы чараларда халыкның берләшүе, тел белән беррәттән, халыкны саклап калучы күренешләр булуы да онытылып бара.

Йомгак ясап әйткәндә, Новосибирск өлкәсендә узган экспедиция вакытында матур гына табышларга ия булдык. Риваять-легендалар, мифологик хикәятләр, им-том текстлары язып алдык. Йолалар, бәйрәмнәр турында материал тупладык. Теләгебез бер генә: халык туган телен, мәдəниятен киләчәк буыннарга да саклап калсын иде.

# ӘЙТҮКӘ БЕЛӘН БАТЫШ ТУРЫНДА КЫЙССА

*Илсөяр Закирова*

Татар халкында бәхетсез мәхәббәтне бәян иткән дастан-кыйссалар, легендалар, тарихи җырлар гаять популяр. Аларның дистәләгән вариантлары булып, бәхетсез гашыйклар тарихын белмәгән кеше юктыр. Таһир белән Зөһрә, Ләйлә белән Мәҗнүн, Кузы Көрпәч белән Баян-Сылу мәхәббәтләре турындагы дастаннарны халык яттан белгән. Сезгә тәкъдим ителә торган Әйтүкә җырлары да – мәхәббәт җырлары. Бу җыр – эчтәлеге белән романтик дастанга якын әсәр. Дөресрәге, реаль вакыйгаларга нигезләнгән Әйтүкә җырлары җыр жанры белән дастан арасында тора.

Хәзергә кадәр Себергә оештырылган комплекслы экспедицияләр вакытында «Әйтүкә җыры» турында еш ишетергә туры килә. Информантлар бу җырның Әйтүкә исемле егет белән Батыш исемле кызның бәхетсез мәхәббәтен бәян иткән җыр булуын хәтерләсәләр дә, соңгы елларда ул онытыла бара, информантлар аерым строфаларын гына искә төшерәләр. Җыр Новосибирск өлкәсендә яшәгән татарларда киң тарталган булган. Җырда тасвирланган вакыйгалар, җыр чыгуга сәбәп булган мәхәббәт тарихы күпсанлы, еш кына бер-берсенә каршы килгән риваятьләрдә, истәлекләрдә дә саклана.

Бу мәкаләдә, җырларның барлык юлларын, төрле елларда һәм төрле галимнәр тарафыннан язып алынган вариантларны да кертеп, эзлекле бер текст буларак туплап, мөмкин булганда

риваятьләр ярдәмендә тулыландыра барып, Әйтүкә мәхәббәте белән сезне дә таныштырырга телибез.

Әйтүкә җыры Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре тарафыннан Себер татарларының фольклорын өйрәнү максаты белән оештырылган экспедицияләр вакытында күп тапкырлар язып алына. Җырны иң беренче язып алучы кеше Хафиз Рәхмәтуллин була. Ул 1894 елда Омск өлкәсенең Усть-Ишим районы Тау авылында туган. Хафиз Рәхмәтуллин 1928 елдан 1936 елга кадәр Новосибирск өлкәсендә төрле вазифалар башкара. 1932–1936 елларда «Азат Себер» газетасында редактор урынбасары һәм баш редактор булып эшли. Ул киң эрудицияле, күпкырлы талантлы шәхес булып, Себер татарларының рухи байлыгын туплау һәм киләчәк өчен саклап калу максатында зур хезмәт куя. Себер татарларының күпсанлы җырлары әлеге шәхес язмага теркәү сәбәпле сакланып калган. Хафиз Рәхмәтуллин Новосибирск өлкәсендә эшләгән дәверендә Әйтүкә җырын да язып ала.

В.В. Радлов эзләре буенча оештырылган 1940 елгы экспедиция вакытында бу җырларны һәм Әйтүкә тарихын Хәмит Ярми һәм Мөхәммәт Садри (В. Хаҗиев) язып алалар. Мөхәммәт Садри бу елларда туплаган «Әйтүкә» җыры турындагы риваятьләрне 1964 елда «Совет әдәбияты» журналында искә ала (1964, №8, 135–136 битләр), җыр текстын «Казан утлары» журналында бастырып чыгара (1978, №9, 118–120 битләр), бу җыр әдипнең «Иртешкә сәяхәт» исемле җыентыгында да урын ала (Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 115–119 битләр).

1967 елда Хәмит Ярми җитәкчелегендәге экспедиция яңадан Новосибирск өлкәсендә эшли. Әйтүкә җырын, Әйтүкә белән Батышның мәхәббәт тарихын, тормышларын яктырткан риваятьләрне Х. Ярми, Һ. Мәхмүтов, Ф. Урманчеев, Ф. Әхмәтова, Х. Гатина, В. Хаҗиев язып алалар. Ике тапкыр оештырылган экспедиция нәтиҗәсендә Әйтүкә белән Батыш турында кызыклы риваятьләр, шактый гына җыр текстлары туплана.

Әйтүкә җыры диалектологлар игътибарыннан да читтә калмаган. Диалектолог Л.В. Дмитриева 1967–1968 елларда Ново-

сибирск өлкәсенең Чаны районы Тармакүл авылында җырның унҗиде строфасын язып алып, аларны үзенең «Язык барабинских татар» исемле китабында бастыра (Л.:Наука, 1981, С. 73–77). Әйтүкә җырын һәм риваятьләрен Новосибирск өлкәсендә узган экспедицияләр вакытында диалектолог Ф. Йосыпов туплый. «Барабинские татары. Страницы духовной культуры» дигән коллектив монографиядә галим үзе язып алган вариантлар белән диалектологлар Л.В. Дмитриева,Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова һәм әдип М.Садри бастырган текстларны да биреп, бу җырның билгеле вариантларын бергә берләштерә (Казань: Казанский университет, 2013, С. 253–274).

Диалектологлар Ф.С. Баязитова белән Д.Б. Рамазанова Әйтүкә җырының сүзләрен Себер татарларының этнокультура лексикасына багышланган җыентыкларында бастырганнар (Баязитова Ф.С. Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы. Казан, 2009, 546–547 б.; Рамазанова Д.Б. Себер диалектларыннан материаллар. Казан: Фикер, 1998. 98–100 б.).

Риваятьләр һәм истәлекләр буенча, Әйтүкә белән Батыш – Себердә Үнәр авылында (хәзерге Новосибирск өлкәсенең Чаны районында Тармакүл авылы) туып үскән кешеләр. Әйтүкәнең тулы исеме – Әйтмөхәммәт, Батыш – Фатыймадан кыскартылган. Озын исемнәрне кыскарту күренеше элегрәк татарларда киң таралган була. Геройларның биографиясе берничә варианттагы риваятьләрдә бәян ителә.

Беренче риваять буенча, *Батыш Үнәр авылының Балыйк (Халыйк, Халик) исемле байның кызы була. Әйтүкә бик ярлы гаиләдән. Атасы аны ун яшендә Балыйк байга сата. Үсеп җиткәч, ул шул байның хезмәтчесе булырга тиеш була. Әйтүкә Батыш белән бергә уйнап үсә.*

*Әйтүкә йөзгә чибәр, күркәм холыклы егет булып үсеп җитә. Шул ук вакытта егетнең тавышы шулкадәр матур, аны ишетеп-күреп бер кеше дә битараф кала алмый. Әйтүкә үзе җырлар да чыгара, дөресрәге, егет чичән-җырау сәләтенә ия була, һәр вакыйганы җыр белән шәрехләп бара. Батыш белән Әйтүкә бер-берсен ярата башлыйлар. Бай Әйтүкәне кызына тиң күрми,*

*бу мәхәббәткә чик куярга теләп, Батышны бер байга кияүгә бирә. Тәбсәү (туй) көнне Әйтүкә белән Батыш ат менеп качып китәләр. Алар урманда качып яшиләр. Бер-ике елдан, сагынуларына түзә алмыйча, кире әйләнеп кайталар.*

*Ләкин бай Әйтүкәне кияве итеп танырга теләми. Байлар, муллалар, җыелып, Әйтүкәне шәригать буенча хөкем итәләр. Кыйнап кулын сындыралар. Шул вакыйгаларның шаһите булган халык, Әйтүкәне яклап, байлар кулыннан тартып ала. Шуннан соң Әйтүкә белән Батыш җыр белән үзләренең мәхәббәтләрен сөйлиләр.*

Икенче риваять буенча, *Батыш ярлы кызы була. Аны Үңәр бае көчләп үзенә кияүгә ала. Соңыннан Әйтүкә Батышны байдан тартып алып кача.*

Бу риваятьләрне 1940 елда Хәмит Ярми Новосибирск өлкәсе Чаны районы Аялу авылында Нур Ибраһимовтан язып алган.

1967 елда Ф.И. Урманчеев Чаны районы Тармакүл авылында Гази Шәмсутдиновтан язып алган риваятьләр алдагы риваятьтә бирелгән мәгълүматларны тулыландыра.

*Әйтүкә Тармакүлдә туып үскән. Уналты яшендә үзе яраткан Фатыйманы алып, авылдан качкан. Өч ел буена бу авылдан 100 чакрым җирдә, Казах илендә яшәгән. Аның яшәгән җирен күргән кешеләр дә бар, ди. Фатыйма бу яктагы иң матур кыз булган. Үзе биюче дә булган. Маңгаена....(сүз танылмый. – И.З.) белән су куеп биегән. Әйтүкә бәхер (ярлы) булганга күрә, Фатыйманың әтисе аны Әйтүкәгә бирәсе килмәгән. Шуннан соң Әйтүкә, өйләнмәгән булса да, Фатыйманы алып качкан.*

*Фатыйманың биш агасы булган. Фатыйманы Балык дигән бай кешегә биреп, кодалатып куйган булганнар. Әйтүкә белән Фатыйма әүвәл сөйләшеп, аннан качып киткәннәр. Кайбер кешеләрнең Әйтүкәне күргәннәре дә булган. Әйтүкәне тотып алып килгәннәр. Аннан соң Әйтүкә үзенең җырларын җырлаган. Җырларны русчага тәрҗемә иткәннәр. Шуннан соң пристав Әйтүкәне җибәргән. Фатыйманың атасы кызына аңа кияүгә чыгарга рөхсәт итмәгән. Шулай итеп, Әйтүкә белән Фатыйма, бер-берсен яратсалар да, кушылып бергә яши алмаганнар. Фа-*

*тыйма ялгызлыкта гомер уздыра, Әйтүкә соңра өйләнгән булса кирәк. Ләкин анысын тәгаен белүче юк. Бу вакыйгалар моннан бер йөз ел элек булган.*

Ф. Әхмәтова 1961 елда Новосибирск өлкәсе Барабинск районы Бакчакүл авылында 1891 елгы Ажбаков Мөслим бабайдан, 1967 елда Новосибирск өлкәсендә Куйбышев районы Шагыр авылында 1897 елда туган Баязитова Оркыя әбидән, 1878 елгы Сәлимҗанов Хәмидулла бабайдан Әйтүкә җырының аерым строфаларын да, геройлар турында сөйләк-риваятьләр дә язып ала. Бу язмаларда кайбер геройларның исеме башка булса да, Әйтүкә белән Батыш турында алдагы язмалардан аерма күп түгел.

*Тармакүл авылында (Үңәр элеккечә) Ибраһим хәзрәт була. Аның Әйтүкә исемле батрагы була. Әйтүкә хәзрәтнең Батыш исемле кызын ярата. Калым түләр хәле юк, хәзрәт бирми дә аңа кызын. Яшьләр, бер-берсен яратышып, казакъ далаларына качып китәләр. Шулай шактый йөргәннән соң, туган якларына кайтырга булалар. Кайбер легендалар буенча, тотып алып кайталар. Үңәрдә халыкны җыеп, Әйтүкәне камчы белән суктырмакчы булалар. Хөкем алдыннан Әйтүкә үзе чыгарган җырларны җырлап күрсәтергә тәкъдим итә. Батышның матурлыгын, аңа булган мәхәббәтен җыр аша әйтеп бирә. Бу җырларны тыңлаган авыл картлары, мондый саф көчле мәхәббәт өчен җәза бирү гөнаһ булыр дип, хәзрәттән яшьләрне кичерүне үтенәләр.*

*Әйтүкәне төрмәгә утыртканнар. Аның төрмәдә җырлаган җырлары да бар, диләр.*

*Әйтүкә Батышны ташлап, башка хатын янына, үзенең кызы белән калган элекке хатыны янына кайткан дип тә сөйлиләр.*

Әйтүкә җыры халыкта бик популяр булып, аны туйларда кара-каршы җырлаганнар. Җырның көйләре бик күп булган, ул борынгы бик озын көйгә дә, кыска көйләргә дә башкарылган. Бараба районы Тандау авылында яшәгән информант Сәбидә әби Бигушевадан Ф. Урманчеев язып алган мәгълүмат буенча, аның яшьлегендә туйда ике кеше «Әйтүкә» җырын башкарганнар. Аларның берсе Әйтүкә булып, икенчесе Батыш булып җырлаган.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан төрле елларда язып алынган мәгълүмат хәзерге вакытта Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең фольклор фондында саклана. Бу мәкаләдә әлеге архив материалларын бер цикл буларак туплап, аерым строфаларны эчтәлегенә карата эзлекле бер хәлгә китереп, укучыларны таныштыруны максат иттек.

Фольклорчы галимнәр җырның берничә көйгә җырланганын искәртәләр.

Башкарылу сәбәбенә, вакытына, кемгә аталуына карап, Әйтүкә җырларын берничә төркемгә аерырга мөмкин. Бу җырлар арасында кыска гына аңлатмасын биреп барабыз. Җырларның эчтәлеге һәр ситуацияне аңлаткан риваятьләр белән ярашып бара.

**Әйтүкә җыры**

«Әйтүкә белән Батыш» җыры геройларның бер-берсенә мәхәббәтен аңлаткан җырлар белән башлана. Алар бу җыр аша бер-берсенә соклана, бер-берсен мактый, бергә булырга да сүз бирешә.

*Әйтүкә:*

Йөгерәләй куян, йөгерәләй,
Мамык тикләй йонын туздыралай,
Бер яхшы берлән, ай, бер яман,
Әй җаныкай гынам, сылуым,
Шатлык белән гомер уздыралай.
Варианты:
*Йөгерә лә куян баласы,*
*Мамыктай ла йонын туздыра.*
*Ике лә яхшы бер кушылса,*
*Әй җаныкай гынам, сылуым,*
*Шатлык берлән гомерен уздыра.*

Ике лә генә кырның уртасында
Ятадыр ла куян баласы.

Дөнья-ахирәт, мәхшәр сәхрасында,
Әй жаныкай гынам, сылуым,
Корыладыр мизан тарасы.

*Батыш:*

Тәрәзәләрдән ник бактың?
Кар йомарлап, жаныем, ник аттың?
Берләр лә атмай, жаныем, ике аттың,
Әй жаныкай гынам, сылуым,
Яшь йөрәккәемә ут яктың.

Сикереп ләй төштем бакчага,
Бакчадагы пешкән алмага.
Бер матур белән уйнаймын дип,
Әй жаныкай гынам, сылуым,
Гөнаһкяр ла булдым Аллага.

*Әйтүкә:*

Әй жанкәм лә жанкәм, түзә алмыйм мин,
Тәрәзәдән күрсәм күз алмыйм мин.
Үнәр урамнарын, әй, үткәндә,
Синеләй күрмәй үтәлмим мин.

Урамыгыздан узганымда,
Ике генә күзем тулды яшем.
Кара ла кашым, асыл ташым,
Исән булсын газиз башың.

Әй, урамыгыздан, әй, узамын,
Яшел лә ефәк мин сузаем.
Яшел лә ефәкләр житмәсә,
Тәхлил-бәет әйтеп мин узаем.

Ай тулган ла жанкәм, әй, ай тулган,
Ай туган чакта ла син туган.
Тулган айдай якты ла йөзең,
Бу жиһанда синдәен кем булган.

Әй кыйгач ла кашым, карлыгачым,
Сине лә кайда күрәем мин?
Кызыл алмадай ай йөзеңне
Кай җирләрдән суырып үбәем мин.

Җырларда өч тапкыр Түкә кәмшек телгә алына. Язып алынган материаллар бу кешенең кем булуы турында информация сакламый. *Түкә Төхфәт* дигән исемнең бозылган варианты булырга мөмкин. *Кәмшек* сүзе «кыегайган, ямьшәйгән» дигән мәгънәдә. Бу очракта ул Төхфәтнең исеме белән янәшә кулланыла торган кушаматы булырга тиеш. Төрки халыклар эпосында, яшьләрнең мәхәббәтенә комачаулап йөргән хезмәтче традицион образ булуын да истә тотсак, Түкә Батышның атасында хезмәттә булган, кызны саклау да аңа йөкләтелгән хезмәтчесе булырга мөмкин.

*Батыш:*

Әй җанкәм лә, җанкәм, күзем туймас,
Бу җиһанда синдәен егет булмас.
Йөгереп чыгып үбәр идем,
Түкә лә кәмшек капка ачмас.

Таллардин ла очар талга кунар
Кара бакчай кошының баласы (кара бакчай – сыерчык).
Билдинләй кысып, авыздан сөйсәң,
Яхшы ла әткәйләрнең баласы.

Әй, Уралдай биек тау бармы икән,
Барып ла күргән ир бармы икән?
Авырлыклар күрмәй, әй, ярын алган,
Бу җиһанда андаен яр бармы икән?

Чобырлай чобыр тамчы тамар,
Тамчылары сары май кебек.
Кешеләр күзләренә әллә ничек,
Үз күземә тулган ай кебек.

*Әйтүкә:*

Әй, иртә лә торып юлга чыксам,
Олы ла юлда урыс ямщик.
Урыс ямщигенә, әй, охшаган
Үңәр урамында Түкә лә кәмшек.

Әй, йөгерепләр лә йөгереп җитәлмим мин,
Тал, читәннәрдән үтәлмим мин.
Билгеләре шулдыр сөюемнең,
Катындыйн (яныннан) ташлап китә алмыйм мин.

*Батыш:*

Әй, иртә лә торып тәрәзә ачып,
Таң атуларын көтәмен мин.
Йөрәгемә тулган гыйшык уты,
Сине лә уйлап уңамын мин (уңу – саргаю, сулу).

Батышны икенче кешегә ярәшкәннән соң, яшьләр өйләнешүдән өмет өзә, алар үзләре өчен качып китү генә калганын аңлыйлар. Җыр буенча фикер йөртсәк, Батыш качып китүне үзе тәкъдим итә.

*Батыш:*

Әй, китәек, җанкәм, әй, китәек,
Кара урманнардан, әй, үтәек.
Аяк аска басып дошман сүзен,
Үз теләгебезгә без җитәек.

Үңәр лә күле, әй, киң икән лә,
Сулары ястыкка тиң икән.
Ике лә күңел, әй, бер булганда,
Аеручы ла дошман, әй, кем икән.

Әй, баш имәм, җанкәм, баш имәм мин,
Үз теләкләремне итәрмен мин.
Аягыма богау салсалар да,
Аны да ла тибеп өзәрмен мин.

*Әйтүкә:*

Әй, китәрбез, җанкәм, әй, китәрбез,
Үз теләкләребезне, әй, итәрбез.
Безгә каршы килгән, әй, дошманның
Битләренә төкереп без үтәрбез.

*Батыш:*

Әй, күктә лә йөзгән бер йолдызга
Әйтәләр лә икән «Чулпан» дип.
Дошман ла сүзен читкә каккан
Егетләрне әйтәләр «солтан» дип.

*Әйтүкә:*

Каен төпләренә балта чапсаң,
Гөрләп оча аның, әй, тургае.
Үз сүзләреңдә, әй, тугры булган
Син, җанкәем, кызның, әй, солтаны.

*Батыш:*

Ашасаң ла шикәр, әй, бән куямын,
Ашаганыңны ла, әй, күрәем.
Ашаганыңны ла, әй, бән күрәем,
Сәнеңләй өчен бән үләем.

Әй, кырларда үскән куш каенның
Төпләренә билге кем юнган?
Сөйгәндә лә ярына туры булган
Бу җиһанда синдәен кем булган?

Яшьләр үзләренең мәхәббәтен дә, киләчәктәге бәхетсезлекләрен дә язмыш дип кабул итә. Җырда язмыш мотивы төрле яктан ачыла.

*Әйтүкә:*

Майдалай кәккүк, әй, кычкырадыр,
Язынлай-көзен һич белмидер.
Халаек безне күп сөйлидер,
Хак язганын һич белмидер.

Туй көнне Әйтүкә Батышны алып качып китә. Качып барганда, аларның бияләре колынлый. Ат колыны белән мавыгып бармый башлый. Бу вакыйга ике төрле бәян ителә. Беренчесендә колынлы бия тиз бара алмаганга, Әйтүкә колынны суярга тели. Әмма Батыш, колынны кызганып, бу эшкә юл куймый. Әйтүкә дә, Батыш каршы килгәч, колынга тими. Риваятьнең икенче вариантында, киресенчә, Әйтүкә колынны кызганып, аны суярга кулы күтәрелми. Батыш, атның туктап калуы аркасында бөтен планнарының җимерелү куркынычын аңлап, колынны үзе суя. Җырда да шушы хәлләр тасвирлана:

*Әйтүкә:*

Кара ла колын кешнәгәндә,
Туры ла биям, әй, тулады.
Батыш җанкәм аны суй дигәндә,
Ике лә кулым, әй, бармады.

Минем лә кулым, әй, бармады,
Батыш җанкәм пычак ошлады (ошлау – тоту).
Кешнәп лә торган, әй, колынны
Бугазыннан суеп, әй, ташлады.

Шуннан соң Әйтүкә үзенең халыкта иң таралган җыр юлларының берсен җырлый:

Кызылгат дигән, әй, җиләкнең,
Тышлары ла татлы, эче ташлы.
Минем лә сөйгән, әй, Батышның
Телләре лә татлы, күңеле каты.

Бу строфа галимнәр тарафыннан кат-кат язып алынган. Риваяте онытыла барып, җырның яңа варианты барлыкка килгән. Әйтүкәнең кызның кискенлеген, холкын күреп, гаҗәпләнеп җырлаган җыры мактауга, соклануга әйләнә:

Кызылгат дигән, әй, җиләкнең
Тышлары ла татлы, эче ташлы.
Минем лә сөйгән Фатыйманың
Авызы ла татлы, теле баллы.

Качып киткән яшьләр җыр юлларына Ябышкан дип кергән урманда, икенче вариантта болында яши башлыйлар. Бу җирләр аларның туган авылларыннан шактый ерак, кеше аягы басмаган аулак урын була.

Әйтүкә качып китеп урнашканнан соңгы җырларында аның сөйгәне белән кавышудан сөенеп, күпмедер вакыт эйфория халәтендә булуы аңлашыла:

Суда ла йөзгән ак балыкның
Баласын әйтерләр «култан» диеп.
Акча ла бирми ярлар сөйсәң,
Әйтүкәне әйтерләр «солтан» диеп.
Яр буйлары, әй, Ябышкан,
Ябышканда яткан бармы икән?
Яр буенда яткан Әйтүкәне
Әйтерләр аны «солтан» дип.

Шул ук вакытта үзләрен тынычсызлык, кире кайту турында уйлау, киләчәкнең билгесез булуы яшьләргә бәхетле булырга да ирек бирми. Алар үзләрен йолаларга каршы килүләре, илдә булмаган гамәл кылулары өчен гаепле тоялар. Алдагы строфаларда бер-берсен гаепләү, чарасызлык чагыла:

*Әйтүкә:*

Ябышканның буе ярлар микән,
Барып кына күргән барлар микән?
Газиз генә башын хурлар кылган
Яр сөйгән матур ярлар микән?

Ябышканның буе ярлар микән,
Барып кына күргән барлар микән?
Сөйгәнен алып мәерләй канган (мәерләй канган – күңеле рәхәтләнгән)
Бу дөньяда барлар микән?

Ябышканның буе ярлар микән,
Барып та лай күргән барлар микән?
Уйны да йөрдем, буйны да йөрдем,
Җан сөйгәннән артык барлар микән?

Кешеләрдән читтә яшәү аларга кыен бирелә. Икесе дә туган иленә кайту турында уйлый башлый.

*Әйтүкә:*

Карагат (карагат – карлыган) бәнем икеләй күзем,
Саргайды ла бәнем ике йөзем.
Исән генә булып илгә барсам,
Әйтергәләй күптер бәнем сүзем.

Сикереп лә төштем, әй, инешкә,
Ат бәйләдем сары камышка,
Үлмәсә дә адәм үлми икән
Эчекәе тулган сагышка.

Ябышкан буе, әй, ком такыр,
Алтын акчалар булмас бакыр.
Сагындым, җаный, әй, саргайдым,
Кайтмаенча булмас, ахыр.

Әй, әдернә лә тартып уклар аттым (әдернә – җәя)
Кырларда ла йөргән киекләргә.
Газиз генә башым туган икән
Дөньясынамы көекләргә (көек – кайгы, борчу).

Муены ла озын, әй, пүз (бүз) торна,
Әллә ничә төрләй бузнайдыр (бузнау – көйләү, сайрау).
Әй, уйны да йөреп, пуйны ла йөреп,
Мөхәндәрдин адәм узмайдыр (мөхәндәр – язмыш).

Күпмедер сугылып йөргәннән соң, Әйтүкә белән Батыш туган илләренә кайтырга булалар. Икенче версия буенча, аларны эзләп табып кайтаралар. Авылга кайткач, җырның эчтәлегенә караганда, авыл халкы җыела.

Хөкем иткәнче, Әйтүкә үзе чыгарган җырларны җырлап күрсәтергә тәкъдим итә. Бу җырларда ул Батышның матурлыгын, аңа булган мәхәббәтен тасвирлый. Картлар, бу җырларны тыңлагач, мондый көчле мәхәббәт өчен җәза бирү гөнаһ булыр иде дип,

хәзрәттән яшьләрне кичерүен үтенәләр. Әйтүкә җырларында мондый юллар бар:

Ул да яхшы, бу да яхшы,
Чәй эчкәндә бал да яхшы,
Баш коткарган тел дә яхшы.

*Ашаган чакта бал да яхшы,*
*Сөешкән чакта яр да яхшы.*
*Газиз генә башка эшләр төшсә,*
*Сөйләшкән чакта тел дә яхшы.*

Әйтүкә белән Батышның җырларында үзләренең гаепсез булуларын, бигрәк тә бер-берсенең гаебе юклыгын исбатларга тырышалар, берсе икенчесен коткарып калырга телиләр.

*Әйтүкә:*

Шаулап ла аккан, әй, елгада
Чуртан йөзә суларның үзенә.
Кимсетмәгез безне, әй, дусларым,
Кеше кермәс кеше ләй гүренә.

Таң алдыннан яуган, әй, карларга
Ак куяннар йөгереп лә юллар салган.
Сөйгәндә дә сөйгән ярын алу
Йосыф белән Зөләйхадан калган.

Суларда ла йөзгән, әй, балыкның
Баласына әйтегез «култан» диеп,
Маллары ла булмас ярлар сөйгән
Әйтүкәне әйтегез «солтан» диеп.

*Батыш:*

Күлләрдә лә ялгыз аккош,
Баласыннан аерып атмагыз.
Минемдә лә сөйгән Әйтүкәне
Малы юк дип читкә какмагыз.

Әй, какмагыз безне, әй, какмагыз,
Түкә кәмшек сүзенә бакмагыз.
Гомерлек лә итеп сөйгән ярым,
Аерып ла мине утка ла якмагыз.

Аера алмассыз мине Әйтүкәмнән,
Бугазыма баулар, әй, салмыйча.
Аера алмассыз мине Әйтүкәмнән,
Газраилләр җаным, әй, алмыйча.

*Батыш:*

Әй, беләгемә кигән куш беләзек
Ай яктысы төшсә ялтырый.
Минем лә сөйгәнем, әй, Әйтүкә
Ир-егетләрнең лә иң батыры.

Үнәр байларының соравы буенча, Әйтүкәне хөкем итү өчен, шәһәрдән кыңгыраулы унсигез пар атта 18 түрә килгән. Алар Әйтүкәне гомерлек каторгага хөкем итәләр. Ахырда баш түрә: «Сезне җырчы диләр, ахыргы минутыгызда бер җырлап күрсәтегез», – ди. Баштагы җырдан түрә бу безне бик мактады дип аңлый, «бик күп маллар түгәр идем алтын штуф укалы якагызга» дигән юлларны бу безгә ришвәт бирәчәк икән дип аңлап, хөкем бәзасын йөз чыбык суктырырга калдыра.

Әйтүкәнең суд приставы килгәч җырлаган җыры:

Ат бәйләгән кубагызга (куба – күчмә өй, чыбыктан үрелгән),
Чәң (чәң – кыңгырау) бәйләгән дугагызга.
Гакылым бетте, исем китте
Алтын штуф бәйләгән якагызга.

Ат бәйләрмен курагызга,
Чәң бәйләрмен дугагызга,
Бик күп маллар түгәр идем
Алтын штуф укалы якагызга.

Риваятьләр Әйтүкәне төрмәгә утырткannar, аның төрмәдән җырлаган җырлары да булган дип бәян итә.

Икенче версия буенча, Әйтүкәне утыртмаганнар, ләкин аңа Батыш белән калырга да рөхсәт булмаган. Ул үзенең беренче хатыны, баласы янына кайткан.

Әйтүкә белән Батышның хөкем карарыннан соңгы җырларында мәхәббәткә, гашыйкларның тугрылыгына дан җырлана:

*Әйтүкә:*

Батыш җанкәм суга иңгән,
Көянтәсен талга элгән.
Буе зифа тал чыбыктай
Яр буласын, әй, кем белгән.

Батыш җанкәм урак ура,
Уң беләген, әй, талдырып.
Батыш җанкәй мине сөйде,
Байлар күңелен, әй, калдырып.

Батыш җанкәй, әй, кия лә
Кара сатин көйләген ( көйләк – күлмәк).
Батыш җанкәм ташламайды
Маллар өчен, әй, сөйгәнен.

Ашасаң да шикәр, бән куямын,
Ашаганыңны ла, әй, күрәем.
Ашаганыңны ла, әй, бән күрәем,
Сәнеңләй өчен бән үләем.

*Батыш:*

Онытмам ла, җанкәм, онытмам мин,
Синнән лә башканы яр итмәм мин.
Синең лә кайгыңнан, әй солтаным,
Камыштаен саргаеп үләрмен мин.

Өченче риваять Әйтүкәнең хөкем ителүен бәян итә. Әйтүкә өстеннән җәза башкарылган. Баш түрә Әйтүкәдән, яңадан Батыш-

ны алмам, дигән сүз ала. Шуннан соң Әйтүкәне атып үтерәләр. Бу вариант җыр юллары белән дә туры килә. Батышның соңгы җырларында хөкем карарының нинди булганы да, палач турында да мәгълүмат саклана:

Сине генә сагынган чакларымда,
Астанаңа башымны куярмын мин.
Әй, моңланып кошлар сайраганда,
Сине генә уйлап җырлармын мин.

Әйтер сүзен әйтә алмый торды,
Эт урядник кылыч, әй, алганда,
Әйтер сүзен әйтә алмый торды,
Түкә кәмшек мылтык, әй, атканда.

Әй, куе ла кауданлы каен төбе,
Яныкаем, яткан җирең булды.
Кара ла туфрак, әй, астында
Алмадаен кызыл ла йөзең сулды.

Батыш, Әйтүкә үлгәннән соң, башка кияүгә чыкмаган. Гомере буе Әйтүкәне эзләп, 60 яшендә Үңәргә кайтып вафат булган.

*Текст Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәим сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең фольклор архивында сакланган материаллардан төзелде.*

*Аларны фольклорчы галимнәр Х. Рахматуллин, Х. Ярми, Һ. Мәхмүтов, Ф. Урманчеев, Ф. Әхмәтова, Х. Гатина, В. Хаҗиев Новосибирск өлкәсенең төрле районнарында фольклор экспедицияләре вакытында туплаган. Информантлар исемлеге:*

*Бараба районы Бакчакүл авылы, Аәнбанов Габбас, 1884 елгы, Ажбаков Мөслим, 1891 елгы.*

*Венгерово районы Арынсас авылы, Вахитов Мәгърүф, 1905 елгы; Венгерово авылы, Назирова Мөршидә, 1910 елгы.*

*Куйбышев районы Шагыр авылы, Рафикова Мөхлисә, 1882 елгы; Баязитова Оркыя, 1897 елгы; Мәргу Хәйдарова, 1898 елгы; Сәлимҗанов Хәмидулла, 1878 елгы.*

*Чаны районы Кошкүл авылы Мөхәммәтшин Аллаяр.*

*Чаны районы Тармакүл авылы, Ишмакова Нәкыя, 1923 елгы; Нургалиева Вәйдә; Шәмсетдинов Гази, 1903 елгы; Кәрим Ташпулатов; Сәфәргали Юнанов; Сиражҗетдинов Давыт; Хәбибуллина Хәтирә, 1890 елгы; Вәлиуллина Нурҗамал, 1899 елгы.*

# ДЕКОРАТИВНО-ПРИКЛАДНОЕ ИСКУССТВО ТАТАР НОВОСИБИРСКОЙ ОБЛАСТИ

*Роза Фаткуллова*

Данный материал посвящен исследованию состояния развития декоративно-прикладного искусства и ремесел татар Новосибирской области в настоящее время. Впервые производится анализ произведений народного творчества местных чатских и барабинских татар с особенностями искусства татар других регионов России и в особенности казанских татар. Значительное внимание уделяется искусству вышивки и декоративной резьбы по дереву. Высказываются предположения о возможности возрождения традиционного прикладного искусства, которое может послужить фактором сохранения национальной идентичности.

Статья написана по материалам экспедиции, которые дают представления о прикладном искусстве татар Новосибирской области с конца XIX века и до наших дней. Были обследованы практически все ныне существующие населенные пункты татар данного региона.

Опираясь на собранный материал, можно с уверенностью сказать, что прикладное искусство играло значительную роль в жизни местного татарского населения. Желание удовлетворить эстетические потребности в художественном оформлении жилища, одежды и предметов быта способствовало развитию различного вида ремёсел.

Татары – один из древнейших и многочисленных этносов на территории Новосибирской области, имеющие непростую историю этнокультурного развития. Годами татары вбирали в свою культуру множество элементов культур разных народов, проживавших на территориях степи, лесостепи, южной тайги, что отразилось на своеобразии особенностей их материальной и духовной культуры [13].

**1. Сельские дома и постройки**

Благодаря сохранности строений, возведенных в конце XIX в., имелась возможность провести исследование более ранних временных отрезков. Сохранилось много старых домов, по которым можно судить об особенностях расположения и назначении жилых и хозяйственных построек. В ходе исследования было опрошено преимущественно старшее поколение, благодаря чему удалось узнать об элементах и поселенческо-усадебного комплекса, бытовавших в начале XX в. Об особенностях более современной деятельности местных мастеров можно было разузнать методом непосредственного наблюдения.

В Новосибирской области проживают чатские и барабинские татары. Со слов имама мечети в деревне Юрт-Ора Навиля Хасановича Шагабутдинова, татары проживают здесь с VIII в. н.э. Степень уникальности местного зодчества и прикладного искусства в деревнях также имеет некую зависимость от процентного соотношения количества коренного населения с приезжими татарами и другими национальностями. В довоенные годы, особенно во времена голода в Поволжье, а также во избежание репрессий, сюда переехало жить много татар из Татарстана, Ульяновской и Самарской областей. Новосибирская область расположена в лесной и лесостепной зонах. В XIX в. сибирские татары называли собственные поселения юртами или аулами. Исключением является деревня Юрт-Ора, там деревню называют «аил».

Первоначально места жительства татар возникали близ естественных водоемов, на возвышенных местах. Поселения XVI–XVII веков в основном располагались на некотором расстоянии от реки. Такое расположение позволяло более комфортно пережить

зимние невзгоды (защита от ветра, наличие поблизости топлива для отопления и т.д.). В конце XVIII – середине XIX вв. формируется тип заселения по берегам мелких речек и озер [20, с. 3].

У деревень Новосибирской области приречный тип поселения, например, в Колыванском районе преимущественно все татарские деревни расположены у рек Обь и Уень. Для большинства деревень характерна правильная прямолинейная планировка двусторонних улиц, распространившаяся под влиянием окрестных русских деревень. Начало процесса формирования улиц в деревнях татар Новосибирской области можно отнести к середине XIX в. К концу XIX в. большинство поселений татар имели уличную планировку. В XX в. уличный тип планировки сохранялся с различными вариантами – одноулочным, двухулочным и многоулочным. Одноулочная планировка встречалась, прежде всего, в поселениях, основанных во второй половине XIX – начале XX вв.

В Колыванском районе преобладает уличный тип планировки, в деревнях насчитывается по четыре – пять улиц, в Каргатском районе деревни имеют преимущественно одноулочную планировку. В селениях изучаемого населения не сложилось квартальной планировки.

Исследование плотности застройки поселений и расположения усадеб показало, что застройка поселений татарами велась в различных направлениях – как вдоль водоема, как в деревнях Юрт-Акбалык, Юрт-Ора, так и в сторону от него. Как и прежде, их улицы имеют различную форму (изогнутую, Г-образную, прямую) [20, с. 3].

В XIX – начале XX вв. посередине деревни или на берегу реки находилась деревянная мечеть. Она выступала религиозным и общественным центром, местом общих собраний, и несла центрообразующую функцию в планировке поселения [18]. На сегодняшний день в Новосибирской области татарские деревни, как правило, имеют ярко выраженный центр, которым может быть мечеть, как в д. Юрт-Ора, сельский клуб или здание школы, как в деревнях Казанка, Мусы, Теренино.

В VIII веке поселения делились на зимние и летние. Летние, в отличие от зимних, располагались в местах удобных для

ведения сезонного хозяйства (лова рыбы, выпаса скота и т. д.). Обычно это была пойма крупной реки. Источники XVIII–XIX веков свидетельствуют о том, что таких сезонных поселений могло быть несколько. Примером могут служить деревни Теренино и Шибаки, которые местные жители называют по-татарски Жэйлэу и Кышлау, что в переводе как раз означает летнее и зимнее поселение. По рассказам жителей, раньше их предки летом жили в Теренино (Жэйлэу), а на зиму переезжали в Шибаки (Кышлау).

Своеобразие быта сибирского крестьянина и местный климат требовали наличия определенных особенностей в строительстве. Сельские дома Новосибирской области имеют свои отличительные особенности, которые, по рассказам местных жителей, в основном характерны для многих сибирских домов. Это четырёхскатная крыша, минимализм декоративной отделки, высокое крыльцо (илл.1,2). Редко встречаются дома, богато украшенные резьбой и с двухскатной крышей. Однако в деревне Юрт-Акбалык есть дома коми-пермяков, имеющие фриз, богато украшенный прорезной резьбой (илл. 3,4,5).

В деревнях Юрт-Ора и Юрт-Акбалык сохранились дома, построенные зажиточными крестьянами более ста лет назад. Это жилища с просторными комнатами, с высоким крыльцом, их окна большие по размеру и имеют арочные своды. На улицу у таких домов выходят по 5 окон. (илл.6) Многие из них раньше имели второй этаж, но были перекатаны и стали одноэтажными. Было это сделано, по рассказам жителей, во избежание репрессий в сороковые годы прошлого века. Большинство из них – это крестовые, шестистенные дома с четырёхскатной крышей, имеют просторную веранду и крыльцо (илл. 15, 53). Некоторые окна сдвоенные или строенные (илл. 17). Встречаются дома татар-мишарей с мезонином, который местные жители называют балкон. Аналогичное название встречается у сергачских мишарей.

Следует отметить наличие достаточного количества архаичных черт. Кровля и фундамент выполнены «архичными» для нашего времени материалами и технологиями. Основа дома – окладник, для изготовления которого использовали «сагызлы

агач» (в переводе буквально – смоляное дерево), кедр или сосну; деревья, выделяющие смолу, что способствовало крепости фундамента, для которого старались выбрать наиболее толстый ствол (илл. 58). Иногда встречаются дома без фундамента, но таковых немного. Характерная особенность деревень Колыванского района – заборы «читэн» (по-русски «заплот»), которые встречаются в сибирских деревнях из-за обилия леса вокруг. Это сплошная стена из бревен, высотой в человеческий рост или выше (илл. 59,60). Наиболее часто они встречаются в деревне Юрт-Акбалык. В Каргатском районе такие заборы не встречаются, по всей видимости, из-за отсутствия в этой местности хвойных лесов.

Декоративная расцветка фронтонов такая же полихромная, как и у казанских татар, однако в Каргатском районе, в отличие от Колыванского редко встречаются красные и жёлтые фронтоны. Излюбленные цвета – голубой, ультрамарин, бирюзовый, белый и светло-зелёный. Например, в деревне «Теренино» самая популярная окраска – светло-зелёного цвета ( илл. 82, 84, 85, 86, 88). Наиболее предпочтительные оттенки – зелёные и синие цвета. Из синих оттенков чаще всего встречается небесно-голубой и ультрамарин. Зеленый цвет, символизирующий жизнь, наиболее важный цвет в исламе. Синий и голубой цвет также любим и почитаем здесь, как и во многих других регионах проживания татар, на арабском Востоке и у разных тюркских народов Евразии. Его считают цветом неба, а также цветом духовности. При окраске чаще всего встречаются сочетания трех цветов – синий, белый, голубой или зеленый, синий, белый или зеленый, бирюзовый, белый. Однако, богато украшенные декором дома в Колыванском районе, в деревне Юрт-Акбалык, отличаются более богатой цветовой палитрой. Они содержат также красный, жёлтый, розовый, коричневый, оранжевый цвета (илл. 63, 65, 76). В целом, самый популярный цвет во сех деревнях Новосибирской области – небесно-голубой.

Палисадники в д. Юрт-Акбалык и Юрт-Ора имеют глубину полтора или два метра, а в деревне Казанка многие палисадни-

ки глубиной всего один метр и даже меньше (илл. 73). В Каргатском же районе часто встречаются гораздо более широкие палисадники. Например, в деревне Теренино есть палисадники глубиной в два с половиной или три метра (илл. 90, 92). Ограда палисадника здесь преимущественно из штакетника, в связи с недостатком строительного леса. Обычно палисадники окрашены в той же цветовой гамме, что и окраска самого дома. Палисадники есть почти у каждого дома, однако в Юрт Акбалык встречаются и дома, не имеющие палисадника. В основном это небольшие дома – пятистенки, которые также располагаются длинной стороной к улице (илл. 67, 68).

На сегодняшний день наличие мечети в деревне отмечается только в Колыванском районе, и преимущественно это новые постройки, чему поспособствовали поддержка администрации региона и местного духовенства. В исследованных деревнях Каргатского района мечетей нет, однако в музее клуба деревни Мусы выставлен макет существовавшей ранее мечети, сделанный по старой фотографии.

Как правило, мечети одноэтажные, и отличаются от обычного дома наличием минарета, имеющего балкон (шерефе). В центре деревни Юрт-Ора стоит нарядная мечеть современной постройки (илл. 8, 9, 10). По своей архитектуре напоминает современные мечети в сёлах Татарстана. Материалом для строительства выбрана сосна. Её построил местный мастер – плотник Гариф Галеев, благодаря усилиям и поддержке имама Навиля Хасановича Шагабутдинова, а также благодаря поддержке главы администрации Колыванского района.

Следует отметить наличие желания сберечь сохранившиеся постройки и рукодельные материалы, а также желание возрождения традиционного творчества у администрации и жителей деревни Юрт-Ора. Со слов имама мечети Шагабутдинова Навиля Хасановича, в деревне начинается строительство национального музейного комплекса для размещения сохранившейся музейной коллекции. Деревня Юрт-Ора считается поселением татар-чатов, частично сохранивших аутентичные древние обычаи. Ее уникаль-

ность в том, что она находится на территории древнего городища, вновь выявленного памятника археологии. Организовано посещение туристами дома-музея, в котором можно увидеть национальную одежду, обувь и другие предметы ручного труда.

К сожалению, количество сохранившихся деревянных ворот очень невелико, большинство ворот современные, металлические. Большинство деревянных ворот богато украшены декором, содержащим элементы растительного и геометрического орнамента, такие как: волнообразный побег, сложные линейные композиции типа «модехиль», мотивы трилистника и тюльпана, а также геометрический орнамент, сердцеобразный мотив и мотив розетки. Ворота, которые имеют двускатное перекрытие, обычно высокие и достигают карниза дома.

В Юрт-Акбалык есть некая примечательная особенность, свойственная больше для сибирских деревень. Это ворота с острым треугольным завершением, имеющие массивные столбы, которые имеют квадратное сечение и иногда такие же острые пирамидальные завершения со слегка обтесанными краями квадратов. Столбы ворот по своей массивности не имеют аналогов на европейской территории России, что обусловлено скорее всего климатическими условиями (илл. 69).

Отличительная особенность местных крылечек в том, что они очень высокие, имеют по семь или восемь ступенек, в большинстве массивные, украшенные вставной пропильной резьбой, узорами с богатым геометрическим орнаментом. В селах Казанка и Юрт-Акбалык много крылечек с лёгкой калиткой с двумя дверцами у последних ступеней.

С 1950-х гг. усиливается стремление к компактному расположению построек на усадьбе и их объединению [21, с. 2]. В деревнях Юрт-Акбалык, Юрт-Ора, Мусы часто встречаются системы навесов, соединяющие хозяйственные постройки усадьбы, и образующие дополнительные объемы, использующиеся в хозяйственных целях. Дом может иметь большую веранду, плавно переходящую в подсобные постройки или мастерскую.

Богатым разнообразием выделяется декор наличников. Примечательно, что в Каргатском районе наличники украшены го-

раздо проще, что тоже говорит о недостатке дерева, в виду отсутствия достаточного количества леса в округе. Деревянный промысел здесь не получил такого расцвета как например в Колыванском районе, где по рассказам жителей, раньше было много мастеров – плотников. Желание иметь красивые наличники было для жителей важным.

Большинство окон здесь имеют большие размеры по сравнению, с окнами в деревнях Татарстана. Особенно можно выделить окна деревень Юрт-Ора и Юрт-Акбалык – они самые богатые по декоративной отделке и самые большие по размеру, имеющие наличники украшены накладной и пропильной резьбой. Орнамент при оформлении используется геометрический, растительный и стилизованный зооморфный. Применяются такие элементы, как: розетки, полурозетки, поверхности в виде прямоугольных, ромбовидных форм, трилистники, пальметты, полупальметты, тюльпанообразные и листовидные узоры, узоры сердцевидной формы, изображения лотоса, мотивы набегающей волны, рогообразные мотивы (илл. 64, 76). Последние редко встречаются у казанских татар, а чаще встречаются у сибирских народов и у народов Средней Азии, например, у казахов, а остальные, вышеперечисленные, встречаются и у народов Сибири и в творчестве казанских татар, что может указывать на связь местного населения с тюркскими народами Сибири и с казанскими татарами. В деревнях Юрт-Акбалык и Юрт-Ора есть окна, имеющие арочную форму, построенные в первой половине XX века местным плотником Вахитовым Курбаном (илл. 76). Наиболее часто зооморфные мотивы в виде птиц, оленей встречаются в деревне «Казанка», где живут потомки татар, переселившихся сюда с территории современных Татарстана, Башкирии, Самарской и Ульяновской областей. Большинство населения – казанские татары, которые дали в свое время название населенному пункту. Наиболее популярным мотивом является стилизованное изображение птиц, которых часто можно увидеть на кокошнике наличников. Несмотря на отсутствие высокого художественного уровня исполнения, в них чувствуется стремление к реалистической передаче живых образов. Образ

птицы был широко распространён и в искусстве казанских татар, что свидетельствует об общности и традиционности их представлений с сибирскими татарами.

В деревне Юрт-Акбалык имеется несколько домов с наличниками, имеющими кокошники со стрельчатыми завершениями, что говорит о связи с мотивами архитектуры Средней Азии и свидетельствует о наличии торговых отношений со среднеазиатскими странами. Часто у таких наличников имеется накладная розетка в виде солнца или цветка, выступающая от фасада и снабжённая резным подзором.

Наибольшее распространение здесь получает своеобразный мотив, который встречается почти во всех деревнях – это волнообразные края кокошника со спиральным завершением кверху в центре. Доски, выпиленные в виде волны, в середине кокошника закручиваются в спираль, между которыми располагается отдельно выпиленный узор, чаще всего в виде трилистника, пальметты или сердца. Мотив «сердца» здесь не менее популярен. Чаще всего можно увидеть, что сердечки располагаются симметрично относительно центра кокошника острыми краями наружу. Подоконный пояс часто отсутствует, а при наличии украшается накладной резьбой, но весьма скромно. Боковые стойки украшены чаще простым геометрическим орнаментом и редко растительным. Обычно на них нанесен глухой рельефный узор, а также популярны накладные элементы: различные розетки, полурозетки, прямоугольники, ромбы, треугольники и квадраты. Кокошники у наличников часто украшаются лотосообразными мотивами, мотивами тюльпана, спирали, что свидетельствует о явном влиянии искусства казанских татар.

В формировании следующей особенности мотива декорирования наличников сыграло, по всей видимости, географическое положение деревни, которую с одной стороны окружает сосновый лес, с другой кедровый, его здесь называют «кедрач». В Юрт-Акбалык встречаются наличники с накладной резьбой с мотивами, тесно связанными с природой, напоминающие шишки и ветки сосны. Такие мотивы не встречаются в Каргатском районе, где

местность болотистая и из деревьев встречается только береза и осина. Эта местная особенность позволяет о наличии уникальных мотивов декорирования, не имеющих аналогов у татар, проживающих в других регионах.

Стоит отметить, что преобладающее большинство окон не имеют ставен, наличие которых характерно для большинства сибирских деревень. У татар не было принято закрывать окна ставнями. В этом не было необходимости, ввиду того, что дом часто размещался далеко от линии улицы. Таким образом, отсутствие ставен позволяет говорить о сохранении национальных черт у местного населения. Исключением являются только дом в деревне Казанка и один дом в деревне Юрт-Акбалык с резными ставнями.

Примечательно, что почти все наличники в деревнях старые, изготовлены не позже шестидесятых или семидесятых годов. На сегодняшний день почти нет мастеров, занимавшихся раньше изготовлением наличников. По рассказу мастера из д. Юрт-Ора Саета Мавлютова, раньше в деревне было много мастеров-плотников. В 1960-е годы славился своим умением мастер по имени Зиннэт, который был одним из лучших изготовителей наличников, а также ворот (какма – тат.). На сегодняшний день это ремесло почти угасло и он считается единственным старым мастером в этой деревне. К сожалению, мастера не оставили после себя учеников. Исключением является Гариф Галлеев (1963 г.р.) из деревни Юрт-Ора, полностью самостоятельно построивший свой дом и все постройки на своём участке. Мастер в работе использует и прорезную резьбу, и накладную. В настоящее время он постоянно работает в своей мастерской, придумывает и разрабатывает новые узоры, чувствуя себя на пике творческого подъёма. В его мастерской большое разнообразие зарисовок и лекал, при изготовлении которых используется сложные растительные и геометрические мотивы (илл. 19–29).

Фриз, богато украшенный прорезной многослойной резьбой, содержит элементы с мотивами тюльпана, сердцеобразные, лотосообразные, спиралеобразные, рогообразные мотивы. Эти формы

также своеобразно применяются в орнаментации наличников. Из сердцеобразного мотива получаются довольно интересные вариации: от фигуры близкой к листочку, до копьевидной. В оформлении крыльца, балкона и в оформлении очелья использованы сложные криволинейные геометрические фигуры. Только в деревне Юрт-Ора среди остальных татарских деревень имеется такая современная, обильно украшенная декором постройка (илл. 32–51). В 2014 г. в деревне им была построена и декорирована мечеть, элементы отделки которой напоминают отделку дома мастера.

Стоит отметить, что дома почти не обшиваются досками, а также отсутствие пилястров в углах фасадов. Изредка встречаются дома, обшитые рустовкой, в основном это косая рустовка. Окрашивают только обшитые дома или обмазанные глиной снаружи, однако большинство домов не окрашены. Самый популярный цвет окраски крыши – краснокирпичный.

Примечательно то, что в Колыванском районе дома обмазаны глиной с песком и покрашены извёсткой только изнутри. Только один дом в Юрт-Ора Сафаргалеевой Раисы Хабибулловны (1934 г.р.) обмазан глиной снаружи и покрашен извёсткой (илл. 13). В Каргатский районе, в связи с сырым климатом, для предохранения дерева от гниения, жители обмазывают глиной дома не только внутри, но и снаружи. Благодаря этому возраст домов достигает ста и более лет. Многие дома обшивают листами ДВП, местные называют его оргалитом (илл. 89, 92). В этой местности по причине болотистых условий лес (береза, осина) для домов не совсем пригоден для строительства, поэтому многие бревна кривые, разной толщины. Материалом для сруба чаще всего служат березовые бревна. Иногда встречаются дома, выполненные по старым традиционным технологиям: без фундамента, углы верхних венцов не обрезаны и выглядят неряшливо. В деревне Мусы большинство домов, обмазанных снаружи глиной, покрашены в светло-зелёный цвет (илл. 81–88).

На основании собранного материала можно сделать выводы о том, что главную роль в становлении самобытности местного творчества сыграли местные природные условия, повлиявшие

на возникновение уникальных особенностей декорирования усадеб. В особенности это выражено в искусстве резьбы по дереву, а также об этом свидетельствует наличие такого ремесла, как изготовление долбленых лодок. Следует отметить большое количество сохранившихся домов конца XIX в. Безусловно, этому способствовала некая отдаленность и обособленность деревень от больших городов. Несмотря на небольшое количество поселений татар и расположение их в окружении русских деревень, они смогли сохранить свою национальную идентичность, выраженную в данном случае в особенностях строительства и резьбе по дереву. К сожалению, современные постройки, за редким исключением, уже не содержат элементов национальной культуры. Однако небольшое наличие мастеров-плотников, любящих свое дело, дает надежду о наличии тенденций к возрождению народного зодчества.

**2. Внутреннее обустройство жилища**

Преобладающее большинство сельских домов крестового типа. Это шестистенники, имеющие в основном по четыре (жилые) комнаты. Встречаются и пятистенники, которые обычно имеют большую веранду. Как правило, дома стоят фасадом вдоль улицы. В деревне Теренино Каргатского района все дома построены по распоряжению в 1960-е годы. Однотипные дома для двух семей с двумя отдельными входами. В плане такие дома имеют форму прямоугольника. Встречается и квадратная планировка. Фронтальная стена дома, которая смотрит на улицу, чаще всего разделена поперечной стеной. Наибольшая по площади комната обычно имеет три окна, а меньшая два. Такая асимметрия наблюдается почти во всех татарских деревнях Новосибирской области. В домах же с симметричной планировкой, со стороны улицы расположены четыре окна.

Обычно, пройдя крылечко, попадаешь на большую веранду, которая обычно очень светлая, просторная, с широкими сплошными окнами. Из веранды можно пройти в первую комнату-коридор, в которой чаще всего есть одно окно. Из этой комнаты обычно ве-

дут две двери, одна в гостиную, другая на кухню. Вход в четвёртую комнату, может быть как из кухни, так и из гостиной. Бинарное разделение дома на женскую и мужскую части отсутствует. Закрепление комнат за различными членами семьи встречается редко. Например, у Мавлютова В. Р. в д. Юрт-Акбалык, к старому дому пристроен новый кирпичный или такой же бревенчатый дом. Печь может располагаться как на кухне, так и в коридоре и в гостиной, и обычно отстоит от стены. А также расположение может быть таким, что печь выходит разными сторонами в разные комнаты.

Изнутри дом обмазывают глиной с песком и белят извёсткой. Чаще всего обмазка белого цвета, но иногда в нее добавляют колер, и стены могут быть розовыми, голубыми, бежевыми. Например, в д. Теренино дом Кунгуловой Захиры Закировны (1940 г.р.) изнутри покрашен в ярко-голубой цвет (илл. 131). Голубой цвет интерьера наиболее часто встречается в Каргатском районе. Такая особенность не имеет аналогов в других регионах проживания татар. Однако примеры раскрашенного интерьера встречаются в Республике Татарстан в Мензелинском районе, что было выявлено во время экспедиции в 2003.

Печь также красят в тот же цвет, что и дом. Печку украшают различной домашней утварью. В любом доме внутри очень чисто и уютно, хотя внутреннее убранство очень скромное. Часто в доме на стене в гостиной висят большие часы. Оформление комнаты с помощью сундука встречается редко. Чаще всего он бывает задвинут в угол или находится в подсобном помещении. Только в деревне Казанка, в доме Мингазетдиновой Асылбикэ Курбановны (1941 г.р.) сундук используется по назначению и служит частью оформления интерьера (илл.101). Однако многие его хранят как память о прошлом, как например, в деревне Юрт-Акбалык Вильлюр Мавлютов хранит сундук, передаваемый из поколения в поколение, который достался ему от отца (илл.100).

Оклейка комнат обоями здесь почти не встречается. Искусство шамаиля в этой местности не было развито, однако популярны шамаили, купленные в магазине, в виде репродукции на бумаге. Их можно встретить почти в каждом доме, также как и купленные

ковры с пасторальными мотивами, с изображениями оленей или лебедей. Не менее популярны и намазлыки, висящие на стенах, используемые для украшения жилища. Почти везде на окнах стоят горшки с цветами.

Излюбленное украшение интерьера – разноцветные занавески из хлопчатобумажной ткани. В деревне Казанка, например, занавески с оборками вешают на комод, над входом и украшают ими верх печки. Салфетки, вышитые гладью, принято вешать острыми углами вверх и вниз на стену в качестве украшения. Не менее популярным и актуальным было вязание сидушек для табуретов из шерстяной и хлопковой пряжи (илл. 318).

җырлары («Кияү типсәү»), ишек бавы җыры, кызның чәчен икегә аерып үргәндә башкарылган җырлар («Яр-яр», «Үләң таш»), кызны егет өенә озату, туй мәҗлесендә кода-кодагыйларның бер-берсен макташу җырлары, кара-каршы башкарыла торган күңелле туй уены җырлары («Хан кызы», «Башмак» һ.б.), сатып яки көчләп бирелгән кызларның ата-анасын, туган авылын каргап китү җырлары. Гаилә тормышында туйлар зур вакыйга рәвешендә бик күңелле һәм шау-шулы үткән. Туйга авыл халкы белән беррәттән алыстан да кода-кодагыйлар һәм кардәшләр килгән. Кагыйдә буларак, килен читтән алынган. Чөнки ыруглык калдыклары озак сакланып калган Себер татарларында бер авыл кешеләре бер-берсе белән туган-тумача саналган һәм алар арасында өйләнешү тыелган. Туй ул – яңа гаилә төзү тантанасы, кыз белән егетнең җитлегүен мактау тантанасы. Яучылау һәм фатиха бирүдән алып, туйдан кунаклар таралган вакытка кадәр булган һәрбер адым тирән этник мәгънәгә ия. Ул берничә гасырлар элек шушы этник төркемгә хас тормыш-көнкүреш һәм семья-әхлак кагыйдәләреннән чыгып төзелгән.

Туйларга махсус рәвештә җырчылар һәм музыкантлар чакырылган һәм туйның җыр-музыка белән үткән өлешенең уңышлы чыгуы музыкантлар, җырчылар осталыгына турыдан-туры бәйләнгән. Мондый кадер-хөрмәт, күрәсең, җыр-музыка туй вакытында үзенә күрә ниндидер магик көчкә ия була дигән ышануга нигезләнгән. Бу ышану Себер татарларында XX гасыр башларына кадәр дәвам итә. Туй йоласы җырлары да шул чоргача актив рәвештә башкарылып килә, һәм ул җырлар өлкән яшьтәге кешеләр хәтерендә әле дә саклана. Күпләренең өйләнү-кияүгә барулары шул җырлар белән үткән.

Туй йоласы җырларын туйның өч моментында башкару мәҗбүри булган: кияүне урам буйлап «тип сугып» кыз өенә озата барганда «Кияү типсәү» («Күч җыры», «Кияү сүзе», «Ялтыр-талалтир»), кыз өенең капка төбендә «Ишек бавы» җыры, егет өенә китер алдыннан кызның чәчен икегә аерып үргәндә, «Яр-яр» яки «Үләң таш» җырларын җырлаганнар.

«Яр-яр» җырларына тукталып үтик. Себер татарларында, кайбер башка халыклардагы кебек, кыз белән яшь киленне чәч толымына карап аерганнар. Кызлар чәчне бер толымга үреп йөртсә, яшь киленнәр исә аны икегә аерып үрергә тиеш булганнар. Шуңа күрә чәч аеру ритуалы кыз озатканда иң изге, иң җаваплы йолаларның берсе саналган[18]. Ул болай үтәлгән. Кияү егетләре белән кызны алырга килгәч, кызның җиңгәләре чыбылдык эчендә кызның чәчен махсус тарак белән, елый-елый, икегә аерып үрә башлыйлар. Һәм шул вакытта кызның туган-үскән йорты, атаанасы, дус-ишләре, туган-тумачалары белән саубуллашу сәгате җиткәнне аңлатып, «Яр-яр» әйтелә башлый.

«Яр-яр» җырлары гаять зур территориядә яшәүче төрки телле халыкларга хас. Күрше казакъларда ул – «Җар-җар» үзбәкләрдә – «Ёр-ёр», нугайларда – «Хей-җар», каракалпакларда – «Хауҗар», Башкортстанның Ык буе татарларында – «Яр-яр».

«Яр-яр»ның шигъри тексты Курмашиның «Кыйссаи бүз егет» дастанына да кертелгән. Бу очраклымы? Күрәсең, юк. Һәрхәлдә, XVII гасырга караган «Яр-яр» текстының безнең Идел буе төбәгендә табылуы бу йола җырының Идел буенда яшәүче татарларга да ят нәрсә булмаганлыгын әйтеп тора[19].

Драматург М. Фәйзинең дә «Кызыл йолдыз» пьесасына бу куплетларны кертүе, һичшиксез, халык иҗатына таянудан килә. Соңгы елларда гына өйрәнелгән Ык буе татарлары иҗаты да – моның ачык мисалы[20].

«Кияү типсәү». Төмән өлкәсе авылларында шушы җыр белән кияүне кыз куенына озатканнар. Бу болай булган. Башка авылдан килгән кияү иң элек дусларына яки туган-тумачаларына туктый. Нугәрләр (кияү егетләре) кияүне ике яктан култыклап алып,

---

[18] Әхмәтова Ф., Гайнанов Р. Себер юлларында // Социалистик Татарстан. 1967. 13 август саны.

[19] Усманов М. Об археографических экспедициях Казанского университета // Тихомировские чтения 1970 года. Мат-лы науч. конф., посвящ. опыту организации археогр. экспедиций в РСФСР. М., 1970. С. 122.

[20] Мөхәммәтҗанов Р М. Башкорстан Ык буе татарлары йола иҗаты. Автореферат. Уфа, 1973.

шушы җыр белән кыз өенә алып киләләр. Әгәр дә кияү буласы егет күңеленә хуш килгән кеше булса, кыз түшәк җәеп көтеп торган, ошамаса – чыгып качкан. Бу очракта аны беркем дә көчләп бирергә батырчылык итмәгән. Шунысы кызык: кайвакытта олы яшькә җиткән картлар да, шаярып һәм дә гомер иткән карчыгын сынарга теләп, үзләрен шулай «иңдертеп» йөргәннәр. Төмән өлкәсе Вагай районы Күләт авылында Халиков Хәйдәр бабай (1889 елгы) бу турыда менә нәрсәләр сөйли: «Моны ялтир әйтү тиләр. Җегетне көнтес алып кереп таныштырып алатылар. Ваклар җиснә дип килгәч, ул аларга косык (эрбет чикләвеге) өләшә. Кич белән ялтир әйтеп ай әллерләп алып киләләр бичәгә. Йегет пелән кысга аерым чатыр коратылар. Кысны анта саклап утыратылар туслары, җиңгәләре».

Лирик җырлар – Себер татарлары шигъри-музыкаль иҗатының иң зур тармагы. Музыкаль тасвирлау чараларының байлыгы, шигъри нәфислеге белән аерылып торган бу җырларны халыкның эстетик кичерешләре көзгесе дип әйтергә мөмкин. Лирик җырларга киң колачлы аһәң хас. Төрле йола һәм гореф-гадәтләр белән бәйле әсәрләр зур иҗтимагый политик үзгәрешләр аркасында онытылуга таба барган вакытта алар урынын лирик җырлар биләп ала. Җанрлар төрлелеге кимесә дә, «җыр-көйнең халык өчен әһәмияте кимеми. Киресенчә, безнең көннәрдә Себер татарлары музыка хәзинәсенең баюы турында сүз алып барырга мөмкин. Лирик җырлар халык тормыш-көнкүрешенең барлык тармакларына үтеп керә, аның тематикасы киңәя.

Лирик җырларны якынча дүрт төркемгә: сузып җырлана торган ирекле метроритмдагы эпик яңгырашлы озын көйләргә, ирекле метроритмдагы лирик озын көйләргә, төгәл метро-ритмдагы квадрат структуралы җыйнак, кыска көйләргә, ирекле метро-ритмдагы баш өлештән һәм төгәл метро-ритмдагы җыйнак кушымтадан торган озынча салмак җырларга бүләргә була.

Беренче төркемгә Новосибирск өлкәсе Чаны районы Кошкүл авылында Хәбибуллин Кәримулла (1928 елгы), Омск өлкәсе Ишемтамак районы Зур Тибенде авылында Абтюкова Сәлимә (1925 елгы), Саургач авылында Разулев Шәфикъ (1913 елгы),

Төмән өлкәсе Тубыл районы Лайтамак авылында Таҗетдинова Җәмиләдән (1906 елгы) язып алынган «Борынгы җыр», «Туктасын качкы», «Мәхмүт мәргән», «Кара да гына елан» һәм башка җырларны алырга була. Киң эпик яңгырашлы бу җырлар – Себер татарлары иҗатына иң хас үрнәкләрдән. Бигрәк тә бараба татарларының иң күркәм һәм киң таралган «Кара да гына елан» һәм «Асыл кошлар» җырларын һәр җырчы белә диярлек. Ә Казан ягыннан килгәннәре исә «бу инде чын барабалар көе» дип искәртеп куярга онытмыйлар.

Озын лирик көйләр (икенче төркем) – иң күпсанлы төркем. Аларны йөзләп санарга була. Һәм үзенчәлекләрен дә бер-ике үрнәк белән күзаллау һич мөмкин түгел. «Туп-туп баскан туры ат», «Аргамагым», «Агавын» (Бараба татарлары), «Иске пасхуд», «Җиктем күк юрга» (Омск өлкәсе). «Димен лә», «Бадъян баскыч», «Моңлы көй (Том татарлары) җырлары халык телендә бүген дә яши.

Калган ике төркемгә кергән җырлар Себер татарларының һәр этник төбәгенә дә бердәй хас. Шунысы кызыклы: лирик озын көйләргә «Йосыф – Зөләйха», «Бүз егет», «Таһир – Зөһрә» «Сәйфелмөлек» кебек мәгълүм дастаннарның аерым өзекләре дә җырлана. Алар күптән инде мөстәкыйль җыр булып таралып киткәннәр.

Себер татарларының музыка сәнгате тамырлары белән тарих тирәнлегенә китә. Аның нигезләре борынгы төрки телле кабиләләрнең шигъри-музыкаль хәзинәсеннән аерылгысыз. Югарыда әйтелгәнчә, ул гаять катлаулы шартларда барлыкка килгән Себер татарларының үз арасындагы төрле этник төркемнәрнең, бөтен татар халкының, Казакъстан һәм Урта Азия халыкларының музыкаль культурасы Көнбатыш Себер төбәгендә даими бәйләнешкә керәләр. Бу – иҗади процесс.

Кайбер гомумтөрки бәйләнешләрне карап үтик. Менә бараба татарларының тиңдәшсез «Кузы-Көрпәч белән Баян-Сылу» дастаны. «Шигъри хәзинәсендә «Кузы-Көрпәч белән Баян-Сылу» дастаны булган һәрбер халык аны үз әсәре дип исәпли, туган телендә сөйли, милли моңы белән җырлый... Безнеңчә, дастанның

һәрбер милли версиясе һәм барлык вариантлары да бер тамырдан үсеп чыккан, бер тамырдан таралган», – дип яза Ф. Урманчеев[21]. Бу гаҗәеп әсәр халык тормышының үткәнен зур панорама итеп күзалларга мөмкинлек бирә. Дастанның төп эчтәлеге сөйләп, кайбер диалоглары көйләп әйтелә. Ләкин аның әле күптән түгел уен коралына (мәсәлән, «җатыган» дип йөртелә торган кыллы уен коралына) кушылып, көйләп әйтелүендә безнең шигебез юк.

«Хан кызы» җыры, фольклорчыларның билгеләве буенча, бәетләргә керә[22]. Шуңа карамастан «эчтәлеге белән дә, формасы ягыннан да әсәр бәет жанрының башка үрнәкләреннән аерылып тора»[23] икән. Менә шул аерымлыкларын исәпкә алып та, кайбер фольклорчылар «Хан кызы» бәет түгел, җыр дип исәплиләр. Себер татарлары, мәсәлән, Төмән өлкәсе Тубыл районы Лаитамак авылында яшәүче Исәньярова Зинникамал (1927 елгы) «Хан кызы»н җыр дип атый. Аның әйтүенчә, туй мәҗлесләрендә, яшьләрнең аулак өендә ул кара-каршы башкарылган күңелле, шаян җыр икән. Аны кунакларның кәефен күтәрү, китәсе кызның туган өйдән аерылу хәсрәтен җиңеләйтү өчен җырлаганнар. Фольклорчыларның билгеләве буенча, бәетләр – бары тик безнең татар халык иҗатына гына хас жанр. «Башка халыкларда безнең бәетләргә тәңгәл килердәй әсәрләр юк. Дөрес, бәетләр башкорт халык иҗатында да бар. Ләкин, башкорт галимнәренең фикеренчә, алар татар фольклоры йогынтысы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Ә менә Ф. Н. Катановның хакасларда язып алынган фольклор үрнәкләре арасында «Хан кызы» җырының шигъри юлларына тәңгәл килә торган әсәр бар[24]. Үзбәк халкында да шуңа охшаш җырны очратабыз.

[21] Урманчеев Ф. Мәхәббәт дастаны. Кузы-Көрпәч белән Баян-Сылу // Татар әдәбияты мәсьәләләре. КДПИның гыйльми язмалары. №133. Казан, 1974.

[22] Бадыйгый. Халык әдәбияты. Бәетләр. Казан, 1913; Х. Ярминең күрсәтелгән хезмәте.

[23] Урманчеев Ф. Халык авазы. Б. 83.

[24] Катанов Ф.Н. Хакасский фольклор. Абакан, 1963. С. 20, 98.

*Йигит:*

Сочимги узун дейдилар,
Доно укам, ер-ер,
Кора соч укам, ер-ер,
Курсат сочингни, бир курайин,
Жоним укам, ер-ер!

*Киз:*

Сочимни кўриб нима киласиз,
Сиз акажоним, ер-ер,
Жон акажоним, ер-ер,
Бозордаги сочпапукни
Курмабмидингиз, ер-ер!

«Хан кызы» Себер татарларында гына таралган җыр түгел[25]. Мәсәлән, ул Г. Тукайның җырлар дәфтәрендә дә бар (кызганычка каршы, бу көйнең җырлары дәфтәрдән ертып алынган)[26]. Г. Тукай аны җырлар арасына кертә, бәетләр белән бутамый. Әлбәттә, бу кызыклы факт. Менә шуңа күрә дә «Хан кызы»ның яңа вариантларын язып алырга кирәк. Күп вариантларның көй һәм сүзләрен чагыштырып карагач кына, җырның төп функциясе турында катгый фикер йөртергә мөмкин булачак.

Себер татарлары иҗатын өйрәнгәндә, кайбер бәхәсле җырлар да очрый. Мәсәлән, «Тамчы тама» шундыйлардан. Аның көе С. Габәши, В. Виноградов һәм Г. Әлмөхәммәтовның мәгълүм «Эшче» операсындагы Нигъмәт ариясе белән тәңгәл килә. Новосибирск өлкәсе Чаны районы Белекте авылында Йосыпова Шәмсинур (1900 елгы) әйтүенә караганда, көй бу авылда бик күптәннән, «бабайлар заманыннан» билгеле. Көйнең Себердә бик популяр булуын төп Себер татары Таминдаров Сәгыйр дә (1888–1975) раслады. Аның әйтүенчә, Кемерово өлкәсендә яшәүче халыкларда бу җырны нүгәр егетләре кызны егет өенә озатыр алдыннан җырлаганнар. Җыйналган барлык кеше елаган. 1969 елның көзендә, бу җырны ачыклау өчен, махсус рәвештә

---

[25] Бер вариант Н. Мөштәриева тарафыннан Пермь өлкәсендә язып алынган.

[26] Тукай Г. Әсәрләр. Том 2. Казан, 1955. Б. 295.

Кемерово өлкәсе Юрга районы Кышлау авылына керелде (С. Таминдаров исә күрше Эскәтем авылында туган). Авылның иң олы кешесе – 87 яшьлек Шулаяков Гафур бабай бу җырны «Кыз озату җыры» дип яздырды. Яшь вакытта ул аны нүгәр егете булып җырлап йөргән. Димәк, җырның ким дигәндә алтмыш еллык гомере бар. «Эшче» операсы исә 1930 елда сәхнәгә куела. Солтан Габәшинең Нигъмәт ариясе турында язмалары күренми (һәрхәлдә, әлегә табылмаган). Шуңа күрә бу көйне Себер татарларыныкы дип өзеп әйтергә ашыкмыйк. С. Габәши — халык җырларын җыючы һәм өйрәнүче, музыкаль фольклорны гаять тирәннән белүче. Әгәр дә композитор үзе белгән һәм җыйган йөзләгән көйләрнең берәрсен операда файдалана икән, бу профессиональ музыка өлкәсендә табигый хәл санала. Күп вакытта автор көйнең кайдан алынуын да әйтеп тормый. Мәсәлән, Җ. Фәйзи 1952 елда Әлмәт шәһәрендә язып алган «Сагынам» җырының көен «Тапшырылмаган хатлар» операсында Галия ариясендә генә файдаланып калмый, операның төп музыкаль лейтмотивы итә.

Теге яки бу җыр-көйнең таралып китүен алдан әйтү кыен. Алар иң беренче чиратта фән өчен әһәмиятле. Теләсә кайсы халыкның музыкаль-поэтик хәзинәсе – зур культура кыйммәте булган, илебез музыкантлары һәм галимнәренең игътибарын көннән-көн үзенә җәлеп итә торган тиңдәшсез дәүләт милке. Аны мөмкин кадәр югалтмыйча җыю һәм саклау – дәүләт эше. Себер татарлары җыр-көйләрен магнитофон тасмасына яздыруда йөзләрчә җырчылар катнашты. Шулар арасында Нургалиева Вәйдә, Абитов Биктимер, Уразов Зәйнулла, Разулев Шәфикъ, Хәбибуллин Кәримулла, Сөләйманов Имаметдин, Таҗетдинова Җәмилә, Корманов Шәриф, Шулаяков Гафур, Таминдаров Сәгыйр кебек кабатланмас иҗади шәхесләр белән очрашулар күңелдә тирән эз калдырды. Аларның һәрберсе – халык иҗатындагы коллектив башлангычның һәм шул ук вакытта башка җырчыларга караганда чагыштырмача индивидуальләшүнең гүзәл гәүдәләнеше. Үз авылларында гына түгел, ә тирә-якта дан тоткан бу җырчы-музыкантлар социаль әһәмияткә ия булган вазифа үтиләр. Алар – халыкның кадерле мирасы, иң әһәмиятле

милли үзенчәлекләреннән берсе булган музыкасын һәм аны башкару традициясен саклаучы, яшьләрнең тәрбиячесе һәм акыллы киңәшчесе. Музыкантлар һәрвакытта да иҗтимагый тормышның уртасында яши.

Омск өлкәсе Ишемтамак районы Зур Тибенде авылында яшәүче Абитов Биктимер абый татар халык җырларын күп белүе белән безне таң калдырды. Аның башкаруында магнитофон тасмасына кырыктан артык җыр язып алынды[27]. Аңарчы билгеле булмаган «Җиктем күк юрга», «Ямщикәй», «Иске пасхуд», «Сәвә» (кыз исеме), «Уракчы», «Милай Мәхмүзә», «Исәт» һәм башка бик күп җыр-көйләр үзенчәлекле интонацион-лад төзелешләре белән аерылып торалар иде. Биктимер абыйдан язып алынган җырлар тематик яктан гаҗәеп күптөрле: арада тормышкөнкүреш җырлары да, ямщиклар моң-зары, бәет-мөнәҗәтләр дә бар. Иң күбе – мәхәббәт җырлары. Аларга эпик яңгыраш, тирән фәлсәфи мәгънә хас. Биктимер абый бу зур мирасның күп өлешен әтисеннән өйрәнгән. Әтисе Мәлик бабай әйләнә-тирәдә дан тоткан җырчы-ямщик булган. Безне таң калдырганы тагын шул булды: үлем түшәгендә ятканда да, Мәлик бабай җырларын Биктимер абыйга өйрәтеп яткан. Менә кайда музыкаль традициянең көче, менә кайда саекмас чишмәләр!

Себер татарлары музыканы бик яраталар, Сабан туйлары, бәйрәмнәр һәм туйлар оста җырчы, скрипкачы һәм гармунчысыз үтми. Биредә «Тәфтиләү», «Кара урман», «Уел», «Зиләйлүк», «Сарман» һәм башка бик күп җырларыбызны да бик яратып җырлыйлар.

Халыкның җыр-моңы – аның буыннан-буынга тапшырылырга тиешле иң зур хәзинәләренең берсе. Җыры яшәгәндә, халыкның теле дә, мәдәнияте дә яши, димәк, халык үзе дә яши.

---

[27] Мондый феноменнар әкият сөйләүчеләр арасында да бар. Мәсәлән, шул ук районның Эбаргуль авылында 78 яшьлек Хамматов Әхмәт бабай егерме әкият яздырды.

**Кушымта**[28]

## ЙАР-ЙАР

Чыбылдыгым эчентә
Чыбын уйный, йар-йар!
Бескә төшкән кийәүләр
Мулла мигән, йар, йар!
Кара сыер мөгесен
Кайырмагыс, йар-йар!
Заман ахры җиткәнче
Айрылмагыс, йар-йар!
Килер-китәр йулыңа
Киндер чәчтем, йар-йар!
Инде киндер пешкәнче
Килеп китең, йар-йар!




Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Шагыр авылында Садыйкова Сәлихадан (1905 елгы) 1972 елда язып алынды.

---

[28] Бу мәкаләгә бирелгән кушымтада Новосибирск өлкәсендә Илгиз Кадыйров тарафыннан җыелган һәм нотага салынган халык җырларын ноталары белән бирәбез. Алар беренче тапкыр басыла.

**ЙАР-ЙАР**

Шутыр-шутыр камышта
Сыргам тѳште, йар-йар!
Сыналмаган йат җиргә
Сеңлем тѳште, йар-йар!
Үнә күсе сынганда
Улык торган әнекәм,
Үнә сынлы мин киттем,
Инте тынгыл, әнекәм.




Новосибирск ѳлкәсе Чаны районы Кошкүл авылында Мѳхәммәтшин Аллаярдан (1894 елгы) 1968 елда язып алынды.

## КЫЗ ОЗАТУ ЖЫРЫ

Имәнчә туга, көрән ат,
Тартыпы, чай, салар кешеме йук.
Касис ләй башым эшкә төшкәч,
Йолыпы, чай, алыр кешем йук.

Алтын, чай, вийәр[29], көмеш каш,
Китеп лә барай газиз баш.
Китсә лә китсен, әй, газиз баш,
Исән-сау калсын карындаш[30].

Алтын, чай, көмеш – байларда,
Йомырча туйакы – тайларта.
Тай тигәннәрем, әй ат булты,
Үз туганнарым йат булты.




да
Мөхәммәтшин Аллаярдан (1894 елгы) 1968 елда язып алынды.

---

[29] Вийәр – ияр.

[30] Карындаш – бер әнидән туганнар. «Кабы бер – карындаш, атасы бер – авылдаш» диләр барабалар. Атасы бер булса да, инәләре икенче булса, якын саналмаган.

# ТАМЧЫ ТАМА

Тамчы тама, тамчы тама,
Бөркән шәлең тамчий тамгыйнчий.
Мин китәмен йыракъ сәфәрләргә,
Озатып кал күзеңе талганчий. (Соңгы ике юл кабатлана.)

Кыйбла яктин болыты чыгай,
Йавар микән инде күкерәп.
Башларыма төштей зур хәсерәт,
Күтәрәлмий минем күкерәк.




Новосибирск өлкәсе Чаны районы Белекте авылында Йосыпова Шәмсинурдан (1900) язып алынды. 1968 ел.

## КАРАМА ТУГА, КАРА ЙУРГА

Карама туга, кара йурга,
Йургалайтыр кибет алтынтау.
Пуйы ла зифа пер матур кыс
Иркәләйтер йегет алтынта.
Пуйы ла зифа пер матур кыс
Иркәләйтер йегет алтынта.

Карама туга, әй җиз колча[31],
Шыңгыртайтыр тартып йеккәнтәй.
Аузы ла уймак, бите коймак,
Сулкылтайтыр суырып үпкәнтә.
Аузы ла уймак, бите коймак,
Сулкылтайтыр суырып үпкәнтә.

Агыйделнең арйагынта
Селәүчәннәр[32] чыгар уйынгау.
Селәүсен кебек матур йарлар
Кайчан керер беснең куйынга?
Селәүсен кебек матур йарлар
Кайчан керер беснең куйынга?

Һауата очкан ойа лачын,
Ойасынта гөрли күгәрчен.
Шул күгәрченнәр нигә гөрли,
Песнең кебек моңлый, күрәсең.
Шул күгәрченнәр нигә гөрли,
Песнең кебек моңлый, күрәсең.

[31] Колча – кыңгырау.

[32] Селәүчән, селәүсен – бал корты.




Новосибирск өлкәсе Чаны районы Кошкүл авылында Мөхәммәтшин Аллаярдан (1894 елгы) 1968 елда язып алынды.

## БАРАБА ҖИРЕНӘ КҮЧКӘНДӘ

Бийек кенәй кырның, әй, башында
Борлыгадыр богдай орлыгы.
Карындаш тугандин, әй, айырылган,
Әй-хайы гынай дөньяның хурлыгы.

Бараба ла җире – әй, мал җире,
Беснең Сембер җири – ут җири.
Ут җири дә булса китмәс идем,
Бар да бер Ходайның тәкъдире.

Утырдым чананың, әй, төбенәй,
Дилбегәй генәмне кулыма алып.
Өч мең чакрым җиргәй бән барымын,
Әҗәл генәмне кулыма алып.

Өч тубаска[33] йектем, әй, китәргә,
Бараба иленәй җитәргәй;
Туганнарым, әй, китәргәй,
Белмәймен үк, нихәл итәргәй.



Новосибирск өлкәсе Чаны районы Кошкүл авылында Сәлимҗанов Гыйльманнан (1889 елгы) язып алынды. 1968 ел.

Гыйльман абыйның әйтүенә караганда, бу – Себергә күчкән мишәрләр җыры. Авылның Ядүгәр исемле мулласы бөтен бер авылны, үзенә ияртеп, бараба далаларына алып киткән.

[33] Тубаска – повозка.

## ЗӘЙНУЛЛА АБЫЙ КӨЕ

Келүсез йозак һәр киз[34] ачылмас,
Төкәнгән гомерем һәр киз озаймас.
Муйныма таккан кайгу җепләрем,
Текәнеп[35] череп, һәр киз өзелмәс.
Бу гарип күңелем ник кайгы баскан?
Уйнасам-көлсәм, бер киз ачылмас.
Ясин-тәбәрәк һәр дәм[36] телемдә,
Синең сыйфатың һәр киз күңлемдә.
Күңелем туйганчы күрмәгән идем,
Нигә дип әҗәл килде лә сиңа.
Хак Тәгаләмә һәр дәм ялварам,
Кавыштырса иде җәннәттә безне.
Торый күпмегә инде безләргә?
Әҗәлгә бәндә сарасыз түзә.




Новосибирск өлкәсе Чаны районы Тармакүл авылында Ишмакова Нәкыядән (1928) язып алынды. 1968 ел.

---

[34] Киз – вакыт. «Туры килү» мәгънәсендә. «Вакытына киз килдең», «Һәр киз бал булып тормас» дип сөйләшәләр.

[35] Текәнү, төкәнү – киселү, чикләнү, өметсез югалу. «Төкәнгән гомерне ялгый алмассың».

[36] Дәм, тәм – тын, сулыш.

Җырны магнитофон тасмасыннан кәгазьгә төшергәндә, кайбер сүзләрнең мәгънәсен ачыкларга кирәклеге беленде. Шушы максат белән Нәкыя апага хат җибәрдем. Анда бу җырның бараба татарлары арасында кайчандыр таралган булган «җырлап йылау» йоласы калдыгы түгелме икәнлеген һәм кайдан килүен ачыклау мәсьәләсе куелган иде. Җавап түбәндәгечә: «Бу җыр үлгән кешегә багышланган, билгеле. Ләкин безнең тирә татарларында «җырлап йылау» йоласын язычниклар гадәте диләр. Ул юк. Беренче килүчеләр – Сембер губернасы Петрякс авылыннан. Бу җырны чыгаручы – Петрякстан ерак булмаган Куйсуы авылыннан килгән Гөлҗәүһәр әби. Авылыннан чыгып китү вакыты – 1850 еллар».

## «КУЗЫ-КҮРПӘЧ ҺӘМ БАЯН-СЫЛУ» ДАСТАНЫНА НАЗЫМ

*(Кузының әнисе белән диалогы)*

*Әнисе:*

Алай да иттем –
Тыңламадың, балам;
Болай да иттем –
Тыңламадың, балам.
Китәрдәй юлың
Булсын, балам;
Кайтырдай юлың
Булмасын, балам.
Кырның кырык
Аюы чыгар, балам;
Аны ла ничек
Чыгарсың, балам?

*Кузы:*

Кырның кырык
Аюы чыкса, әни,
Угымның бер бүләсе[37]
Шай[38] булыр, әни,
диде ул.

---

[37] Бүлә – пуля, ядрә.

[38] Шай – таман, впору.


«Кузы-Курпяч һәм Баян-Слу»
дастаныннан назым
♪=155
Әнисе: А – лай да ит-тем, тың-ла-ма-дың, ба-лам,
Бо-лай да ит-тем, тың-ла-ма-дың, ба-лам.
Ки-тер-дәй ю-лың бул-сын, ба-лам,
Кай-тыр-дай ю-лың бул-ма-сын, ба-лам.
2нче назым
Кыр-ның кы-рык а-ю-ы чы-гар, ба-лам,
А-ны ла ни-чек чы-гар-сың, ба-лам.
Кузы: кыр-ның кы-рык а-ю-ы чык-са, ә-ни,
У-ены-ның бер бу-ла-са шай бу-лар, ә-ни, ди-де ул.

Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Яркүл авылында Мусина Фатыйма (1900) һәм Рәфикова Хәбибҗамалдан (1899) язып алынды. 1968 ел.

## «МӨЛТӘЛ» ӘКИЯТЕННӘН НАЗЫМ

Җил-җил арбам, җил арбам,
Җиде агайга җитәек,
Җидесен дә күрәек;
Өр-өр, этем, өр, этем,
Бүре килгән – сизәек;
Мыраула, песи, мыраула,
Тычкан килгән – сизәек;
Кычкыр, әтәчем, кычкыр,
Таң-таң атканны сизәек.



## МӨЛТӘЛ

Борын-борын заманда булган, ди, бер ир белән хатын. Аларның булган җиде улы. Сигезенчесе туар алдыннан гына, аталары үлеп киткән, ди.

Җиде егет үсеп җитеп, үзләренә кыз эзләргә китмәкче булганнар. «Их, әни, синең бер кызың да юк, без кыз эзләп кайтыйк. Әгәр син без югында кыз тапсаң, капка башына каба белән орчык куярсың, малай туса — ук белән җәя»,— диләр һәм юлга чыгалар. Болар киткәндә, әниләре бик елап кала. Ә бер атнадан аның кыз баласы туа. Кыз бала тугач, ул шунда ук капка башына каба белән орчык чыгарып куйган, ди.

Аларның күршесендә генә җиде-сигез яшьлек бер кыз яшәгән икән. Шул кызчык каба белән орчык урынына ук белән җәя китереп куйган.

Берзаманны җиде туган әйләнеп кайтканнар, кайтсалар, капка башындагы ук-җәяне күреп, әниебез тагын малай тапкан икән дип белеп, кире киткәннәр, ди.

Әниләре яңа туган кызга Мөлтәл исеме кушкан. Кыз, ай үсәсен көн үсеп, уйнарга әлеге күрше кызы белән чыккан.

Көннәрдән бер көнне күрше кызы әйтә моңа:

– Их, Мөлтәл, йөрисең бер ялгыз, синең бит җиде агаең бар, – ди.

– Каян килсен миңа җиде агай? – ди Мөлтәл. – Юк минем беркемем дә, – ди.

– Ышанмасаң, кайтып әниеңнән сора, – ди күрше кызы.

Мөлтәл әнисенә әйтә:

– Әни, бармыни минем җиде агаем? Кайда йөри алар? – ди. Әнисе әйтми. Шуннан Мөлтәл тагын күрше кызы янына керә.

– Юк минем беркемем дә, мин ялгыз, – ди.

– Алайса, син әниеңнән бодай куырт, шуны кызган килеш күкрәгенә бассаң – әйтер, – ди теге кыз.

Мөлтәл өенә йөгереп кайта да: «Әни, ашыйсым килә, бодай куырып бир әле!» – ди. Әнисенә нәрсә, куыра да бирә. «Юк, ашамыйм, – дип киреләнә Мөлтәл, – имәсем килә!» – ди. Әнисе аны

кочагына алып имезә башлый. Мөлтәл шулвакыт аның күкрәгенә кызган бодай белән баса. «Бармы минем җиде агаем?» — дип аптырата. Әнисе бусында: «Бар»,– дип әйтә. Мөлтәл яңадан күрше кызы янына кереп китә.

– Бар икән минем җиде агаем, – ди.

– Алай булгач, – ди дусты, – сип әниеңнән җил арба ясат. Эт, песи, әтәч алдыр... Җиде агаеңны эзләргә китәрбез, – ди.

Бик сорагач, әнисе җил арба ясап бирә. Эт, песи, әтәч сатып ала. Мөлтәл белән күрше кызы, җил арбага утырып, җырлыйҗырлый китәләр:

Җил-җил арбам, җил арбам,
Җиде агайга җитәек,
Җидесен дә күрәек.
Өр-өр, этем, өр, этем,
Бүре килгән — сизәек.
Мыраула, песи, мыраула,
Тычкан килгән — сизәек,
Кычкыр, әтәчем, кычкыр,
Таң-таң аткан — сизәек.

Шулай баралар болар. Арба йөгерә, эт өрә, песи мыраулый, әтәч кычкыра. Бара торгач, бер күл янына җитәләр.

– Әйдә, су керәбез, – ди күрше кызы.

– Юк, мин кермим, – ди Мөлтәл, – мин болай да таза, – ди.

Тагын торып китәләр. Тагын җырлыйлар:

Җил-җил арбам, җил арбам,
Җиде агайга җитәек,
Җидесен дә күрәек.
Өр-өр, этем, өр, этем,
Бүре килгән – сизәек.
Мыраула, песи, мыраула,
Тычкан килгән – сизәек,
Кычкыр, әтәчем, кычкыр,
Таң-таң аткан – сизәек.

Шулай тагын бер күлгә җитәләр. Иптәш кызы тагын су керергә димли. Мөлтәл бу юлы риза була. Аннан күрше кызы

әйтә: «Әйдә, чумабыз, кайсыбыз су астында озаграк торыр икән», – ди. Мөлтәл ничек тә озаграк торырга тырыша. Ул арада күрше кызы тиз генә судан чыга да, Мөлтәл киемнәрен киенеп, арбага утырып китеп бармакчы була. Җырлый:

Җил-җил арбам, җил арбам,
Җиде агайга җитәек.
Җидесен дә күрәек.
Өр-өр, этем, өр, этем,
Бүре килгән — сизәек.
Мыраула, песи, мыраула,
Тычкан килгән — сизәек,
Кычкыр, әтәчем, кычкыр,
Таң-таң аткан — сизәек.

Тик җил арба урыныннан кузгалмый, эт өрми, песи мырауламый, әтәч кычкырмый.

Мөлтәл, елый-елый, күрше кызы киемнәрен киенә дә арбага менеп утыра.

Җил-җил арбам, җил арбам,
Җиде агайга җитәек,
Җидесен дә күрәек.
Өр-өр, этем, өр, этем,
Бүре килгән – сизәек.
Мыраула, песи, мыраула,
Тычкан килгән – сизәек,
Кычкыр, әтәчем, кычкыр,
Таң-таң аткан – сизәек.

Арба йөгерә, эт өрә, песи мыраулый, әтәч кычкыра. Баралар болар, баралар, бара торгач, жиде агай янына килеп җитәләр.

Бу вакытта аларның кайсы токмач басып, кайсы бәрәңге әрчеп маташа икән. Күрше кызын сеңелләре дип белеп, алар аны күтәреп алалар, үз яннарына утыртып, бик каты сыйлыйлар. Ә Мөлтәлне ишек катына утырталар.

Кич булгач, йокларга яталар болар. Күрше кызы түргә, Мөлтәлне ишек катына гына яткыралар. Төн урталары узгач,

аны ат эчертергә җибәрәләр. Әле таң атмаган. Айның якты чагы. Мөлтәл, җырлый-җырлый, ат эчерә:

Олы агайның атына
Тонык сулар эчерәм,
Уртанчы агай атына
Көмеш сулар эчерәм,
Кече агай атына
Алтын сулар эчерәм.

Аннары, Айга карап:

И Айкаем, Айкаем,
Күрдеңме бәнем әнкәем? –

дип җырлый. Ай аңа әйтә:

Күрдем сәнең әнкәңне
Аяклы келәт алдында,
Ачкычлары кулында,
Эчәдер дә кичәдер,
«Мөлтәл» диеп елыйдыр, – ди.

Бер агасы моны чыгып тыңлап торган була. Ул, кереп, туганнарын уята да: «Әйдәгез әле, чыгыгыз, күл буенда кемдер бик моңаеп җырлый»,– ди. Шуннан чыгып тыңлап торалар:

Олы агайның атына
Тонык сулар эчерәм,
Уртанчы агай атына
Көмеш сулар эчерәм,
Кече агай атына
Алтын сулар эчерәм...
И Айкаем, Айкаем,
Күрдеңме бәнем әнкәем?

Ай бу юлы да:

Күрдем сәнең әнкәйне
Аяклы келәт алдында,
Ачкычлары кулында,
Эчәдер дә кичәдер,
«Мөлтәл» диеп елыйдыр, – ди.

Җиде агайның җидесе дә Мөлтәлдән:

– Нигә болай моңланасың? – дип сорыйлар.

Мөлтәл, үкси-үкси, барысын да сөйләп бирә.

– Мине күрше кызы алдады, минем киемнәрне киенеп, хәзер сезнең сеңлегез булып утыра, – ди.

Абыйлары сеңелләрен күтәреп кайталар да күрше кызына, сынар өчен, эт савытына аш салып бирәләр. Ул аны шунда ук ашап куйган, ди. Төн урталары узгач, күрше кызын ат эчертергә җибәрәләр. Су буена барса, атлар эчми, тибешәләр генә, ди. Ай да күренми, ди. Көйләп карый, көе дә килми, ди.

Шуннан соң җиде агай киләләр дә моның Мөлтәл түгел икәненә ышанып: «Сиңа ат койрыгы кирәкме, орлык тубалы кирәкме?» – диләр. «Ничек тә ярый, орлык тубалыннан орлык ашармын, ат койрыгына атланып чабармын», – ди хәзер теге. Алдакчы кызны орлык тубалына салалар да ат койрыгына тагып, куып җибәрәләр.

Җиде агай, сеңелләре Мөлтәлне ияртеп, әниләре янына кайтып төшәләр, ди. Җидесе дә өйләнеп, сеңелләрен кадерләп, әниләрен сөендереп, баеп-бакшып әле дә шулай яшәп яталар, ди.

Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Яргуль авылында Тимганова Талигадан (1912 елгы) язып алынды. 1968 ел.

## АК ТӘВӘЛӘР[39]

Ак тәвәләр килә бит, әй, бузнашып,
Путалары калгандыр бәйләнеп. }ике кат
Ак тәвәләр кебек бузнасак та,
Үткән гумер килмәс бит әйләнеп.

Ак күбәләк очадыр, әй, яз көне,
Сары чәчәкләрдән лә йем эзләп. }ике кат
Сары чәчкә кебек яшь гумерне
Табып пулмай, тусларым, йыл эзләп.

[39] Тәвә – дөя.

Кәнәферләр ачы ла, бадиян төче,
Бакчаларда үсәдер сусамый. }ике кат
Үткән гумерләрем исемә тушсә,
Янып ук китә йөрәгем, түзәлмый.



Новосибирск өлкәсе Чаны районы Тармакүл авылында Нургалиева Вәйдәдән (1898 елгы) язып алынды. 1968 ел.

Җырны Тармакүл авылының Фәннән атлы кешесе чыгарган. Ул 1845 еллар тирәсендә туган булырга тиеш. Бу турыда безгә Ишмакова Нәкыя апа сөйләде.

## ХӘНДЕЛДӘ[40] ШӘМНӘР ЯНАДЫР

Хәнделдә шәмнәр янадыр,
Тарма-тарма мае тамадыр.
Озын ла керфек сиксән бөртек
Мөбәрәккәй йөсен ятадыр.

Ыстаканның төпләре –
Күк күгәрчен кошның сөтләре.
Эчегез, байлар, ашагыз, байлар –
Без бәхирнең күкрәк көчләре.

Җирәнчәнкәй атым койрыгын
Кыйблалардан искән җил тарый.
Үз бәхеткәйләрең булмагач,
Байга хезмәт итеп кем ярый.




Новосибирск өлкәсе Чаны районы кошкүл авылында Хәбибуллин Кәримулладан (1918) язып алынды. 1968 ел.

[40] Хәндел – кәндил, берничә шәм куела торган зур шәмдәл.

## МӘКӘРҖӘ

Әй, дускаем, сиңаниләр бирим,
Мәкәрҗәдин килгән ләй малым йук.
Яннарымны ярып бирер идем,
Яндай башкай йәшәр ләй хәлем йук.

Башкаеңай кигән түбәтәең,
Укаларын салып лай кем уйган?
Акылларың камил, буең зифай,
Исем шәрифләреңне кем куйган?



Новосибирск өлкәсе Чаны районы Тармакүл авылында Сиражетдинов Давыттан (1899) язып алынды. 1968 ел.

1940 елда шагыйрь Мөхәммәт Садри Тел, әдәбият һәм тарих институты һәм Казан музыка фольклоры кабинеты оештырган экспедиция вакытында Давыт абый Сиражетдиновтан «Карчыга», «Камыш» җырларын язып алган.

Бу җырларның текстлары Мөхәммәт Садри төзегән «Иртешкә сәяхәт» (Казан, 1989. Б. 120,122) һәм ноталары Александр Ключаревның «Татар халык җырлары» (Казан, 1955. №110, 112) китапларында урын алган.

## ТУЙ-МӘҖЛЕС ҖЫРЛАРЫ, КЫСКА ҖЫРЛАР ТЕКСТЛАРЫ

Ат җиксәң, бик тартма,
Дилбегәсен бик какма.
Ят баласын алдым, диеп,
Яфрак кебек саргайтма.

Башыңдагы түбәтәең
Тәңкәләрдән түгәрәк.
Кашың-күзең, ай, мубәрәк,
Йөзең айдин түгәрәк.

Алтын була, көмеш була
Тегүчеләр кайчысы.
Сөйгән ярлар бик күп була,
Мәхәббәтсез кайсысы.

Ай янында якты йолдыз
Кереп кача болытка.
«Син – минеке, мин – синеке», –
Дигән сүзне онытма.

Арамсаз белән Шагыр арасы тарма-тарма агач булган. Арба белән йөреп булмаган. Кысны алып киткәнтә, махсус иярле ат белән алып китәтеләр. Ияр өстенә чатыр кебек нәрсә коратылар, кеше кысны күрмәсен дип. Кыс куштырып китепте алар.

Яңгыр явып җир тулмас,
Асыл кош талга кунмас;
Асыл коштай туганнарым
Аерылгач, янда булмас.

Яңгыр ява, яңгыр ява,
Шомарлана[41] бос була.

[41] Шомарлану – йомарлану.

Йегет сөйсә – үзе сөйсен,
Кызлар сөйсә – назлана.

Кисәм дә тар, салсам да тар
Ак сатин күлмәккәем.
Сөйсәм – ерак, ташласам – жәл,
Өзелә үзәккәем.

Сарат[42] алдым, сарат салдым,
Сарат салкын алсын дип.
Чит илләргә чыгып киттем,
Башым гыйбрәт алсын дип.

Бөгелмәле, сыгылмалы
Тугалары бар әле.
Кара кашлы, кара күзле
Сөйгән ярым бар әле.

Тәрәз төпкә ак кар яуган,
Килмә, дустым, эс итеп.
Син килерсең дуслар итеп,
Дошман сөйләр сүс итеп.

Җилләр исә, леп-леп итә
Тәрәсәнең пәрдәсе.
Ходай кушса кавышырбыз,
Без дә Ходай бәндәсе.

Аклы күлмәк – ак бит ул,
Кесәсендә хат бит ул.
Иске дуслар истин чыкмый,
Яңа дуслар ят бит ул.

[42] Сарат – сары ат.

Алма бирдем – алмадың,
Тәңкә бирдем – сайладың.
Түшең киереп йөри итең,
Әллә кемгә барматың.

Ал яулыкны күк яулыкка
Әллә алыштырыйкмы?
Күзне күзгә тилмерткәнче,
Әллә кавыштырыйкмы?

Алмалар ашыйм микән лә,
Карбызлар башлыйм микән?
Шушы янган йөрәгемне
Өзгәләп ташлыйм микән?

Кулымдагы балдагымның
Исеме Зиннәт кенә.
Минем сиңа кушылуым
Дусларым димләп кенә.

Пароходны күрсәң иде
Суларда әйләнгәнен.
Чәчләремне белсәм иде
Кемнәргә бәйләнгәнен.

Ай яктысы, ай яктысы,
Яртысы кар яктысы.
Сине уйлап үтәр инде
Гомеремнең яртысы.

Биек тауга менмә, дустым,
Биек тауда – җил, давыл.
Уртаклаш хәсрәткәемне,
Ялгыз үземә авыр.

Арьяктин берәү килә,
Кәнфит ашыйсы килә.
Агач башлары яшәрсә,
Илемә кайтасы килә.

Магнитның тәгәрмәчләре
Ник сигез булмадикән?
Бу дөньяның рәхәтләре
Ник тигез булмадыйкән?

Аклы ситса күлмәк киеп
Сипарат әйләндерә.
Бер сөям дип, бер сөймим дип,
Башымны әйләндерә.

Кыйбла яктин искән җилләр
Бөгелдерә каенны.
Нинди шатлыклар булса да
Тараталмый кайгымны.

Айкаламы күлегез,
Чайкаламы күлегез?
Кайсы йондыз турысында
Тора торган илегез?

Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Шагыр авылында Садыйкова Салихадан (1905) язып алынды. 1972 ел.

# ӘЙТҮКӘ

*Илгиз Кадыйров*

Көнбатыш Себер территориясендә яшәүче бараба татарларында атаклы «Кузы Көрпәч һәм Баянсылу» дастаны, шулай ук «Асыл кошлар», «Атавын», «Кара да гына елан», «Кияү типсәү» кебек искитмәле җырлар белән беррәттән, Әйтүкә атлы җырчы егет исеме белән аталган тарихи җыр да бик кадерләп һәм сөеп саклана.

Тырыш һәм курку белмәс Әйтүкәнең (тулы исеме Әйтмөхәммәт) Фатыйма атлы сөйгән кызы була. Әйтүкә аны, иркәләп, Батыш дип йөртә. Фатыйма – бай кызы. Әйтүкә исә – ярлы карчык улы. Фатыйманың әтисе үз кызын бай егетенә бирергә тели. Әмма мәхәббәткә киртәләр юк...

Мин бу тарихи җырны 1969 елның сентябрь аенда Новосибирск өлкәсенең Чаны районы, Тармакүл авылында Рәйдә Нургалиева (1899 елгы), Нәкыя Ишмакова (1928 елгы), Белекте авылында Зәйтүнә Хәсәновадан (1928 елгы) язып алдым.

**Әйтүкәнең беренче җыры**

И... Кызылгат[1] дигәне, ай, җимешнең
Этче генә ташылы, тышы татылы.
Минем дә генә сөйгән шулы Батышның[2]
Күңеле каты, теле татлы.

[1] **Кызылгат** — бөрлегән.

[2] **Батыш** – чын исеме – Фатыйма.

И... Йөгерә-йөгерә җитә алмыйм,
Тал-читәннәрдән үтә алмыйм.
Тал-читәннәрдән үтәр идем,
Сине лә ташлап китә алмыйм.

И... Суда ла йөзгән, ай, балыкны
Баласын әйтегез култан[3] диеп.
Акча ла бирмәй ярны сөйгән
Әйтүкәне әйтегез солтан диеп.

И... Ябышкан[4] буе ярлар микән,
Барып ла күргән барлар микән?
Ярны лай сөеп мәхрүм калган
Бу дөньялыккайларда барлар микән?

И... Ябышкан буе әй ком такыр,
Алтын ла акча булмас бакыр.
Сагындым лай, дуслар, бик сагындым,
Кайтып ла булмас илгә, ахыры.

И... Утыр ла ялган, бутыр ла ялган,
Бу ялганлардин кемнәр үк калган.
Бу ялганнарда барлар микән
Сөйгәнен алып ла мәйре лә калган.

И... Ат бәйләгән кубаныкка,
Шәм бәйләгән туганыкка.
Карап кына торып исем китте
Алтын ыштоп укалы якалыкка.

---

[3] Култан – кечкенә балык.
[4] Ябышкан – күл исеме.

### Зәйтүнә Хәсәновадан язып алынган өлеше

И... Буйны ла озын әй бус торына
Әллә нигә төрле бузнайтор ла.
Уйны[5] ла йөрдем, кырны ла йөрдем,
Мөкәтдәр[6] дә язмыштин узмайтор ла.

И... Әтерне[7] лә тарытып укылар атытым
Кырда гына йөргән кийекләргә.
Газиз генә башны хурлар кыйлып
Дуып калыпсың кийекләргә.

И... Ябышкан буе ярлар мигән,
Барыпчылар күргән барлар мигән.
Газиз генә башны хурлар кыйлган
Җан сөйгән матур ярлар микән.

И... Иртә тә буран, кич тә буран,
Тармаклы буен алган ла сырау[8].
Шул җаныемны уйлай-уйлай,
Сау гына башым булды ла сырхау.

### Дастаннарга тиң мәхәббәт

Әйтүкә, – дөрестән дә, Тармакүл авылында туган кеше. Ләкин ул вакытта әле Тармакүл исеме бирелмәгән булган. Аның әнисе Карлыгаңсылу исемле була. Бу ялгыз бер карчык улы Әйтүкә белән генә Тармакүл авылының Зур күле тирәсендә яши торган була. 1803 елларда туган булырга тиеш. Ятим калган Әйтүкә көтүче булып йөри. Бик матур йырлый, курайда уйный торган була. Үсә, зур була. Үсеп җиткәч тә, шул ук көтүчелек хезмәтен күрә. Бер вакытларны кыш көне, бу вакытта инде мәчет салынып

[5] Уй – уйсулык.
[6] Мөкәтдәр – язмыш.
[7] Әтер – җәя.
[8] Сырау – кар басып китү, көрт өю, сырып алу.

Тармакүл авылына, яшьләр шул тирәгә уйнарга цыга торган булалар. Айлы бер төнне мәчет янында ураза вакытында очрашалар болар Батыш белән. Беренче мәртәбә алар бер-берсенә кар бәрешеп уйныйлар. Менә шул вакытларда беренче аның яратуы. Болар бер-берсен яратышалар. Ләкин Батышның бай абзыйлары, эти-энисе ярлы карчыкның улына кызларын бирергә риза булмыйлар. Алар аны Тамтау авылының Бауычат исемле баена ярәшәләр. Туй әйтелә, туй салалар. Килешәләр. Туй көтелә. Менә бу көннәрнең берсендә сөйгән кызы Батышны Әйтүкә урлап китә. Риза булалар. Биясе була. Менә болар Иртышка таба, казакъ ягына китәләр. Юлда Иртышка җиткән вакытта боларның бияләре колынлый. Әйтүкә арттан куып килүләрен сизә торган була. Шуңа күрә аңа тизрәк китәргә кирәк. Ул колынны нишләтергә белми аптырый. Менә бу вакытта Батыш әйтә: «Без аны бугазлап калдырыйк», – ди. Әйтүкә бик нечкә күңелле кеше була. Ул бик жәлли хәзер генә дөньяга килгән колынны бугазлап калдырырга. «Арбага салып кына алып китик», – ди. Батыш: «Авырлыгы бар, куган-килгән вакытта, безгә тизрәк китәргә кирәк», – дип риза булмый. Менә шулвакытта Әйтүкә җырлый.

Аннан соң болар Иртышның аръягына чыкмыйча, Иртыш буйлап казакъ далаларына китәләр. Павлодарга җитмичә туктыйлар. Нindiдер бер яр сыман урын була. Күле дә юк, суы да юк, үзе ярга охшаган. Менә шул тирәдә туктыйлар болар. Агачлар була бик матур тезелеп үскән. Боларга инде халык арасына барырга ярамый, чөнки болар, яшеренеп йөри торган кешеләр. Бу Батышны биредә калдыра, үзе якын-тирәдән казакъ авылларын эзләп китә. Барып, бер казакъ баен таба. Шул казакъ баеның малын көтәргә ала. Ул шунда тагын көтүчелек хезмәтенә керешә. Биредә ул өч ел яши. Батыш бик уңган хуҗабикә булып чыга. Бакча да утырталар, карбыз да үстерәләр. Әйтүкә бирегә кое казый. Ул кое һаман да бар. Хәзер дә булырга тиеш. 1933 елларда әле аннан су алып эчә торган булганнар. Урыслар ул коены «Айтикин колодец» дип атыйлар. Билгеле, теге коры казакъ даласында бу коеның булуы юлаучыларга бик уңайлы булып китә. Соңыннан әнә шул Павлодарга үтә торган юлаучылар туктый торган булалар. Биредә

болар өч ел гомер итәләр. Әйтүкә сагына. «Илгә кайтырга», – ди. Батыш кайтмаска итә. Әйтүкә: «Кайтыйк», – ди. Шулай итеп болар бу якка таба килеп чыгалар. Ләкин ул Тармакүлгә дип килми. Бу тирәне күреп үтеп, әнисенең исәнлеген генә белеп, соңыннан икенче бер якка китәргә уйлаган. Ул шулай туры килми. Белекте авылында Кечек исемле кенәз була. Шул кенәзнең улы Раймбака көтмәгәндә генә боларны Белекте тирәсендә очрата. Атының башыннан тотып ала да биредә Тармакүлгә алып килә инде. Аны бик күп эзләгән, таба алмаган булганнар. Бласларга хәбәр ителгән була. Чөнки Әйтүкә – ул халык өчен бик хезмәт иткән кеше. Бу вакытларда әле, Әйтүкә биредә вакытта, барабалар түләүне бирә торган булганнар тоткан сунарлаучының тиресе белән. Натурадан түләтә торган була. Ә менә бу натурадан түләүне акчага күчерергә килә бер вакытны. Биредә инде халык үзенә җиңелрәк булган, өйрәнгән натурадан түләүне яклыйлар. Ә бласлар решать итәләр, обязательно шуңа күчәргә, дип. Шул шаукым чыккан вакытта, Әйтүкә беренче булып сүз кузгата. Әйтүкә артыннан бөтенесе дә оешкан хәлдә моңа каршы чыгалар. Бу билгеле була бласларга. Бласлар моны халыкны оештыручы, котыртучы кеше иттереп күрсәтәләр, һәм аны төрмәгә дә алган булалар. Качып киткәнгә кадәрле. Ул Каинаский төрмәсендә утырган була. Суд та булмый, сорау да булмый. Озак вакытлар утыра. Менә шул утырган вакытында җир астыннан гына чыккан тәрәзәсе була, кич шулай ул моңланып кына Әйтүкә җырлап утыра торган була. Менә аның җыр тавышын тагын да төрмә тирәсеннән үтеп бара торган губернатор булгандыр ишетә. Ул хатыны белән прогулкага чыккан була. Шул кешеләр аптырап туктыйлар бу тирәгә: «Бу нинди матур тавыш?» – дип. Аннан соң төрмә сакчысыннан: «Теге кешене күрсәтегез миңа, шул кешене», – ди. Шул кешенең янына әллә алып чыгалар моны. Шул вакытта бу әйтә. Хатыны сорый: «Без үтеп барганда җырлаган җырыгызны бер мәртәбә җырлап күрсәтегез әле», – ди. Бу инде хәзер аларга үзенең җырлаган җырын җырламый, ә тегеләргә карата чыгарып җырлый. Аннан теге кеше сорый: «Русчага әйләндереп хәзер миңа җырлап күрсәтә алмассызмы бу җырны», – ди. Русчага әйдәндереп

җырлый. Аннан соң: «Чыгарыгыз бу кешене биредән», – ди. Шунда ук чыгартып калдыра. Менә шулай итеп, ул авылга кайтып килгән булган.

Хәзер бласлар белән дә әзрәк каршылыклары булган кеше икәнлеген белгәннән соң, байның алар ярәшелгән кызын алып киткәненнән соң, билгеле, материаллар күп кенә җыелган була. Менә хәзер моны инде законлаштырып шул судить итәргә әзерләнеп торалар.

Алып киләләр бирегә. Батышны абзыйларына бирәләр. Әйтүкәне ябып куялар.

Мулла казакъ арасына киткән була берничә көн мулланың килүен көтәләр. Мулла килми. Биредә байларның моннан тизрәк үч аласылары килә. Җыелалар барлык байлар. Җыялар халыкны. Килеп җитә әнә шул Тандау авылыннан Бауычак бай. Биредә, мәчет алдында, үзләренчә суд ясарга җыеналар. Менә шунда решать итә байлар, аларның кыска була инде судлары: «Йөз камчы сугарга!»

Әйтүкә: «Мин элек шуннан алда сезгә әйтәсе сүзләремне әйтеп калыйм», – ди. Менә хәзерге бу мәчетне төзергә дип бүрәнәләре, агачлары хәзерләнеп өелеп куелган була. Шул бүрәнәләр өстенә утырып, ул үзенең җырларын җырлый. Халыкның әйтүе буенча, ул вакыттагы аның җыры йөз угыз җыр була. Мин кечкенә вакытта сиксәнен белә дип ишетә идем. Ә хәзер инде алар бик азайган.

Җырларын җырлап бетерә ул. Кояш байый. Иртәдән башланган әйбер. Халык бирми аны суктырырга. Ә Батышны алып китәләр. Бауычак бау Тандау авылына. Менә ул анда сөргендә йөргән кебек йөри инде. Алып бара, сарыклар көтәргә куя. Сарыклар белән бергә яши торган була. Хәзер анда Батыш дигән бик матур түгәрәк күл бар. Шул күл тирәсендә көтә торган була ул сарыкларын. Ул бик матур, бик оста биюче, бик оста җырчы була.

Күп еллар үтә. Әйтүкә Тармакүлдән китеп кала. Әйтүкә Тармакүлгә килгәндә, шул 50 яшьләр тирәсенә җиткән кеше була инде. 1848 елларны Әйтүкә үлә. Әйтүкә үлеп өч ел булганнан соң, Батыш Тармакүлгә кайта. 1851 еллар була.

Бервакытны минем әбиемә 12 яшьләр тирәсе була. «Дөрестән дә, син Әйтүкәгә гашыйк булган идеңме?» – дип сорый. «Яткан йөрәкне нишләп кузгаттың», – дип җавап бирә Батыш, һич бернинди сүз әйтми. Кич яткан кеше, төне буена күзенә йокы алмыйча, иртәнге таңны шулай аттыра.

Әйтүкә үлә. Әйтүкәне күмгәнне Хөснетдин карт күрмәгән. Батыш озак еллар яши Әйтүкәдән соң. Картаеп үлә. Батыш үлгәннән соң кабер казыган вакытта, бер кабер килеп ачыла. Шул. «Хәзер инде күмәргә ярамый биредә, кабер ачылды». Бу кемнең кабере булырга тиеш?» – дип киләләр муллага. Мулла барып күргәч, Әйтүкә кабере. «Чын гашыйк булганнар икән, ярар, бирегә үк күмәргә кирәк», – дип, икесен бергә күмәләр.

Теге сораган вакытта, Батыш болай әйтә: «Безне аерган Бауычак әллә кая китмәгән, кабере белән купкан. Каберенең өстенә бер үлән дә үсмәгән», – ди».




Хикәят Нәкыя апа Ишмакова сөйләвендә язып алынды.
Җырның нотасы Рөйдә Нургалиева көйләвендә бирелә.
Нотага салучы һәм эшкәртүче – Илгиз Кадыйров.

# ЭТНОМУЗЫКАЛЬНЫЕ ТРАДИЦИИ ТАТАР НОВОСИБИРСКОЙ ОБЛАСТИ

*Неля Нургаянова*

Значимая роль в культурном наследии каждого народа принадлежит этномузыкальным традициям, являющимся отражением его исторической памяти испытанной мудрости, важной предпосылкой для сохранения самобытности и развития национальной культуры.

В настоящее время татарское этномузыкознание стремится рассматривать татарскую музыкальную культуру как синтез регионально-диалектологических компонентов различных этнографических и локально-территориальных групп, что определяет необходимость восприятия татарского музыкального фольклора как неоднородного явления. Изучение национально-культурного наследия разных этнографических групп татарского народа, их межкультурного взаимовлияния, а также взаимодействия с соседними этносами всегда вызывало особый интерес многих российских и зарубежных ученых, этнографов, исследователей-фольклористов и педагогов.

Особый интерес у исследователей на сегодняшний день вызывает традиционная культура сибирских татар, расселенных на обширной территории, коренных жителей Западной Сибири.

В научной литературе, исходя из исторических, этнографических и лингвистических аспектов, сибирских татар подразделяют на этнические группы – это томские, барабинские, тоболо-иртыш-

ские, тобольские, тюменские, ишимские, тарские, тевризские, туралинские, туринские, чулымские, калмакские, заболотные и др. татары, которые также в свою очередь также делятся на подгруппы. Принятые в литературе данные названия групп сибирских татар зачастую связаны с местом их постоянного проживания.

Географические условия проживания представителей разных сибирско-татарских этнических групп обусловили некоторые отличия в сферах быта, материальной и духовной культуры, хозяйственной деятельности, также имеются диалектные особенности в разговорном языке.

Экспедиционные исследования разных лет показывают, что музыкальный фольклор татар, проживающих на территории Сибири, представляет собой многообразное явление. Здесь присутствуют образцы деревенского песенного фольклора, детского фольклора, протяжные, лирические и короткие песни, такмаки, частушки, обрядовые, свадебные напевы, жанры распевного чтения, эпические произведения, баиты и мунаджаты, которые еще сохраняются в памяти людей старшего и среднего возраста.

Регулярные экспедиции в Новосибирскую, Омскую, Томскую, Иркутскую, Тюменскую области, осуществляемые сотрудниками Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан, учеными Казанского федерального университета способствуют выявлению и накоплению сведений об истории, языке, искусстве, фольклоре, музыкальных традициях различных групп сибирских татар.

В 1940 году в процессе комплексной экспедиции с участием Х. Ярмухаметова, М. Садри и др. в Сибири были записаны на фонограф более восьмидесяти образцов музыкально-поэтического творчества от барабинских, тарских и тобольских татар. Часть собранных материалов композитор А.С. Ключарев впервые включил в нотные сборники татарских народных песен, что значительно обогатило представление о стилистике и географии распространения татарского народного фольклора.

Образцы сибирско-татарских песен и инструментальных наигрышей также представлены в нотных сборниках М.Н. Нигмед-

зянова, Л.Р. Сурметовой, Н.С. Капициной и др., информация об эпических традициях отображена в трудах филологов Ф.В. Ахметовой, Ф.В. Урманчеева и др., сведения о музыкальных инструментах содержатся в искусствоведческих исследованиях Ш.К. Монасыпова и др.

В статьях музыковедов Л.Р. Ильясовой, И.Ш. Кадырова, З.Н. Сайдашевой, Е.М. Смирновой и др. характеризуются основные жанры музыкального фольклора разных групп сибирских татар, рассматриваются интонационно-ладовые и звуковысотные особенности напевов, выявляются их параллели с различными тюркскими культурами, в том числе с культурой татар Волго-Уралья.

В последние десятилетия появились диссертационные работы, отражающие музыкальные традиции отдельных этнографических групп сибирских татар. Жанровому своеобразию песенно-музыкальных традиций татар Тюменской области посвящено исследование Л.Р. Сурметовой[1].

Интересные сведения о песенных традициях чатских татар представлены в диссертации Н.С. Капицыной[2], в которой отражены материалы музыкально-этнографических экспедиций, проводившихся с 1999 по 2002 годы сотрудниками и студентами Новосибирской государственной консерватории (академии) им. М.И. Глинки. В ходе полевых исследований была собрана аудиоколлекция из 272 образцов музыкального фольклора разных жанров от тридцати двух обско-чатских исполнителей, которые легли в основу описания культурного контекста песенных традиций.

Комплексная экспедиция ИЯЛИ АН РТ 2017 года охватила три района Новосибирской области: Колыванский, Каргатский, (деревни Юрт-Ора, Юрт-Акбалык, Казанка, Мусы, Теренино

---

[1] Сурметова Л.Р. Жанровое своеобразие песенно-музыкальных традиций татар Тюменской области: автореферат дисс.... канд. филол. наук, 2007, 33 с.

[2] Капицина Н.С. Песенная традиция чатов: автореферат дисс.... канд. искусствоведения, 2011, 26 с.

(Жәйләу), Шибаки (Кышлау), Форпост-Каргат, в том числе и места обитания чатских и барабинских татар.

Несмотря на то, что в формировании музыкальных представлений современного населения большое влияние оказывают средства массовых коммуникаций, радио и телевидение, в селах Новосибирской области еще сохранились носители татарского музыкального фольклора.

В результате исследования был зафиксирован разнообразный и интересный, в некоторой степени оригинальный фольклорно-этнографический материал, включающий песни, инструментальные наигрыши, а также комплекс жанров традиции распевного чтения (көйләп уку). Были записаны образцы татарской народной музыки, музыкально-поэтические произведения, песни татарских композиторов, получены сведения о молодежных посиделках, играх, обрядах, праздниках, сделаны аудио- и видеозаписи, фотоснимки.

Известно, что пение – один из самых доступных видов народного творчества, поэтому практически во всех традиционных музыкальных культурах песенное творчество занимает центральное место и является активно функционирующим. Песни могут исполняться как отдельными солистами, так и коллективно, иногда в сопровождении музыкальных инструментов.

Песенное исполнительство у сибирских татар широко распространено и занимает важное положение в традиционной культуре локальной субэтнической группы. Песенная традиция татар Сибири обозначается термином «йыр», «йер» (җыр) – песня или «көй» – напев, мелодия, и в настоящее время включает жанры, характерные для татарской музыки в целом: «озын көй» (протяжный напев), «кыска көй» (короткий или скорый напев), «авыл көе» (деревенский напев), «урам көе» (уличный напев), «мәҗлес көе» (застольные), гостевые, «кодалар көе» (песни сватов), «уен көе» (игровые напевы), такмаки, частушки, лиро-эпические жанры и т.д.

М.Н. Нигмедзянов в сибирских напевах прослеживает связи с казахской и даже узбекской музыкой. Они характеризуются

диатоничностью, широкими мелодическими интонациями, суровостью общего колорита[3].

Среди носителей песенных традиций особо выделяются исполнители, имеющие зычный голос, знающие большое количество мелодий и текстов песен. Такие народные певцы всегда пользовались большим уважением односельчан и были непременными участниками знаковых событий жителей села, их приглашали на свадьбы, посиделки, праздничные застолья и т.д.

В Колыванском районе Новосибирской области членам экспедиции удалось прикоснуться к традиционной культуре одной из диалектных групп томских татар – обских чатов, проживающих в деревнях Юрт-Ора и Юрт-Акбалык.

Деревня Юрт-Ора расположена на месте традиционного, начиная с VIII века, проживания сибирских татар и представляет собой сочетание исторического, этнографического и археологического культурного наследия. На территории села находится древнее городище с зоной культурного слоя, позволяющее говорить об уникальности поселения, а также о его значении для изучения истории и культуры сибирских татар.

Чаты – представители восточной группы сибирских татар, проживающих в Томском районе Томской области и в Колыванском районе Новосибирской области. Язык томских татар входит в кыпчакско-булгарскую подгруппу кыпчакской группы тюркских языков[4].

Исламская религия является идентификационным знаком татарского народа, идейной опорой сохранения его исторической и духовной самобытности. Ислам – религия с развитой письменной культурой, предписывающая своим последователям стремиться к знаниям. Несмотря на то, что в советский период существовал идеологический запрет на изучение явлений культуры и искусства, связанных с религиозным мировоззрением, у пожилых сельских жителей сохранились рукописные тетради и печатные сбор-

ники молитв на арабском языке, отдельные суры и аяты Корана, хадисы, брошюры с разъяснениями религиозных обрядов, тексты мунаджатов и баитов. Поэтому сохранение арабографичных книг, как религиозного, так и светского содержания, их рукописных и печатных вариантов, несмотря на запреты и уничтожение в разные исторические периоды, является наиболее существенной приметой татарской народной культуры[25].

Из бесед с жителями татарских деревень Новосибирской области удалось выяснить, что ранее пожилые люди владели традицией распевного чтения (китап көйләү), знали религиозные песнопения, читали Коран («Коръән укыдылар»), сказывали баиты, мунаджаты, но сейчас почти никого не осталось.

Многие информанты высказывали сожаление, что в молодые годы не думали об изучении религиозно-дидактических книг и не придавали значения необходимости овладения навыками распевного чтения. Да и в советские годы антирелигиозная пропаганда не позволяла открыто исполнять духовную музыку различных конфессий, в том числе и мусульманских жанров.

Однако в настоящее время образцы книжного пения активно исполняются в период мусульманских праздников, на встречах родственников, во время поминовения усопших.

В татаро-мусульманской культуре к традиции книжного пения музыковеды относят не только чтение книг нараспев, но и интонирование баитов и мунаджатов. В основе каждого из этих, обладающих своей спецификой, жанровых разновидностей музыкально-поэтического творчества, исследователи отмечают комплекс типологически родственных элементов: письменный текст, часто нравоучительного, дидактического характера, арузная метрика[26], формирующая мелодику речи, монодийный характер чтения, как правило, лишенного сопровождения[27].

---

[25] Сайфуллина Г.Р. Музыка священного слова. Чтение Корана в татаро-мусульманской культуре. Казань: Изд-во Татполиграф, 1999. С. 67.

[26] Аруз – система метрического стихосложения, которая основывается на чередовании долгих и кратких слогов.

[27] Сайфуллина Г.Р. Музыка священного слова... Казань, 1999. С. 68.

Близко стоящим к религиозной книжности и распространенным среди татар-мусульман является духовный жанр – мунаджат. Это один из древнейших жанров народного музыкально-поэтического творчества лиро-эпического, лирико-философского и лирико-драматического характера.

Ученые отмечают тематическое разнообразие поэтических текстов мунаджатов, проводят классификацию этого жанра. Одна часть включает мунаджаты-славления – это зикры, салаваты, эльвидаги и т.д., воспевающие Аллаха, мусульманскую религию, пророка Мухаммеда, святых; а также мунаджаты-обращения к Аллаху с просьбой о помощи, милосердии; ритуальные мунаджаты, исполняемые во время религиозных обрядов и праздников. Другая часть включает мунаджаты-размышления о смысле жизни, о загробной жизни, о смерти и бессмертии. Важное место занимают ностальгические мунаджаты о разлуке с Родиной, родными, друзьями; мунаджаты-жалобы матерей на одиночество, старость, на разлуку с детьми («Ана зары»); жалобы сирот («Ятим бала зары»); завещания и наставления, обращенные к детям («Ана васыяте»)[28].

В процессе экспедиционного исследования в Новосибирской области удалось зафиксировать несколько мунаджатов, среди которых особое место занимает «Салават» («Сәләwәт») – славословие Пророку. Образцы духовных песнопений среди населения распространялись как изустно, так и в рукописном виде. В настоящее время многие праздничные молитвы, духовные стихи, мунаджаты, салаваты, тексты религиозных книг жители изучают и исполняют из современных изданий, среди которых «Көйле китап», «Бәдүән» и др.

Сафаргалеева Райса Хабибулловна (1934 г.р.) из деревни Юрт-Ора (родилась в селе Казанка) проинтонировала Салават, посвященный празднику Ураза-байрам «Ораза аетенә[29] багышланган Салават», переписанный у бабушки-абыстай в Новосибирске. Она

[28] Сайдашева З.Н. Татарская музыкальная этнография. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2007. – 78-79.

[29] Ает (чат.) – гает (тат.) – праздник.

вспоминала, что раньше после чтения Корана всегда сказывали Салаваты, но сейчас почему-то эта традиция забылась. В ее тетради данный образец записан под заголовком «Көйле Салават».

Повествования духовных текстов всегда начинаются со слов «Бисми-л-ләхи-р-рахмани-р-рахим» – «Во имя Аллаха, Милостивого, Милосердного!», с которых мусульманин начинает каждое важное действие.

**Көйле Салават**




1. Унсигез мең галимнәргә сорау бирмәс Мөхәммәт.
Аллаһуммә салли галә сайединә Мөхәммәт!
(Да благословит Аллаһ Пророка Мухаммеда!)
2. Ятимнәргә, гарифләргә шәфкәтче ул Мөхәммәт.
Аллаһуммә салли галә сайединә Мөхәммәт!
3. Ураза тоткан өммәтләргә шәфкәтче ул Мөхәммәт.
Аллаһуммә салли галә сайединә Мөхәммәт!
4. Коръән укыган өммәтләргә шәфхәтче ул Мөхәммәт.
Аллаһуммә салли галә сайединә Мөхәммәт!
5. Абы җәһилгә шәфхәтче ул Мөхәммәт.
Аллаһуммә салли галә сайединә Мөхәммәт!
6. Рәсулла намаз укый, башында аның тахия чалмасы.
Аллаһуммә слли галә сайединә Мөхәммәт!
7. Төн ятып йокламаган, тәвәкәлле ул Мөхәммәт.
Аллаһуммә слли галә сайединә Мөхәммәт!
8. Сәхәргә торучыларга шәфкәтче ул Мөхәммәт.
Аллаһуммә слли галә сайединә Мөхәммәт!
9. Өмәтем-өмәтем диеп түгелә аның күз яше.
Аллаһуммә салли галә сайединә Мөхәммәт!
10. Салават әйткән өммәтләргә шәфкәтче ул Мөхәммәт.
Аллаһуммә салли галә сайединә Мөхәммәт!

11. Салаватны күп әйтегез, каберегездә нур булыр.
Аллаһуммә салли галә сайединә Мөхәммәт!
12. Салаватны күп әйтегез, йортыгызда нур булыр.
Аллаһуммә салли галә сайединә Мөхәммәт!
13. Ятимнәргә, гарифләргә бик шәфкәтче ул Мөхәммәт.
Аллаһуммә салли галә сайединә Мөхәммәт!
14. Салаватны күп әйтиек сәхәр чәйләре эчкәндә,
Фәрештәләр каршы алыр Сират күп[е]рен кичкәндә!
15. Намаз укыган өммәтләргә шәфкәтче ул Мөхәммәт.
Аллаһуммә салли галә сайединә Мөхәммәт! Амин!

В селе Казанка Колыванского района Мингазетдинова Асылбика Корбановна (1928 г.р.) прочитала такие строки:

Ләә Иләәһә Илләлааһы, Мөхәммәди Рәсүлүлла!
«Ләә Иләәһә Илләлааһы»ны әйтәмен
Балаларымны сагынган чакта.

Ходай Тәгалә исәннек-саулык бирсен
Газиз балаларым белән бергә-бергә булырга!
Аллаһу Хак, Әсәллү Мөхәммәт!
Мәңге баки иманнарымны
Юл башы авылларым белән бергәләп! Амин!

Дөнья шары түгәрәк,
Чырнап калган күбәләк.
Шул күбәләк эчләрендә
Яшик дуслар барыбыз бергәләп! Амин!

*Записано в селе Казанка Колыванского района от Мингазетдиновой Асылбики Корбановны (1928 г.р.)*

Также в селе Казанка от Чапкаевой Зульхабиры Тимерхановны (1954 г.р.) зафиксирован интересный факт исполнения салаватов на мотив татарской народной песни «Туган тел».

Большое место в традиционной культуре татар занимает лиро-эпический жанр – баит. Широко освещая жизненные явления, ба-

иты выражают характер, мировоззрение, мироощущение народа в любую эпоху его бытования. Слово «баит» (бейт) арабского происхождения, обозначает двухстрочную строфу. Со временем баит стал употребляться не только в первоначальном значении, но и обозначать законченное стихотворное произведение, а в дальнейшем и целый жанр татарского народно-поэтического творчества.

Содержание сюжетов баитов отличается большим разнообразием: нравоучительные, семейно-бытовые, исторические, приключенческие, но чаще всего трагические. Отражая реальные события, баиты нередко содержат сведения о точном времени и месте происшествия, так как сочиняются по горячим следам. Посредством поэтического текста баитов происходит передача чувств, мыслей, переживаний человека – трагедии расставания с миром, жизнью, родным краем, с близкими.

Произведения этого жанра находили широкое применение в учебной практике: тексты входили в дидактические книги, учебные пособия, переходили из поколения в поколение письменно, а напевы баитов передавались устным путем. В былые времена распространению этого жанра способствовали исполнители баитов – баитче (бәетче), в произведениях которых произошедшие события сразу же находили своё отражение.

Баит отличает особый стиль поэтического повествования с определенным ритмом, мелодическими оборотами, приемами интонирования нараспев на определенные типы мелодии. Обычно баит предполагает сольное звучание, при этом исполнитель должен владеть различными выразительными средствами, обладать хорошей памятью, так как встречаются образцы, состоящие из нескольких десятков куплетов.

В разных селах Новосибирской области, особенно среди татар-переселенцев, было зафиксировано знание баита «Сак-Сок, который относится к наиболее ранним образцам жанра, полностью основанным на древних мифологических представлениях. Содержание передает легенду о двух братьях-близнецах, проклятых матерью и превращенных птиц за непослушание. Обреченные на вечное скитание, разлученные навсегда братья, больше

никогда не имеющие возможности встретиться, могли лишь слышать голоса друг друга.

Данный баит является одним из самых любимых у татар: в народе бытует более пятидесяти различных вариантов текста и мелодий.

Зайнулина Мавзида Миргалеевна (1933 г.р.) из деревни Юрт-Акбалык Колыванского района баит «Сак-Сок» услышала в детстве от своей тёти. Несмотря на преклонный возраст, Мавзида аба[30] смогла исполнить его наизусть.

**Сак-Сок**




*Записано от Зайнулиной Мавзиды Миргалеевны (1933 г.р.) из деревни Юрт-Ак-Балык Колыванского района*

Необходимо отметить, что в настоящее время среди сибирских татар наблюдается процесс укрепления духовных мусульманских традиций, в селах строятся мечети, издаются сборники мунаджатов и баитов. Можно заметить возрождающийся интерес к освоению духовных жанров среди молодежи.

Таким образом, на основе усвоения традиции книжного пения как феномена художественного образования и воспитания, через интонационное воздействие на слушателей татарского стиля интонирования в контексте духовной мусульманской культуры происходит не только формирование комплекса знаний, но и воспитание способности к межкультурному и межконфессиональному диалогу.

---

[30] Апа.

Конечно, в настоящее время носителей музыкально-поэтического фольклора сибирских татар становится все меньше, а вместе с тем пропадает возможность сбора и записи аутентичного исполнения образцов народного творчества.

Но благодаря мероприятиям в учебных заведениях, школах, сельских клубах, социально-культурных учреждениях происходит постепенное приобщение детей и молодежи к татарской народной музыке, постигаются истоки национальных традиций.

Изучение и сохранение для последующих поколений музыкального фольклора сибирских татар, обладающего неисчерпаемым богатством, позволит прочувствовать самобытные и общечеловеческие основы духовности всего татарского народа и его традиционной культуры.

# ЕРАК ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ

Кушымтада Новосибирск өлкәсендә яшәүче милләттәшләребезнең рухи һәм мәдәни мирасын тулырак күзалларга ярдәм итә торган, әлегә кадәр киң катлау укучыларга билгеле булмаган берничә текст тәкъдим итәбез. Болар – XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында язылган Бараба иле турындагы тарихи ядкяр, Новосибирск өлкәсендә табылган кулъязмаларда теркәлгән фольклор текстлары, төрле елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Хәмит Ярми, Һәнүз Мәхмүтов һәм Илгиз Кадыйров тарафыннан экспедицияләр вакытында җыелган үрнәкләр, XIX йөздә төрки телләр белгече В.В. Радлов язып алган дастан тексты. Материаллар информантлар турында мәгълүматлар, әлеге әсәрләр турында күзәтүләр һәм искәрмәләр белән тулыландырылган.

*Илсөяр Закирова*

**Бараба иле**

*Бараба иле. XIX гасыр азагы – XX гасыр башларында хәзерге Новосибирск өлкәсенең Чаны районы Кошкүл авылы мәсҗедендә мәзин вазифаларын башкарган Әхмәтҗан Гыйззәтуллин тарафыннан язылган тарихи ядкяр. Текст Казан федераль университеты китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар фондында Т 3413 шифры белән теркәлгән кулъязмадан алынды.*

*Чыганакта кулъязманы тапкан һәм китапханәгә тапшырган тарихчы галим Миркасыйм Госманов кулы белән түбәндәге аңлатмалар бирелгән: «Кулъязма 1961 елгы Бараба якларына,*

*бараба телен күзәтү өчен, диалектологик экспедициягә барган чакта, Умы авылында Зәйнәб апа Назировадан алынды. Тикшерә торгач, кульязманың Чаны районы Кошкүл авылында яшәгән, 1860 тирәсендә туып, 1933 елда шунда вафат булган Әхмәдҗан мәзин Гыйззәтуллин тарафыннан төзелгән булуы ачыкланды. Мәгълүматларны Кошкүлдә көтүче булып торучы Насрулла Гыйззәтуллин – китап хуҗасының төпчек угылы бирде. Төрле әсәрләрне эченә алган җыентык. «Бараба иле» һәм «Туралы Тубыл халкы» дигән ике тарихи язмасы белән бик әһәмиятле истәлек. Кульязмалар җыю эшенә керешкән чакта табылган беренче истәлек. Миркасыйм Госманов. 1961–1963 ел. Шәһре Казан». Кульязманың алдагы битенә 3x10 см зурлыгында «Зәйнәб! Бу китапта «Бараба тарихы» бар. Син бу китапны югалтма!» дип язылган кәгазь кыстырылган.*

*Текст тулысынча беренче тапкыр басыла.*

Бараба иле, 4000 җандан гыйбарәт улан бер кабиләдер. Мәкаре мәскәнләре шәркан Уб нәһере[1], гарбән[2] Иртыш, җанубән[3] Чаны вә Сартлан күле һәм Уткүл, шималән[4] Тара елгасы. Бараба дию исемләнмәкләрендә янә төрле сүз бар. Бәгъзеләре кауленчә[5], биләре күчкәндә «Сезләр бара торың, безләр дә исәнләремезне җыйнашдырыб булган соң, артыңыздан барыб җитәрмез» дип, соңра баралмый калыб, «Бараба» булыб калган, имеш, диләр.

Тәхминән[6] 1900 нче еллар булса кирәк, Тум биләмәсенә сөлүк[7] берлә китдекемдә әүвәл Аскәтимгә төшеб, андан ат илән кидеб, Тум иленә бардыкымда, Хәбиб муллага кунак булдым иде. Шул вакытда Бараба хакында сүз чыкыб, исемләнү хакында шул югарыдагы сүземезне әйткән идем. Шунда мәзкур мулла «Юк, алай

---

[1] Мәкаре мәскәнләре шәркан Уб нәһере – тора торган урыннары көнчыгыштан Уб елгасы буенда.

[2] Гарбән – көнбатыштан.

[3] Җанубән – көньяктан.

[4] Шималән – төньяктан.

[5] Кауленчә – әйтүләренчә.

[6] Тәхминән – якынча.

[7] Сөлүк – хезмәт, йомыш.

түгел. Сезнең ул әйтүләреңез хата», дип рәдд кылды[8]. Аның сөйләве буенча, мәшһүр Чыңгызхан вә әүладе вакытларында фетнә ташкыны, кан тулкыны булган. Хосусан, Үгедәй хан заманында шул вакыт фетнәләрдән / [25а бит] күб халык качыб боскан. Шул вакыт Төркестандан, Бохарадан күб халык бу якга күчеб акган. Шунда Фараб нәхияләрендән[9] дә бер гөруһ[10] таифә тибрәнеб, төн ягына елышканлар. Анлар әкренләб кидеб, әүвәл кара кыргыз эчендә берничә ел торганлар. Анда килешмәгәч, андан кидеб, Чаны, Сартлан күленә якын ултырганлар. Анда казак тынычсызлагач, Чаны эченә утрауларында ултырганлар.

Әүвәл вакыт Чаны күле кызыл кырчын кубак[11] турында булган. Шул вакыт казаклар һәман боларны барматы кылыб талаб, булаб торган. Анда алай да бәгъзе вакыт кырчын арасында качыб, яшеренеб ятыб, кинәттән һөҗүм, ук берлән тиздән атарга боларга да уңайлы булган сәбәбле, казаклар күб файдалана алмаган сәбәбле, бер коры елны ут салган. Шул утдан Чаны урыны йите ел кукыган[12], имеш. Шул Фараб диярындан улдыклары өчен «Бараба» аталган диде. Элекке исеме «Фараби», ягъни фараблык димеш улыр. Бохараи, мысри дигән кеби. Бараба, шул утдан качыб, Чаны күленең төн ягына чыгыб ултырганлар. Анда казак тынычсызлагач, андан кидеб, Тартха (?) сугымга да кереб ултырганлар. Сугым утрау шикелле, әйләнәсе су аллаб, уртасы коры йир, имеш. /

[25б бит] Соңра тора, казак анда барыб йидеб, Барабаны талаб, малын итбал (?) итеб[13], хатын-кызларын әсиренҗә алыб китделәрендән тәмам индекеб, Калмак ханлыгына интиҗа кылганлар[14]. Калмак кабул кылса да, Барабаны амән саклау тәдбирен

---

[8] Рәдд кылды – кире какты, килешмәде.
[9] Нәхияләрендән – якларыннан.
[10] Гөруһ – төркем.
[11] Кырчын кубак – таллык.
[12] Кукыган – төтенләгән.
[13] Итбал итеп – бетереп, үтереп.
[14] Интиҗа кылганнар – сыенганнар.

күреб, низамын иҗра кыла алмаган[15]. Казакны манигъ була[16] алмаган. Һәман ара-тора таланыб торганлар. Тубылда Күчем ханга да мөтәбәгать күрмешкәнә[17], аннан да файда күрә алмаганлар.

Болай кыйналыб торганларында ишеткәнләр: кайдадыр Ак падишаһ бар. Падишаһысы татар, бик гадәләтле вә шәфәгатьле, зыйәдә рәгыйть пәрвәр[18]. Шул вакыт җәмәгать ясаб, ике кеше сайлаб, аны эзләргә карар биргәнләр. Шул сайланган кешеләрнең берсенең исеме Ималдаш, икенчесенең исеме Малтабар булган. Шул ике кемсә, чаңкы илә кидеб, эзләб барыб, Мәскәүдән табканлар. Ул вакытда, чынлаб та, Борис Фёдырич татар вакытлы ханлык мәснәдендә[19] булган. Шул вакыт бу дәд нәстыйга гарс (?) кылыб, кабул кылынуын үтенгәнләр. Соң казаклардан шикаять кылыб, аларның золымлыкларындан амән саклавын сораган. Шул вакытда сораулары кабул улыныб, амән сакламакчы улган.

Бәгъзеләрнең әйтүе буенча, Борис ханлык мәснәденә ултыргач, бөтен Себергә, Амур нәһеренәчә татарларны үзенә бәйгатькә (буйсынырга сүз бирергә) дәгъвәт кылыб[20], илчеләр күндергән. / [26а бит] Анық дәгъвәте буенча Амурдан итәкләб төрле таифәдән 92 кеше барыб йитеб, инородцә исемен дә биргәнләр. Шул кешеләрнең арасында барабаларның да вәкилләре бергә булган. Хәйкән[21] сүз бар: ул вакытда урысдан яки башка халыкдан әсәр булмаганга «ыстарший житель земля хозяин фирна буд дафний качу ишши (?) инородцә» аталганлар. Казак фетнәсендән амән сакламак ясак төлке тиресе илән алум[22] алмак шарты илән гакед, гаһед кылышыб[23], эшләре тәмам булган. Шул шарт буенча, һәр ике өйгә бер солдат куелган. Себергә юл ачылыб йөрелә башла-

---

[15] Тәдбирен күреб, низамын иҗра кыла алмаган – чарасын күреп тәртибен җайга сала, тормышка ашыра алмаган.

[16] Манигъ була – туктата, тыя.

[17] Мөтәбәгать күрмешкәнә – буйсынганга.

[18] Зыйәдә рәгыйть пәрвәр – бик яхшы идарәче.

[19] Мәснәдендә – тәхетендә.

[20] Бәйгатькә дәгъвәт кылыб – буйсынырга сүз бирергә чакырып.

[21]Хәйкән – мөһим.

[22] Алум – он.

[23] Гакед, гаһед кылышыб – сүз бирешеп, килешү төзеп.

ган. Моңа узган урыс мәэмүрләре[24] олау йиктереб, бараба күбрәге сунарчы, сәййад[25] булганга күрә өйдә булмаганга, бала вә хатынларга җәберләб йикерә, сүкеб сугалар. Аның өстенә яшь хатынкызга да тияләр.

Ул вакытда халык авылсызгә алтмыш, йитмеш, йөз чакрымда бер ат эшенә олау алыб киткән. Җәмгыләб вакыт үткәрәләр икән. Әйтәек, Олыкүлдән Туңтурага, андан Булатавига, андан Машнинга, андан Убигә, андан Тәрнәгә, андан Уткүлгә, андан Чаныка йикәләр икән. Болай булганда бу олау боларга казак фетнәсендән дә агыр тоелган. Болар ахыр, моңа тәкать тота алмый, ике солдатларны үлтереб, / [26б бит] бары күтәрелә, калмак тарафына күчеб киткәнләр. Солдатларның котылыб качканлары Тарага качыб барыб, янаралга хәбәр биргәнләр. Янарал да гаскәр илә боларның артындан куыб йитеб, бустуй зәррә мотлак берлә ата башлаган. Боларның да бер батыр миргәнләре булыб, кулына ук, йагы алыб, бушка тәгәрмәченең кигәйләрен кырка аткан.

Янарал сугыш буларын белеб, мылтык атуны туктаб, солых тарафын тотыб, ничек булса да нәсыйхәт кылыб, «Һич берни булмаз», – дия ант идеб ышандырыб кире кайтарыб килтергән. Ләкин падша Борис Фёдыричкә булган вакыйганы бер тәкүл (?) йазыб йибәргән. Шул вакытда боларның башлыклары Маңкыдай чичән дидеке кеше булган. Бу кауль[26] Бориска ирешкәч, Маңкыдайны үзенә Мәскәүгә чакырган. Баргач, хосусына алдырыб, исемен сораганда, «Маңкыдай чичән диб әйтәләр» дигән. Борис: «Чичән ни дигән сүз» диб сорагач, «Белгүр, аңлагыр дигән сүз» дигән имеш. Аннан бер дә кауль кәгазен укыб, «Бу булган вакыйга чынмы?» дигән. Маңкыдай: «Чын, дөрест». Падишаһ: «Сез үзеңез килеб, сораб биреләсез дә, ник болай кыланасыз?» Маңкыдай чичән: «Без сезгә сез үземезнең татар, казакдан амән саклар, бәлкем, дию бирелгән идек. Сезнең безгә куелган солдатларыңыз / [27а бит] казакдан да яманрак булды» дию солдатларның фәна

[24] Мәэмүрләре – җирле идарәчеләре, чиновниклары.

[25] Сәййад – аучы.

[26] Кауль – сүз.

мөгамәләләрен[27] бәян кылгач, Борис Фёдырич: «Алай булганлар булса, собаке собачий смерть, алар өчен һич сүз юк. Инде мондин соң ничек булырга телисез» дигәндә, Маңкыдай: «Мин солдат бирмимен, олау йикмимен, юл төзәтү, күпер ясау эшен муйнымга элмимен», – дигән. Борис «Алай булгач, без ничек сезгә падишаһ, сез безгә рәгыять[28] булмакчы буласыз», – дигән. Маңкыдай: «Безнең рәгыятьлекемез сезгә шул: сез безгә йитәрлек безгә бирең арткан м(й)иргә керсан (?) йортларың», – дигән, имеш. Шуның бәйгате гакыд, гаһед кылышыб[29], һәман да казакдан саклакчы булыб, эшне бетергәнләр дә, Маңкыдайга бер ярым минутга панкә[30] ачкан. Алтын кабчыгына блиҗ[31] салыб, ни нәрсә, никкә саламыз дигәндә башындан тумагын[32] алыб тоткан. Бер-ике блиҗ сосыб салгач, тумак тулыб киткән. «Дагы ниеңкә саламыз?[33]» дигәндә, итәген тоткан, вакыт узыб киткән дә, салынмаган. Шул падша, тәбәссем кылыб [34]: «Ах, чичән, абарзил», – дигән. Бараба шул гаһед буенча камил ригая кылыныб[35], солдат бирми, юл ясамый, натуральный башнина [36]бирми, олау йикми мең тукыз йөз елгача яшәб килделәр.

Мәгәр мең сикез йөз елдан соң төлке йамакы куелыб, / [27б бит] красаслы җит бутут (?) булган. Аннан соң великий кенәз Владимир Александрич килеб үткәндә, аңа прошения биреб, шул вакытда ясак заманындан бирү кала килгән Барабинский убраваның утыз мең недоимкасын кичеб йибәргән иде. Барабаның хөкүмәт тарафындан иҗра кылынган[37] фәрманлары ул

[27] Фәна мөгамәләләрен – начар эшләрен.

[28] Рәгыять – буйсынган халык.

[29] Бәйгате гакыд, гаһед кылышыб – сүз бирешеп, килешү төзеп.

[30] Панкә – банк.

[31] Блиҗ – уч.

[32] Тумагын – баш киемен.

[33] Дагы ниеңкә салабыз – тагын кай җиреңә салабыз.

[34] Тәбәссем кылыб – елмаеп, көлеп.

[35] Гаһед буенча камил ригая кылыныб – килешү буенча тулысынча буйсынып.

[36] Башнина – пушнина – җәнлек тиресе.

[37] Иҗра кылынган – чыгарылган.

вакытда ясавыл йаукды аркылы нәшер кылына[38] булган. Аларның хезмәтләре гомерлек булган. Ике соңгы ясавыл Тиле (?) күлдә Исмәгыйль дигән кеше булган. Җуйдәмус дигән кеше йаукды булган. Андан соң Бараба йите аймак – барабача йите убрава кылыб, кантур ачыб, һәр убравага берәр старшина кенәз сайлаб, ике кандидат, бер писарь, бер сотник тәгаен кылынган. Шул тәртиб янә бер илле биш еллар чамасы торганлар.

Бараба убравасында тәхминән[39] 20 старшина булыб үткәргән иде. Аннан мең тукыз йөз унынчы еллар тирәсендә бараба авылларын урыс волосларына якын-якын таратыб разбит кылынды[40]. Мең тукызынчы йөздән соң барабаларның йирләре тушага[41] 21 тисятин калдырылыб, артыгы алынмага башлады. 1916 елында инородцә яшьләре оборонага кара йомыш хезмәтенә алынды. Шул вакыт безнең / [28а бит] Кошкүлдән 29 егет алыныб, рика (?, река, Рига) якынында хезмәт кылыб, 8 айдан соң барысы сәламәт кайдыб килделәр.

1917 ел март башы берлән падшамыз Николай Александрович апставка кылыб, олуг инкылаб булды. Русия төрле-төрле фиркаләргә бүленде: большевик, меньшевик. Араларында сур сугышлар булды. Кызыллар, аклар бартияләре булды. Кавказдан урыс хөкеме күтәрелде, Хивадан урыс гаскәре чыкды, Украин автономия алды.

Без кайтаек сүземезә – барабаларның әүвәл каю диндә булыб, каю заман, ни сәбәб илә Ислам илә мөшәррәф улдыкларының[42] мәгълуме юклыгына. Хәбиб мулла әйтүенә караганда, бараба әүвәл Фараб дийарындан[43] чыкганда да мөселманлар иде. Замананың үтүе, дәүранның дәүнәве[44] сәбәбле наданлык,

---

[38] Нәшер кылына – тарала.
[39] Тәхминән – якынча.
[40] Разбит кылынды – бүлгәләнде.
[41] Тушага – душага – бер кешегә.
[42] Мөшәррәф улдыкларының – хөрмәтләнүләренең.
[43] Дийарындан – илләреннән.
[44] Дәүранның дәүнәве – вакытның тиз узуы.

җәһаләткә[45] җәлеб кылыб, саташыб маташканлары улса да, һәман мөселманлар булган. Мөселманлык игътикадындан[46] аерылмаганлар. Бәнаә галәйһи[47] алар Русиядән килгән яки нәфи кылынган[48] бер кеше булса, «мулла» дип, аңа хөрмәт кылыб йөрткәнләр. Аның белер-белмәз әйткәненә бер дә каршылык кылмаганлар. Шуңачы Оренбургда Собрания мәхкәмәсе, мөфти интихаб ителгәч[49], шул вакытда мөселман бар дию мөселманларга брафиркә[50] булганда Тары ысбравник барабаны да мөселман дип күрсәткән. Андан соң мөселманларга имам лязем диб, ул ук убравалар – Бараба берлән Күләбә алардан акыл берлән ике имам булырга тиешле диб строго кушылгач, / [27б бит] Күләбә Озынкүлдән шәех Әхмәд мулланы, Бараба убравасындан Тамтау Бикбау мулланы бриговор берлән сайлаб, Собраниягә имтиханга йибәрелгәнләр. Алар иң әүвәл имтихан кылыб, рәсми рәвешдә указный имам улганлар. Тәхминән 1800 еллар тирәсендә, аннан соң 1830 еллар тирәсендә Уңар (Өңәр) карт хәзрәт собрания барыб, имтихан кылыб, указный имам улган.

Барабада иң әүвәл салынган мәсҗед Тәрмәдә – «шәфикуйский мәсҗед», имеш. Ул салынган тәхминән 1750 елларда. Аннан соң Күләбә мәсҗеде, андан соң Тамтау мәсҗеде, андан соң Уңар мәсҗеде. Күләбә бер йахути гасыр (?) Белекте авылы кадәр. Чаны илә Чадыга бардыгымда Чады мәсҗеде бик иске иде. «Каю заманда салынган?» – диб сорарга бер дә хәтергә килмәде. Уми авыл мәсҗеде дә күб авылның мәсҗедендән элек салынган булса кирәк.

Тамтауда безнең имам рәсми булган: Бикбау мулла, Фәхреддин мулла, Хөсәен мулла. Кошкүлдән Габделгазиз мулла, Юныс, Гайнеддин мулла, Гыймран. Тибес авылында Мөхәммәдрәхим мулла, Габдеррәшид, Хасыйм (Хадим) мулла, Габдеррахман мулла, Хәбибулла мулла, Хәсән мулла. Болар рәсми

[45] Җәһаләткә – наданлык караңгылыгына.

[46] Игътикадындан – диненнән, ышануыннан.

[47] Бәнаә галәйһи – шуңа күрә.

[48] Нәфи кылынган – сөрелгән, куылган.

[49] Интихаб ителгәч – сайлангач.

[50] Брафиркә – проверка – тикшерү.

рәвешдә. Тармаклыда Ибраһим хәзрәт, Гыймадеддин хәзрәт, Габделбакый мулла. Уми авылында Мәгъсүм ахунд, Мәхмүд мулла, Насрулла мулла. Белектедә Нәфигъ мулла, Бәшир мулла, Шәфигулла мулла.

1920 нче елда имамлардагы метрикаенча / [29а бит] коңырчакга[51] табынучылар Күңнекүлдә, Җабтарда, Күләбәдә, Тукәҗидә булгалаган, имеш...



*Тандау (Тамтау) авылы мәсҗеде. Бөек Ватан сугышы елларыннан соң төшерелгән фото. Гасанова Сафия Магруповна архивыннан*

[51] Коңырчакга – курчакка.

## Нурмөхәммәд Ибраһимов сәяхәте

1953 елны Казакъстанның Павлодар областена килеп, казакъ агайлары илә аралаша башлагач, «сөягең ни, затың кем?» дигән сораклар[52] бирүчеләр күп булды. Нугай дисәң, кай йирнең нугае, диләр. Бараба йиренең дисәң, күпләре беләләр. Арасында белмәүче аксакаллары да булып, «Бараба кай йирдә, олусмы, күп ил, күп халыкмы» дигән сораулар да булгалады. Мин: «Бараба – Борынгы Каинский өязе дигән йир. Бараба йире. Бөтен Бараба йирендә 35 һәм кырыклап (кечкенә авыллар илә) мөселман авыллары. Барабалар булган. Йирләре яхшы, иген уңа, җуб үсә. Агач, урман күп. Матур түгәрәк күлләр, озын-озын, сузылып, бормаланып аккан елгалар, елгаларның ике ярына үскән кызыл агачлар, нәзек, зифа буйлы сары таллар, тирәкләр, шомыртлыклар», – дим.

Су буеның биек ярында зур-зур авыллар, калалар, шәһәрләр, утлап йөргән күпсанлы куйлар, сыерлар, сәхрәләрендә төрле чәчәкләр, гөлләр, күбәләкләр, җиләкләр, җимешләр. Яшел камышлы күлләрендә сары бакалар, симез үрдәкләр, моңлы аккошлар. Моңлы кичләрнең, ямьле иртәләрнең саф һавасын сулап, балык, үрдәк аулап йөрүче балыкчылар, үрдәкчеләр. Тара, Тартас, Ум дигән зур гына сулары бар, Арамсаз, Майсаз, Ураз Иҗә, Кама дигән кечкенә агым сулары бар.

Тара суы, Кыштуф районыннан үтеп, Тара шәһәрендә Иртышка кушыла, Ум суы, Куйбыш, Чаны, Татарка районнарыннан үтеп, Омский шәһәрендә Иртышка кушыла. Ак сакалга калай тәгъриф кылсак та, бу йиргә бараба халкы кай йирдән килеп урнашып калган дигән сөальне куймады. Хәзерге көндә шул илдән ераклашкан булсак та, асыл ватанымыз күңлемезгә якын вә сөекле улдыгыннан, бу елгы Бараба иленә сәфәремезнең мөкаддимәсендә күргәнемезне вә ишеткәнемезне кыскача язып үтәмез.

Кошкүл авылының Әхмәдҗан мөәзин язган кечкенә «Бараба тарихы» исемендәге язмада, барабалар Төркестандагы Фараб шәһәреннән күчеп килү сәбәпле, «бараба» дип аталып калганнар дип күрсәтелә. Мин: «Бу дөрес түгел, Төркестанда Фа-

[52] Сораклар – сораулар.

раб исемендә шәһәр юк», – дип занн кыла[53] идем. Әмма мәрхүм Каюм Насыйри хәзрәтләренең бер әсәрендә бу сүзләр күренде: «Фәйләсуф әл-ислам Әбү Наср әл-Фараби. Вафат 839нчы сәнәи һиҗриядә. Фарабиның чын исеме Мөхәммәд ибн Тархан иде, Төркестан вилаятендә Фараб атлы шәһәрдән иде, Исламның олуг хөкемәсендән иде. Хасыйле кәлам[54], хөкәмаи исламдан Фараби кебек кемсәнә дөньяга килмәде» димеш. Дәхи лагерьда йөргәнемдә, үзбәкләрнең бәгъзе бер сүзләре, бараба сүзләре берлә бердәй булганы ишетелде. Мәсәлән, татар әдәбиятында «дөге ярмасы» дип языла һәм әйтелә икән, бараба халкы «гөрүч» диләр. Үзбәк һәм «гөрүч» ди икән. Татар әдәбиятында «кырмыска» дип языла икән, барабалар «җөмәлди» диләр. Үзбәк һәм «җөмәлди» ди икән. Тагын башкалар. Мондый сүзләрне ишеткәч, чыннан да, Төркестан тарафыннан килделәр микән дигән уйлар килеп кала.

Бәгъзе бер бараба картлары Күчем хан үзе белән бергә алып китүгә әйткәч, «хәзергә каламыз, соңыннан барырмыз дип калганнар да бара алмаганнар, шуннан бараба аталып калганнар», – дип сөйлиләр. Әмма бу асылсыз булыр дип занн кылына. Әмма, тараби ихтималы, Татарка шәһәрендән Каргат стансасына кадәр булган йирләр Барабинский степь – «Бараба сахрасы» дип аталдыгыннан, шул сахрага әүвәл килеп урынлашулары сәбәпле, бараба дип аталулары кариб ихтималдыр[55].

Һәрбер җан иясендә табигый булган бер сизү, бер тойгы, хис кылу булу кирәк. Шул хис, шул тойгы аны туган иленә, үскән йиренә сөйрәгән һәм җитәкләгән фәһемләнә. Бер ат яки бер сыерны ерак бер йиргә сатып йибәргән вакытта, берничә айдан соң кайтып килүе булгалады. Димәк, бу гакылсыз хайван дип йөртелгән мәхлукларымыз да үз илен, үз ватанын хис кылу, аның кай тарафта икәнен белү, сизү хисе булмаса, аның йөрәгендә ватан мәхәббәте урынлашмаса, ул «кайда булса да бер тамак, кайда булса да бер камыт» дип йөргән булыр иде. Зур суларны, калын кара урманнарны, биек тауларны кичеп үтеп, иленә, иленең юлы-

---

[53] Занн кыла – уйлый.

[54] Хасыйле кәлам – нәтиҗә ясап әйткәндә.

[55] Кариб ихтималдыр – дөреслеккә якындыр.



*Нурмөхәммәд Ибраһимов сәяхәтнамәсенең беренче бите*

на төшеп, кайтуларны белә алмас иде. Киң далаларны, калын кара урманнарны яңгыратып кешнәп, илен, авылын, юлдашларын эзләмәс иде. Димәк, әл-Вахид[56] тарафындан гата кылынган[57] җәзаи бер сизү хисе аны киң сахралар, калын урманнар, зур сулар аръягында калган туган иленә, үскән йиренә ихтыярсыз сөйри, җитәкли. Йөргән йирләрен, аунаган урыннарын сөюен-сагынуын исбат кылыр өчен, әүвәл ук шул урынга, шул йиргә, шул үзе күп йөргән болынга килеп кешни, исни, ауный.

Тәңре тарафыннан йир өстенең хәлифәсе ителеп халк кылынган[58] адәм баласында хисләр, тойгылар, файда-зарарны аңлаулар, төшенүләр туган-үскән илен, йирен сагынулар, дуслар, юлдашлар белән йөргән йирләрне, утырган урыннарны хәтерләүләр, искә төшерүләр бигрәк тә көчле, бигрәк тә куәтле, бигрәк тә моңлы, бигрәк тә зарлы. Арасында йөргәндә, бергә булганда, һичбер нәрсәнең кадерен, кыйммәтен аңламыйсың, белмисең. Байлык эчендә дөньяга килгән мал кадерен белми, юлы-мәсләге бер булган дуслар, юлдашлар арасында яшәүчеләр аның кадерен белми. Азат, хөр адәмнәр азатлык, хөрлекнең кадерен белми, туган илендә яшәүчеләр туган илнең йөрәккә ничек якын торганлыгын, нинди ямьлелеген, нинди яхшылыгын белми. Туган илнең ае-кояшы, кара төндә җемелдәгән йолдызлары,

[56] әл-Вахид – Бердәнбер, Аллаһы Тәгаләнең 99 эпитетларыннан берсе.

[57] Гата кылынган – бирелгән, бүләк ителгән.

[58] Халк кылынган – тудырылган, яратылган.

агарып аткан таңы, зәңгәр күге, җиләкле кыры, карагатлы талы, җәелеп яткан матур күле, сузылып яткан озын кара юлы... Аһ, бу күренешләр, бу манзаралар минем йөрәгемнән бер минут, тик бер генә минут китеп торсаларчы... Бу сихерле картиналар минем күзем алдында иләсләнмәсәләрче, минем зиһенемне, хыялымны ерак күкләргә, фәзаэ гайре мөтәнәһиягә[59] очырмасаларчы... Икенче бер галәмдә, күрмәгән бер дөньяда, серле сәмадә[60], тын яткан диңгезләрдә сәяхәт кылдырмасаларчы...

Бу күренешләр, бу манзаралар йөрәгемнән сызылып үтеп, башымда илне, үскән йирне тагын бер күрү дигән уй-фикер тудыру сәбәпле, быел июль аенда, югарыда сөйләп үтдегем Бараба иленә барып кайту нияте илә Железинко дигән (Урлытуб районының мәркәзе) каланың автобус вокзалына килдек. Автобуска ултырганда, яңа янып ялтырап чыккан кояшның җемелдәгән нурларын котлап, кечкенә былбыллар нәзек канатларын кагып сайрап ултырганда, безнең автобус әкрен кузгалып, тәгәрмәчләрен тәгәрәтә-йөгертә башлады. Очкан кош, искән җил, чапкан ат, аккан су безнең арттан җитә алмастай булып калды. Юллар матур, ямьле иде. Моңлы иде. Омскига таба сузылган иде. Озын юлның ике ягына үскән акация агачлары, киң даланы икегә ярып аккан Иртыш суы, Иртышның биек яры буенда утлап йөрүче, кырмыскадан күп булып күренгән куйлар көтүе, киң сахраны сары буяуга буяган көнбагыш чәчкәсе – болар бары да киң далалы Казакъстанның матурлыгын, ямьлелеген, моңлылыгын күрсәтеп торалар иде. Мин хәзерге көндә ватан икамәтем[61] булган Казакъстанның җәелеп яткан киң далаларыннан, тимерчыбыклар сузылган баганалы озын юлларыннан ыргылганда, шул матур манзаралы киң далалар, бормаланып сузылган такыр юллар миңа, минем йөрәгемә илһамнар салган кеби булды. Уй-хыялларымны кайдадыр ерак офыкларга алып киткән кебек булды. Минем күңелем шул даладан да киң, уем, хыялым шул юллардан да озын кеби хис ителәә иде.

[59] Фәзаэ гайре мөтәнәһиягә – иксез-чиксез галәмгә.

[60] Сәмадә – күктә.

[61] Икамәтем – торган, яшәгән җирем.

Шул озын юлларның, очсыз хыялларның йомгагын суза-суза Казакъстан хөдүден[62] үтеп, Сибкрай хөдүденә килеп кергәч, артта калган киң дала миңа күргәнемнән дә киң кеби булып күренеп калды. Ерак даланың ерак офыкында кечкенә ялкын кеби күзгә элбелдәп күренгән сәраб[63] (казакъча сагым) көннең кызулыгын, һаваның яхшылыгын, даланың моңлылыгын күрсәтеп тора иде.

Киң күкрәген ерак күкләргә киереп, мәгърүр булып җәелеп яткан матур далага баш иеп, түбәнчелек күрсәтеп хушбуллашып, ак яулыкларымызны болгап аерылып, Омскига килеп, яшел диварлы, матур көзгеләр белән бизәкләнгән бер вагонга кереп урын алдык. Тигез тимер юлының өстеннән поездның аккан су кеби, искән җил кеби, ыркытмай-сикертмәй сөзүк кенә йөгерүе, чабуы безне бик тиз Татарка, Барабинга килтереп тә куйды.

Бу Татарка – Барабин арасы – безнең йир, безнең сахра, безнең ватан. Бу тирәдәге авыллар – бар да безгә мәгълүм авыллар. Безнең якыннар, кардәш-туганнар, дус-юлдашлар – бар да бу авылларда, бу йирләрдә. Бу йирләрдәге, бу илләрдәге диңгезләр, бормаланып аккан елгалар, яшел камышлы түгәрәк күлләр – бар да, бар да безгә якыннар, безгә сөйкемлеләр. Тармаккүл, Тибес, Җаматау, Тамтау, Сартлан, Уйбу, Утлыкүл, Арыккүл, Сыербаткан, Ум, Тартас, Арамсаз, Тара – болар безнең күлләр, безнең елгалар, безнең сулар. Безнең илемезнең, безнең йиремезнең күрке, бизәге, зиннәте. Төнге чыклар, иртәнге томаннар, агылган болытлар... Аһ, болар, бу манзаралар, бу сихерле күренешләр йөрәкнең тулкыннары, хыял сандыгының ачкычлары, бөек сәмагә[64], чиксез бушлыкка, фәзаэ гайре мөтәнәһиягә[65] очуларның, менүләрнең баскычлары, канатлары, аккан су кеби йөгереп үткән яшьлекнең кире кайтмый торган уклары, туплары.

Гүзәлләр шаһы кояш ерак күкнең иң югарысына күтәрелеп, кызулыгын, шәфкатьле нурын йир өстенә аямаенча, кызганмаенча түккән, койган бер вакытта без, Барабинскийга килеп, ак

---

[62] Хөдүден – чикләрен.

[63] Сагым – мираж.

[64] Сәмагә – күккә.

[65] Фәзаэ гайре мөтәнәһиягә – иксез-чиксез галәмгә.

вокзалның таш җәелгән, матур гөлләр, чәчәкләр ултыртылган бер йиренә килеп төштек. Барабинда борынгы танышларымыздан Габдулла, Җарулла һәм Хәлимә апа да булмау сәбәпле, кереп чыгарга өй эзләмәдек.

Здвинский районына бара торган автобус китеп калу сәбәпле, вокзал янындагы кечкенә базарга чыгып, Бакчакүл авылыннан кеше карадык. Тамтау авылының йомырка, карагат сатып торучы ике хатын «хәзер без кайтамыз, тимер күпер янында безне көтеңез» дигән яхшы сүзне әйтсәләр дә, ахырында ялганчылар булып чыктылар.

Бакчакүл авылы ике урам икән. Авылның җанибендә һәм шәрык җанибәсендә[66] матур күлләре бар. Авылдан ярты километрлык йирдә карт зыярәт. Карт каен агачлары эчендә үлән үскән иске каберләр йир берлән тигезләнгән, ихатасы юк. Мәнси вә мәтрүк[67] булып яткан әрвахлар рухына Коръән багышладык, дога кылдык.

Авылда берничә кешеләрдә кунак булдык. Бу авылда белгән кешеләремез Әмин бабай илә Тәмимдар бабай гына булдыгыннан, болар илә бераз сөйләштек. Габдулла Солтанов тарафыннан мәрхүм Исмәгыйль Гаспринский исеменә аталган Гаспра авылын никадәр күреп китәргә иҗтиһад итсәм дә, көчле яңгырлар сәбәпле, алып баручы булмады. Шулай итеп 7 көн булып, Бакчакүл авылыннан аерылдык.

Июль аенда ак ефәкләр очкан ямьле бер көндә без Барабинскийдан борынгы Каинский исемендәге Куйбыш шәһәренә килдек. Таш түшәләгән, асфальтировать ителгән урам илә Максим Горький исемендәге школның яныннан, Волков магазины алдыннан үтеп, борынгы Ашкруев магазины алдына килеп, автобус тукталды. Автобустан төшеп карана башладым. Әнә шунда (хәтеремдә ялгыш калмаса) Шәмседдинов Хәсән алма белән сату итә иде. Әнә гимназия бинасы. Башкалар хакында уйлый-уйлый, Ум суы аша салынган зур күпердән үтеп квартирга – бер якынның

---

[66] Җанибендә һәм шәрык җанибәсендә – янында һәм көньяк тарафында.

[67] Мәнси вә мәтрүк – онытылган һәм ташландык.

өенә бардык. Биш вакытның берсен әда кылганның[68] соңында шәһәрнең борынгы иске зыярәтенә барып, ясин шәриф укыдык. Барлык әрвахларның рух шәрифләренә багышлаганның соңында, без белгән, безгә таныш булган кемнәр барлыгын уйлый башладым. Мәрхүм Төхфәтулла бабай һәм җәмәгате дә бу зыярәттә булыр дия, рух шәрифләренә махсус багышладык. Каргалы Садыйк хәзрәт, мәрхүм Габделгазиз Илмәтев һәм бу зыярәттә булырга кирәк дия, һәм рух шәрифенә багышладык. Һәм башкаларга.

Зыярәтнең әйләнәсенә бик якын һәртөрле биналар салынган. Зыярәт биналар уртасында кысылып калган. Тиз көндә бу мәрхүмнәрнең өстләренә дә биналар салу куркынычы барлыгы мине кайгыга салып, йөрәгемне сызландырды. Бу мәрхүмнәрнең сөякләре мәхшәр көне җитмәенчә үк кузгатылу хәвефе мине тынычсызландырды.

Аннан яңа зыярәткә бардык. Яңа зыярәт шәһәрнең кыйбла тарафында, Куйбыштан Барабинга киткән тимер юлның уң ягында, матур күл буенда, биек кырның уртасында яхшы йирдә икән. Әле ихатасы юк булу сәбәпле, мал таптау хәвефе бар. Бу йирдәге әрвахларга һәм дога багышланды. Бу шәһәрдә таныш-белеш күп булу сәбәпле, күп өйләрдә кунак булдык. Яркүл Камал аганы һәм монда күрдек. Бер баласының өенә чакырып, кунак кылды. Картайган, куәте сәмгыясен[69] югалткан икән.

Бервакыт Бараба сахрасы халкының мәркәзе булган Каинский шәһәреннән кичке кояш озын күләгәләрен сузып, якты көн белән хушбуллашуга[70] якынлаган вер вакытта, без дә шәһәр белән хушбуллашып, иске шәһәремезне артка калдырып, Ум авылына таба сузылган кара юлдан машинаның куян кеби чабуын, кош кеби очуын карап, Ум авылына җиткәнне белми дә калдык. Ум авылыннан стансага. Тибестә Зәйтүнәдә булып, аннан Кошкүлдә Заһидулла агада булып, аннан Тармаккүл, Белекте, Чуртанлы һәм Венгердан туган авылым Арамсазга.

---

[68] Биш вакытның берсен әда кыйлганның соңында – биш вакыт намазның берсен үтәгәннән соң.

[69] Кувәте сәмгыясен – ишетү сәләтен.

[70] Хушбуллашуга – хушлашу.

Арамсазның күгелдерем күк томаннарга бөркәнгән кеби күгәреп күренгән калын каен агачларына битемезне, йөземезне бордык. Карап күз тала, караган саен карыйсы килә. Якынлаган саен йөрәк сикерә, күңел ашыга... Август ае. Җилсез, яхшы көн. Яшел яфраклы агачлар, хуш исле чәчәкләр, күбәләкләр кунган гөлләр көннең кызулыгына әлсерәп, башларын түбән салып ултыралар. Әйтерсең Кара диңгез буйлары, Кавказ курортлары, Пятигорск, Кисловодск курортлары, Батум, Сухум яклары. Сары түшле тургайлар сайрыйлар, кемнедер мактыйлар, кемгәдер мәхәббәт әзһар итәләр[71]. Бал кортлары мәгъшукалары булган чәчәкләрнең битеннән сөяләр. Кызу көннең музыканты булган чикерткәләр мандолина чиертәләр, балалайка уйныйлар. Бу күренешләр кемнең күңелен кытыкламас, кемне хыялга чумдырмас, кемнәрнең бишекләрен, каберләрен хәтеренә салмас! Җитмәсә, җем-җем итеп, Арамсаз суы ялтырап ята. Әйтерсең Урта Америкадагы Антил диңгезе, ерак Испаниядәге Җәбәл әт-Тарик бугазы, Советлар Союзындагы Волга-Дон каналы, Кавказ илә Төрекмәнстандагы Хәзәр дәрьясы!

Урал тауларының шагыйранә күренешләрен хәтерләткән, еракта төтен кеби күгәреп күренгән, язгы тын төннәрдә Сак-Сок тавышларын үзендә яңгыраткан калын һәм озын каен агачлары янына килеп туктый калдык. Беремез беремезгә бер сүз әйтмичә, бер аптырау астында тын калдык.

Шул агачлар арасындагы туфрак өемтеләренә төшкән күзләрдән яшь тамчылары тәгәри башлады. Бу безнең авылның карт зыярәте иде. Авылның күп картларының вә бик күп яшьләренең ахрави мәкәне[72] иде. Безнең аталарның вә безнең бабаларның сөякләре бу туфрак өемтеләре астында... Боларның хәлләрен сорауга безнең телләремез бармады, күңелләремез күнмәде. Тик, тик колагымызга «Сез дә бер көн бу кара йир астына керәчәксез» дигән бер өн, зарлы тавыш ишетелгән кеби булып, фани хәятнең ахыры шул икәнен уйлап, рух шәрифләренә дога

[71] Мәхәббәт әзһар итәләр – мәхәббәт аңлаталар.
[72] Ахрави мәкәне – соңгы урыны.

әйтеп, Коръән укып, бормаланып аккан су буендагы авылга бардык.

Авыл тулкынланды... Карты, яше ачык йөз, йомшак сүз илә каршы алды. Бу авыл – минем туган авылым, үскән авылым, күп еллар яшәгән авылым! Рәхәтен күргән, михнәтен тарткан авылым! Суларында йөзгән, сахраларында йөргән авылым! Шул сәбәпле җаным-тәнем, бөтен вөҗүдем илә сөйгән авылым!

Берничә көн кунак булдык, хөрмәт күрдек. Әмма бу авыл борын илле йорт иде, хәзер унбишләп кенә йорт калган. Күп йирләргә, күп яхшы урыннарга кычыткан үскән... Фәкать аккан суы борынгыдай ук матур булып агып ята. Аның чылтырап агуы, яшел камышларны тирбәтеп йөгерүе нәзек хисле шагыйрьләрне истән аударыр, күзләренең яшьләрен тамдырыр иде.

Мин бу су буена килдем... Яшь бала вакытымда кармак салып утырган урыннарыма сәлам бирдем. Уйнап-йөгереп йөргән йирләремдәге эзләремне эзләдем. Нинди балыклар тотканымны, нинди үрдәкләр атканымны күз алдыма китердем, күңел сәхифәмнән кичердем. Аһ, яшь гомер! Нигә болай тиз үттең, дидем. Су аркылы салынган искереп беткән карт күпергә килеп карап тордым. Бу күпер аркылы кемнәр йөргәнне, кемнәр үткәнне, бу суда кемнәр йөзгәнне, кемнәр чумылганны хәтеремнән кичердем. Су челтер-челтер агып, шул челтерәгән тавышы миңа көмеш кыңгырау аркылы бик күп әкиятләр сөйләгән кеби булды. Мин тыңлап тордым, зиһенемә салып тордым. Серле бер урында, яшерен бер галәмдә кеби булып тордым. Су агып бара, кемнәр ниләр эшләгәнне сөйләп бара, әйтеп бара иде. Агып барган су өерелеп, әйләнеп, миңа якын килде дә: «Нигә килмисән, нигә күренмисән?» – дип үпкәләгән кеби булды. Гозеремне әйттем, гафуын үтендем. «Инде мин картайдым, хәлдән тайдым. Күзләрем күрүдән, аякларым йөрүдән тукталуга тели башлады. Бәлки, икенче мәртәбә синең яныңа килә дә алмам. Бәлки, бу соңгы килүем булыр. Бу сүземне, бу җырымны тыңла! Әгәр килә алмасам, яшь көнемдә керемне юган кеби, кыямәт көнендә гөнаһымны ю! Сабый көнемдә хөрмәт итә алмаган, кадереңне белә алмаган булсам – гафу ит!» дидем һәм озак, бик озак, озын уйга талдым да,

Челтер-челтер аккан агым суым,
Тирән уйлар салдың күңлемә,
Кара йиргә бер көн күмелермен, –
Син агарсың шулай мәңгегә.
Нигә шулай моңлы син агасың,
Бертуктаусыз кая барасың?
Үткән гомерләрне төшереп искә,
Йөрәгемә утны ягасың.
Сулар буйлап очкан акчарлактай,
Су төбендә йөзгән чабактай,
Сине буйлап очкан, йөзгән идем,
Яшь көннәрем үтмәс замандай.
Яшь көннәрем үтте инде, килмәс,
Аккан суың борылып килсә дә.
Синнән фирак[73] уты һичбер сүнмәс,
Йиде тәмугъ уты сүнсә дә.
Өелеп яткан сукмак өемтесе –
Баскан эзләремнең билгесе.
Аккан суым, сиңа килүемнең,
Бәлки, булыр бу иң соңгысы

дигән шигырьне челтерәп аккан суның моңлы агышы илә аглы йөрәктән ерак урманнарга яңгыратып озаттым да, «Хуш, хуш инде, аккан суым, хуш инде, әбелхәятем» дидем дә, яулыгым илә күземне басып борылдым. Артыма әйләнеп карамаска тырышып киттем. Әмма аккан суның челтерәп аккан саф вә моңлы тавышы минем колагымнан, минем зиһенемнән китмәде.

Ялларын матур итеп тараган парадный яшел тарантаска җигеп, безне автобус юлы өстендәге бер авылга китереп, соңгы хөрмәтләрен билфигыль[74] күрсәтеп кайтып киттеләр. Фәкать авылда намаз укучы бер адәм булмавы, зыярәтнең әйләнәсенең ихата кылынмавы минем йөрәгемә авыр җәрәхәт әләмен салды, авылның күрсәткән бөтен хөрмәтен вә барлык ихтирамын утка якты.

---

[73] Фирак – аерылу.

[74] Билфигыль – чыннан да.

Кичердекемез хәзерге дәвердә юл өстеннән куян кеби чапкан автобусларның берсе безне ерак Нарим краеннан, Васюган, Будин тайгаларыннан агып килә торган Кама елгасының сул як ярына утырган дүрт урамлы Шагыр авылына, кичке сәгать 6 да китереп куйды. Бу авыл – безгә таныш һәм якын авыл. Бу авылның җәнүбеннән калын каен агачлыгы уратып, шималь[75] тарафыннан җәнүбкә Кама елгасы әйләндереп алган. Мәрхүмнең өенә каршы Кама елгасы аркылы салган күпер, шул күпердән үтеп, бу авылның Өтерге дигән яланнарына китә торган озын юл бар. Юлның ике ягы – йомшак үлән үсә торган матур болынлык һәм вак таллык. Әнә шул матур болынлыкта үскән йомшак, яшел үләннәр, вак таллыклар арасында мәрхүм белән ямьле җәйнең ямьле бер көннәрендә утырган идек, йөргән идек. Сызылып аккан Кама суының киләчәкнең фаҗигале булуын сөйләвен тыңлаган идек. Бу авылга килгәч тә, беренче мәртәбәдә үк, күзем шул болынлыкка, шул таллыкка, шул урынга төшеп, йөрәгемнән канлы кылыч җәрәхәте кәһин бер сызлану сызылып, ярылып үтте.

Үткән көннәрнең кадерле сәгатьләрен, кыйммәтле минутларын, серле секундларын хәтергә төшергән бу болынлык, бу матур таллык, бу ефәктән йомшак үсемлек бу сәгатьтә минем йөрәгемә җуелмаслык эз салды, ерак калган үтмешләрнең ябык ишекләрен ачты, янмаска дип сүнгән хыял чырагын яндырды.

Ерак шәрыктан сары таң куе томаннар арасыннан саргаеп, моңлы булып сузылган бер минутта Кама суының биек ярына бина кылынган мәсҗеднең манарасыннан нәзек тавышлы мәзин «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр» дип иртәнге тын моңлыкны ярып, илаһи бер тавыш, моңлы бер аваз илә азан кычкырып җибәрде. Бөтен мәхлукларның авыр һәм тәмле йокыга күмелгән бер минутындагы бу азан бормаланып аккан Кама суын буйлап, яр башындагы калын агачлыкка барып яңгырады. Барлык җан иясен тәмле йокыларыннан уятты. Мәзин шул саданы[76], шул яңгырашны тыңлап алды да, янә моңлы тавыш илә «Аллаһу әкбәр, Аллаһу

[75] Шималь – төньяк.

[76] Сада – аваз, тавыш.

әкбәр» дип сузып, моңлы иртәләрнең моңын, хисле йөрәкләрнең хисен кузгатты, хәсрәтле күңелләрнең күзләреннән яшь агызды.

Иртәнге намаз илаһи бер тынлык, илаһи бер моңлык илә үтәлгәннең соңында, мәрхүмнең үтенүе һәм теләве буенча шул тавышсыз, әкрен аккан су буендагы болынлыкта үскән вак таллыклар арасына барып утырып, иртәнге шифалы һаваны сулышымыз илә эчкә тарта-тарта көнчыгыштан җылтырлы алтын чаткыларын, бриллиант нурларын чәчеп, янып-көеп чыгып килә торган кояшка карап, авыр уйга талдык. Мәрхүм сүзгә башлады: «Бу иртәнге сәгать нинди моңлы, нинди серле сәгать! Йөрәкнең урыныннан кузгалып, фантазиянең белтерүе гайре мөмкин бер галәмдә сер иткән сәгатедер. Башка уй сыман, йөрәккә дәрт сыман, мәгълүматсыз калган, мәгърифәтсез калган, гайре милләттән гасырларча артта калган татар милләтенең киләчәге, истикъбалы[77] хакында ут йотып көрәшүчеләргә көч бирүче юк. Зарланучыларга, сызланучыларга күңел юатып дәрт бирердәй, рух кертердәй сүз юк, ярдәм юк. Галия шәкертләре зыяга наразыйлык[78] күрсәтеп чыгып яталар, мораббилары[79] булган байлар ярдәмнән ваз кичеп яталар. Буби мәдрәсәләре суд залында, мәгъюбләр[80] өстәлендә хөкем кылынып срок алып яталар». Вә башкалар хакында бер хәйли[81] сүзләрдән соң ул, ерак тарихларга кереп,

Нинди моңлы булып ята икән
Алтай тавы – түрк төяге.
Кай йирләрдә ятып чери икән
Бөек бабам – Түрк сөяге?

дигән шигырьне әйтте.

Алтай тавында ат уйнаткан, Алтай тавын яңгыратып гайрәт күрсәткән Ясүкәй батыр вә Чыңгыз хакында, Ясүкәйнең Чыңгыздан башка дүрт бала калдырып вафат итүен, Чыңгыз

[77] Истикъбалы – киләчәге, булачагы.
[78] Зыяга наразыйлык – яктылыкка ризасызлык, канәгатьсезлек.
[79] Мораббилары – ярдәмчеләре, саклаучылары.
[80] Мәгъюбләр – гаепләнүчеләр.
[81] Хәйли – байтак.

атасы үлгәндә 13 яшьтә калуын, Ясүкәй кул астында булган магул, татар, түрк кабиләләренең башлыклары үзләренең ханнары Ясүкәйне күмгәч тә, шул урында ук кечкенә Чыңгызга ант итмәячәкләрен белтерүләрен, тайдушт кабиләсенең башлыгы Торкутайның иптәшләренең берсе Чыңгызга: «Кай вакытта бик тирән коелар да корыйлар, ташлар да ярылалар. Инде без сиңа ни өчен баш иеп торырмыз?» – диюләрен, Чыңгызның анасы Олун әкә ошбу сүздән әсәрләнеп, Ясүкәй һәм Чыңгызның асыл кабиләсе бүрҗәгин кабиләсеннән гаскәр алып, кулына Ясүкәйнең тунын алып, атына менеп, баш тарткан кабиләләргә каршы сугышка чыкканын, гайрәтле анасы Олун әкәнең гайрәте сиясендә Чыңгызның йир селкеткән бер хан булып, Иртыш елгасыннан Хинган тауларына кадәр булган йирләрне, шәрыкта Мохит диңгезе вә Сары диңгез сахилләреннән[82] Алтай тауларының гарби[83] итәкләренә кадәр булган йирләрне, Чыңгыз ул вакыттагы дөньяның иң көчле, иң зур бер императоры булып, берүзе идарә итүен бик тәэсирле һәм бик моңлы итеп сөйләде. «Күрәсең, хәзер Романовлар нәселе кул астында изелеп, 300 ел тапталуымыз» диде дә, Казан хакында сүз башлады: «Гайрәтле бикәмез Сөенбикәнең ире Сафагәрәй хан вафат иткәндә, угылы Үтәмешгәрәй кечкенә булу сәбәпле, ханлык вазифасын анасы Сөенбикә үтәп, дошманнарына каршы гайрәт күрсәткәнен, 1550 ел 14 февраль кенәз Иван җөмлә гаскәре илә Казан крепосте алдына килеп, алтмыш мең гаскәр берьюлы крепостькә һөҗүм иткән куркынычлы бер вакытта, Казанның гайрәтле, гакыллы мәликәсе Сөенбикә крепость өстенә менеп, үзе командалар биреп торганын, 25 ел кадәр хан хатыны булып, соңыннан үзе ханым улган гакыллы Сөенбикәне кенәз Иванга тапшыруга Казан халкының гаһеде[84] буенча кенәз Серебряный алырга килеп, Сөенбикәгә алырга килгәнлеген белтергәндә, Сөенбикә: «Аллаһының тәкъдире шулайдыр инде», – дип, хушсыз булып йиргә егылганын, озатыр алдыннан Сөенбикә Хан мәсҗеденә ке-

[82] Сахилләреннән – ярларыннан.
[83] Гарби – көнбатыш.
[84] Гаһеде – килешүе.

реп намаз укыганын, Хан мәсҗеде янында Сафагәрәй хан (ире) каберенә барып, бик каты егълаганын һәм үзенең сөекле ире Сафагәрәйгә үзенең ничә еллар хан булып, җаны-тәне илә хезмәт иткән халыклары бу көн антларын бозып, үзенең дошманына әсир итеп бирүләреннән шикаять әйтүен һәм «Ач кабереңне, мин керәем! Бу кадәр газап вә хурлыкларны күрми, синең кеби кабердә ятаем! Ач кабереңне, кочагыңа керәем! Ал мине яныңа!» – дип, үзен кабер өстенә атканын, фәкать мәрхәмәтсез кабер ачылмаган да, ярылмаган да икәнлеген сөйләде.

Сөенбикә илә угылы Үтәмешгәрәйне падишаһларга махсус көймәгә утыртып, көймә кузгалып киткәндә, Сөенбикә, егълый-егълый, гаять әсәрле, гаять тә моңлы бәетләр укыганын һәм «Әй, Казан! Әй бәхетсез шәһре Казан! Син элек бал елгалары агыза идең. Инде кан елгалары агызачаксың!» – дип егълаганын, «Хуш, Казан! Хуш, Сафагәрәй!» – дип, соңгы кайнар яшен агызып кычкырганын, бөтен Казан халкының егълап калганын нинди каты күңелләрнең дә күзеннән яшьне ихтыярсыз тартып чыгарырдай бер зар, бер моң илә сөйләде. Бу сүзләрнең йөрәккә никадәр әсәр биргәнлеген, тарихи булган үтмешемезнең фаҗигале бу авыр картиналарын күз алдына ачып куйганлыгын, йөрәгемә нинди сызыклар сызганлыгын мин сезгә аңлата алмам.

1914 елда сөйләгән бу сүзләре, бу сүзләрне сөйләгәндә, киң маңлаендагы тарихи сызыкларның йөрәгенең ялкынын белтереп торулары, башыннан хисапсыз уйларның аккан су кеби агып торулары быел шул авылга бардыгымда, шул урынны күрдегемдә минем йөрәгем үзенең нормальлеген югалтты, үзендә бер тетрәү, бер калтырану сизде. Шул урын һаман да бар, шул су һаман да агып ята. Әмма, әмма ул юк! Фәкать зарланган зарлары, көйләгән моңнары, татар милләте өчен, татар милләтенең истикъбалы өчен ялкынлы йөрәгеннән кайнап чыккан утлы сүзләре минем йөрәгемдә калган, минем йөрәгемнән чыкмаслык һәм китмәслек урын алган. Үзен оныттырмаслык, мәңге җуелмый торган эз салган, әсәр калдырган.

Бу мәрхүм илә моннан соң да күп очраштык һәм күп хатлаштык. Очрашуда да, хатлашуда да бер ут, бер ялкын, бер моң, бер

зар – милләт, изелгән милләт, Романовлар аягы астында тапталган милләт, укудан, гыйлемнән, белемнән мәхрүм милләт дип, гомумтатар милләте өчен кайгыру. Яну-көю соңында үзенең яшәдеге, Бараба халкы хакында «аһ» итә, башыннан кичкән уйларны йөрәге сыйдыра алмаганлыктан гасабиланып, ачуланып китә дә, миңа: «Ил агарту эшендә, җәһаләт белән көрәшү юлында нигә йомшаклык кыласың? Әйләнәңдә – кара төн, надан халык. Күрмисеңме?! Яхшы ат, яхшы йорт нигә кирәк булды? Аллаһыдан вәхи-илһәм яхшы йортларга килмичә, мәгарәдә ятучы мескиннәргә, хаклыкны эзләүче, халыкны җәһаләт караңгылыгыннан коткарырга тырышучы, рәхәтен, тынычлыгын халык мәнфәгате өчен файда итүчеләргә килгәнлеген сез бик яхшы беләсез түгелме?!» – дип, миңа ачы хитаплар да кылып куя иде.

Ул мәрхүм Бараба халыкларының дини һәм дөньяви эшләрдә артта калуларын, бакчачылыкка да әһәмият бирмәүләрен, хәтта кыярны да урыстан сатып алуларын сөйләп, «мәдәни хәятне, мәдәни тормышны без кабул итмибезме, әллә мәдәният безне кабул итәргә теләмимe?» дигән сөальле сүзләр дә әйтеп куйганның соңында, бу шигырьне әйтте:

Безләр йокладык, йокы куймадык,
Киләчәгебезне бик аз уйладык.
Киләчәк килде, безне дә изде,
Без калдык түбән һәркемнән инде.
Шаһидләр – тагълар, бездә низагълар,
Безнең бу хәлгә тагъ һәм таш агълар.
Куллар һөнәрсез, беләкләр көчсез,
Дөнья хәленнән башлар хәбәрсез.
Төкләр агара, туфрак кабара,
Йөк һич кузгалмый, хәл бетә бара.

Бу шигырьләрне укыганда, мәрхүм бер өмидсезлек астында, «халкымызны агарту, илемезне мәдәниятләштерү безгә насыйп булмас, ахрысы, илемездә наданлык төннәре бетеп, гыйлем-белем таңнары агарып атканын, мәдәният гөлләренең чәчәкләрен без күрә алмабыз, җимешләрен без җыя алмабыз, ахрысы» дигән

кебек сизелә иде. Мәрхүмнең зары, моңы Габдулла Тукайның «Егылдык без ике-өч чакрым да бармый, егетләр, бездә көч юк, ахры, булмас» дигән бер өмидсез шигырен хәтерләтә иде. Бу сүзләрдән, бу шигырьләрдән һәм зарлардан соң мәрхүм хатларында милләт өчен кайгыру сүзләрен язмас булды. Гүяки өмид өзде, гүяки кул селтәде. Әмма милләт өчен зарын туктатып, фәкать соңгы язган һәрбер мәктүпләрендә әдәбиятымызда аз күрелгән гыйшык-мәхәббәткә даир табышмаклар, гыйшык-мәхәббәткә даир шигырьләр яза башлады. Бу табышмакларның чишелүен миннән сорап яза иде. Әмма мин никадәр боргалап карасам да, чын мәгънәсен аңлый алмыйм, асыл серенә ирешә алмыйм, тик йөрәгендә көчле бер мәхәббәт уты, гыйшык ялкыны барлыгын аңлатканын гына аңлыйм. Шул табышмакларның берсе генә булса да хәтеремдә калган булса, мин сезгә язган, аңлаткан булыр идем. Әмма, мәга тәәссеф[85], берсе дә хәтеремдә юк.

Йөрәгендә яшерен бер сүз барлыгын белтерә торган табышмаклы хатлар килгәләгәч, мин «сезнең мәктүпләрегез эчендә кинаяле табышмакларыгыздан сезнең йөрәгеңездә бер тулкын, яшерен бер гыйшык, серле бер мәхәббәт барлыгы аңлашыла. Ачык итеп языгыз, әллә сез чыннан да гашыйкмы? Нәрсәгә?» дип сорап язуыма ул шул сүзләрне яза: «Мин гашыйк, мин чын гашыйк! Мин әүвәл милләтемә хезмәткә гашыйк булдым. Милләтем өчен яндым, көйдем, әмма милләтем күземнең яшен күрмәде, йөрәгемне аңламады. Ә, ә хәзер мин нурлар шаһы кояшка гашыйк, җәйге моңлы кичәләрдә калын урман аръягыннан саргаеп чыккан тулган айга гашыйк. Күктәге фәрештәләргә, җәннәттәге хурларга гашыйк. Искән җилгә, аккан суга гашыйк, матур чәчәкләргә кунган зәңгәр күбәләкләргә гашыйк. Юк, юк, мин боларның берсенә дә гашыйк түгел! Мин милләтемә, милләтем өчен хезмәтемә гашыйк!» – дип яза. «Тик фәкать милләткә хезмәткә мәхәббәт бәндә бар, бәнчә монда ямь дә бар, ләззәт тә бардыр, тәм дә бар» дигән мәрхүм Габдулла Тукайның шигырен яза да, йөрәгендә куәт алган бер гыйшык хакында, аның кайдан

[85] Мәга тәәссеф – кызганыч ки.

вә ничек пәйда булуы хакында хыялый сүзләр язганның соңында «Гыйшык дигән нәрсә – бер сердер. Аның кәшфе[86] мөмкин түгел, аның хакыйкатен белгәне юк. Ләкин шуны белү кирәк: гыйшык – төтенсез уттыр, ачкычсыз йозактыр, дәвасыз сырхаудыр, кадәхсез[87] шәрабтыр, йөксез авырлыктыр, мәнзилсез[88] сәфәрдер. Бу утта мин, янып, мәнзилсез сәфәрдә бара ятармын» ди дә түбәндәге шигырен яза:

Гыйшык пәрванасы[89] очты,
Мәхәббәтнең утын төртте,
Аның гыйшкы бәне өтте,
Оныттым ике дөньямны.
Гашыйк гариб диванамын,
Хыялланып куанамын,
Шигырь сөйләп юанамын,
Ки мәҗнүн итте ул бәне.
Хуры түгел, пәри түгел,
Мәләиктән бере түгел,
Вәли инсан ирер бу, бел,
Будыр, бу – сәнгы Сөбхани[90].

Мәрхүм бу шигырендә үзенең мәгънәви мәгъшукасын шулкадәр мактый, хур кызы да түгел, пәри кызы да түгел, фәрештәләрдән дә түгел, әмма инсан ди дә, мондый бер матур сурәтне халәкъ кылган Аллаһы Тәгалә сәнгына хәйран калып, «Будыр, бу – сәнгы Сөбхани» дип, бер тәхәйер[91] эчендә шигырен бетерә. Ул моның белән калмый да һәм туктамый да. Күп вакыт үтми язган озын бер мәктүбендә «Айлы кич» сәрләүхәсе[92] астында язган шушы бер шигырен яза. Әмма күп мисраглары минем хәтеремнән чыккан. Хәтеремдә калганын гына язам. Бу озын иде:

---

[86] Кәшфе – серләре ачылуы.
[87] Кадәх – шәраб савыты.
[88] Мәнзилсез – өйсез, йортсыз.
[89] Пәрванасы – күбәләге.
[90] Сәнгы Сөбхани – Аллаһы Тәгаләнең бар иткәне.
[91] Тәхәйер – гаҗәпләнү.
[92] Сәрләүхәсе – исеме.

Айлы кич, якты чырайлы матур кич,
Ул кунып, ут якты минем җаныма.
Уйнады, көлде вә күп уй уйлады,
Ул борынып ятты хыял юрганына.
Йоклады ул күкрәге калкып, сөенеп,
Киң ишек ачты шагыйрь илһамына.
Ул матур керпекләре – гөл сөнбәле,
Сачрәтер ди шөгъләә нурания[93].
Аллага әйттем сәна[94] мин таң белән,
Ул мәләкнең сау, исән торганына,
Ул – мәләк ди, әллә кем илһам итә, –
Юк, ышанмыйм мин аның борһанына[95].
Юк, ул – инсан, безем дик җанлы тән,
Аптырыйм тик бездә аның торганына.

Мәрхүм бу шигырьләрендә мәгъшукасының уйнап көлүләре, күкрәге калкып сөенеп йоклаулары, талантлыгын, шигъри куәсен вөҗүдкә чыгаруга киң ишек ачканын белтерә. Ниндидер бер көч, ниндидер бер куәт шул мәгънәви мәгъшуканы шагыйрь йөрәгенә мәләк дип илһам итә. Әмма шагыйрь аңа ышанмый, ул – адәм ди, тик шундый матурлыкның йир өстендә, халык арасында торуына, йөрүенә аптырый.

Заман кичкән, көн үткән саен, аның йөрәгендә урын алган мәхәббәт көчәйгәнлеге аңлашыла. Ул соңгы «Кара күзгә» дигән шигыре илә моны исбат итә: шул йир өстендә булмаган мәгънәви мәгъшукасын соң дәрәҗәдә мактап, бер шигырь яза. Ул шигырен сезләрнең назар дикъкатеңезә куям:

Ак келәтеңезнең, ай, алдында,
Кара чәчең майлап тарадың.
Гашыйк булсын миңа дигән төсле,
Чәч астыннан көлеп карадың.
Кара күзем, чәчең ник тарадың?

---

93 Шөгъләә нурания - утлы ялкын, утлы күмер.

94 Сәна – мактау сүзләре.

95 Борһанына - дәлиленә.

Нигә борылып көлеп карадың?
Бер каравың берлә шул сәгатьтә
Моңлы күңлемә син ярадың.
Карауларыңны син бик балладың,
Бер карагач күзең алмадың,
Әй матур кыз, күзем, күңлем нуры,
Минем гашыйк күңлем алдадың.
Сөям, җаным, сөям, и, үзеңне,
Былбыл сайравындай сүзеңне,
Айдин якты, алмалы йөзеңне,
Сөям серле, кара күзеңне.
Сөям, җаным, сөям, бик сөямен,
Сөйгәнлектән янып көямен.
Илтифатсыз гына йөрүеңнән
Синең сөймәгәнең беләмен.
Сөймә, җаным, сөймә, зинһар сөймә,
Мин көйгәндәй янып син көймә.
Гашыйк булу, җаным, авыр икән,
Гыйшык зәһәрләрен син йимә.
Үсеп буйга, җаным, син җитәрсең,
Сөйгәнеңә кавышып китәрсең,
Чын күңелдән сөйгән мин гарибне,
Янар утка салып китәрсең.
Күзләремне салам мин күзеңә,
Куяр идем йөзем йөзеңә.
Музыкадан моңлы тавышың чыкса,
Былбыл сәҗдә итәр үзеңә.
Фәрештәләр тәсбихләрен онытыр,
Матур гына мазып син көлсәң,
Канатларын җәеп каршы торыр,
Юл өстенә чыгып син йөрсәң.
Кулларыңнан тотып, и, бер кыссам,
Билләреңнән кысып бер кочсам,
Басылыр иде йөрәкнең ялкыны,
Телләреңнән суырып бер үпсәм.

Кибә гөлләр сабыннан каерылып,
Китә кошлар илдән аерылып.
Фиракъ уты яга йөрәгемне,
Калам инде синнән аерылып.
Бу җырларны миңа илһам итте,
Шул иляһи матур кара күз,
Бу җырларны сиңа багышладым,
Кабул иткел, җаным, кара күз.

Бу шигырьләрне дикъкатькә алып тикшереп караңыз, шундый матур җөмләләрдән төзелеп, шагыйрьнең йөрәгендәге утын укучыларның йөрәгенә ташлый. Гүя ул мәгъшукасын – йир өстендә булмыйча, күңелендә генә булган сөеклесен келәт алдында очраткан. Аның чәч астыннан көлеп бер каравы, мәрхүм шагыйрьнең бөтен вөҗүден үзенә җәзб кылып[96], «алмалы йөзеңне, былбыл сайравындай сүзеңне, серле кара күзеңне сөямен» дип җырлата. Ул мәгъшукасын мактауда саранлык кылмый, «музыкадан моңлы тавышыңа былбыл сәҗдә итәр, матур гына мазып бер көлсәң фәрештәләр тәсбихләрен онытыр, юл өстенә чыгып бер йөрсәң, канатларын җәеп каршы торыр» дип, искиткеч матур җөмләләр илә мактый. Бу шигырьләрне берәм-берәм тотып тармаклау, бәһаләү озынга сузылачак булдыгыннан, кыскача шуны гына әйтәм: тын яткан тирән диңгезнең дулкыны кеби тын яткан йөрәк дәрьясын дулкынлаткан бу шигырьләрнең нәфасәте[97], тәэсирәте, моңлылыгы алдында мин тез чүгеп, мәрхүмгә соңгы ихтирамымны, соңгы хөрмәтемне гарз кылып[98], мондый талантлыкның, мондый куәте шигъриянең мәйданга чыкмавына сәбәпләр эзләп, әллә ул вакыттагы зәмин[99], яки илтизам итдеке ләвазим[100] мәнигъ булды[101] микән дип хәйран ка-

[96] Җәзб кылып – үзенә тартып.

[97] Нәфасәте – гүзәллеге, кыйммәте.

[98] Гарз кылып – белдереп.

[99] Зәмин – төп нигез.

[100] Илтизам итдеке ләвазим – үзенә тиеш дип тапкан, үз өстенә йөкләгән эшләр.

[101] Мәнигъ булды – тыелды.

лам. Һәрхәлдә, бәхетсез Бараба иленең бәхетсез улы, бәхетсез почмакның әсир былбылы булган бу мәрхүм укыды, язды, сөйләде, әмма сүзе Бараба халкының колагына кермәде яки Бараба халкының колагы кабул итмәде. Шулай итеп, матбугат галәменә дә чыкмады. Кызганыч хәлдә сүнде, югалды.

Бу мәрхүмнең «Тамтау сәгъләбе»[102] исемендә 72 мисраглы һөҗүви[103] бер шигыре бар иде. Кызганыч, бер мисрагы да хәтердә юк. Дәхидә бер авылның икенче авылдан 2 көн соңга калып рузага керүе, рузаны 28 тоткач айның күренүе, ике көн руза тулмыйча, авыл мулласына бәйләнүе, ике көннең калуы халыкка авыр тәэсир итүе хакында озын бер шигыре бар иде. Ике генә мисрагы хәтеремдә калган. Зураеп калган шәүвәл аен муллага күрсәтәләр. Мулла карый. Шагыйрь шулай яза:

Карт ай көмеш нугадай, харьковский дугадай,
............... хәзрәт бугадай, карый иде дидия.
Матур ай күктә йөзә, күңелгә серләр сыза,
Картларның бәгырен өзә, калган көннәр дидия...

Моннан соң ул мәрхүм илә күп вакыт бер-беремез илә очраша алмадык, хат та языша алмадык. «Тормышка» дип язган соңгы бер шигырен хәбесханәдә[104] язды. Ул шигыре бу:

Изәсең дә тормыш, и, изәсең,
Яшь йөрәккәемне кисәсең.
Ник янасың, йөрәк, ник кибәсең,
Әллә бер хәл барын сизәсең?
Яшь йөрәккә каһәр тырнагыңны
Нигә шунчак батырып саласың?
Каһәрлисең җанны, зәһәрлисең,
Әллә калган үчең аласың?
Яна йөрәк, ташый ут ялкыны,
Сүндерә алмас суның салкыны.
Ит кисәге йөрәк бер көн бетәр,
Җәһәннәмнән көчле ялкыны.

---

[102] Тамтау сәгъләбе – Тамтау төлкесе.

[103] Һөҗүви – сатирик.

[104] Хәбесханәдә – төрмәдә, тоткынлыкта.

Ашыкма син, мәлгунь явыз тормыш,
Морадыңа тизерәк җитәрсең,
Янып-көеп үлеп мин күмелсәм,
Каберем өстендә туй итәрсең.

дип җырлады, җылады, янды, көйде һәм, вакыйган, хәятенең соңгы хәлләре бу шигырендә сөйләгәнчә булды.

Быел, ягъни 1959 ел туган илгә сәфәремдә, шул мәрхүмнең авылына килеп, шул авылның карт каен агачлары эчендәге иске каберстаннан мәрхүмнең каберен эзләдем. Шунда кабере юклыгын белсәм дә, кабере бу авыл зыярәтендә түгеллеген аңласам да, һаман эзләдем, һаман эзләдем. Тик хәрарәт[105] эчендә кайнаган йөрәгемнең утын, ялкынын сүндерергә, хәрарәтен киметергә дип йөрдем, әмма, әмма иң дә көчләндереп, иң дә куәтләндереп кайттым... Тик сагынган йөрәк, юксынган йөрәк сагынудан, юксынудан кайнаган йөрәк, эзләде, эзләде... Әмма таба алмады.

**Бараба җиренә күчкәндә**

Биек кенә кырның, әй, башында
Борлыгадыр богдай орлыгы.
Карындаш тугандин, әй, аерылган,
Әй-һай гынай дөньяның хурлыгы.

Бараба ла җире, әй, мал җире,
Беснең Сембер җире – ут җире.
Ут җире дә булса китмәс идем,
Бары да бер Ходайның тәкъдире.

Ултырдым чананың, әй, төбенә,
Дилбегәй генәмне кулыма алып.
Өч мең чакрым җиргә бән барамын,
Әҗәл генәмне кулыма алып.

[105] Хәрарәт – ут-ялкын.

Өч бубаска[106] йектем, әй, китәргә,
Бараба иленә, әй, җитәргә.
Туганнарым әйтми, әй, китәргәй,
Белмәймен ук нихәл итәргәй.

### Кулларыма алдым...

Кулларыма алдым кәгазь, каләм,
Мәҗбүр булдым язып карарга.
Язуларым матур булмаса да,
Батырчылык иттем язарга.
Языйм әле, дускай, языйм әле,
Мине искә алып көйләрсез.
Язулары – алларымда, үзе
Кайда икән диеп сөйләрсез.
Әҗәлләрем җитеп вафат булсам,
Шушы булсын минем сәламем.
Үзем үлсәм инде синең кулда,
Калсын иде язган каләмем.

### Хәмдениса бәете

Риза-бәхилләрем юк
Гали дигән бәндәгә.
Кулларына мылтык алып,
Атып салды идәнгә.
    Мылтыгын кулына алгач,
    Җөрәгем дерелдәде.
    Адәм затыннан түгелдер –
    Кызын да җәлләмәде.
Идәндә яткан чагында
Акты минем каннарым,
Мине күреп бихуш булып
Җылады туганнарым.

---

[106] Бубаска – повозка – йөк.

Әниемнең, мине күреп,
Җөрәге яраланды,
Минем яннарыма килеп,
Хәлләремне сорады.
Әниемнең нурлы йөзен
Кайгы-хәсрәтләр баскан.
Сабыр ит инде, әнкәем,
Диваналыктан саклан.
Тәрәзәмнең төпләрендә
Чәчәк ата гөлкәем.
Гомерләрем кыска булган,
Сабыр ит, әнекәем.
Лимон сары, лимон сары,
Чын сарысы үземә.
Туганнарым, зинһар өчен,
Сүз әйтмәгез кызыма.
«Аллам, Аллам» дигәндә,
Телемә иман бәйләнсен.
Кыямәт көн күрешергә
Ходай насыйп әйләсен.
Мине озатып калдылар,
Хуш бул инде, диделәр,
Аллага шөкер, фәрештәләр
Каршы килеп алдылар.
Мин киттем сезне калдырып,
Мәңгелек җирләремә.
Ходай күрешергә язсын
Кыямәт көннәрендә.

**Манара мөнәҗәте**

Әй манара, ай-уракларың
Каршы иде кыйблага,
Ничә еллар зикер-тәсбих
Әйткән идең Аллага.

Әй манара, исемнәрең
Бигрәк матур кушканнар,
Таң алдыннан килгән булса,
Куркыр иде дошманнар.
Әй, манара, үзеңне кем
Кискәнен белә алмадың,
Бер Ходайдан әмер булып,
Нигә телгә килмәдең?
Әй манара, син утырдың
Мөэминнәргә билгегә,
Сине кисеп төшергәннәр
Хур булсыннар мәңгегә.
Әй манара, таң тугач та,
Азан тавышын көтәбез.
Азан тавышын ишетмәгәч,
Мәхрүм булып китәбез.
Манаракаем, мәсҗедкәем,
Сиңа сыгына мөэминнәр.
Азан да юк, намаз да юк –
Гафилләнде бит илләр!
Әй манара, синең аең
Кояш кебек ялтырый.
Әй манара, син ауганда,
Җөмлә мөэмин калтырый.
Манара әйтә, син ишет:
«Бу көн мине кисәләр!»
«Әй, манара, бәхил бул», – дип,
Кыйбла җилләр исәләр.
«Манараны кисәләр», – дип,
Күп халыклар йөриләр.
Җир йөзенә фәрештәләр
Саф-саф булып иңделәр.
Манара әйтә, кисәләр бит,
Авам, авам, тотыңыз!
Өметләрем, барчаңыз да

«Әл-Касрйинне» укыңыз.
Мәсҗедләрнең тәрәзәсе
Бар да җиргә коелды.
Фәрештәләр, канат җәеп,
Саф-саф булып җыелды.
Бүлем-бүлем баскычларын
Алып-алып куялар.
Бүлем саен фәрештәләр
Саф-саф булып куналар.
Әй манара, сине кискәч,
Барча кошлар таралды.
Әй манара, сине кискәч,
Зиһеннәрем таралды.
Манараны кисәләр дип,
Бала-чага тавышы.
Әй манара, син булмагач,
Бетте азан тавышы...
Манараны кисү белән,
Ай-кояш нуры бетте.
«Иннә иләйһи ражигун» дип,
Манара авып китте.
Җилләр бүген төньягыннан
Ямьсез булып исәләр.
Әй, мөэминнәр, бәхил булың!
Бүген мине кисәләр.
Мәсҗед әйтә, юк гөнаһым,
Сүтәбез дип киләсез.
Кыямәт көн минем турыда
Ничек җавап бирәсез?!

Таралып киттеме шәлләрем,
Табып булмый әйтер сүзләрем.
Күгәрчен әйтә, юк мәсҗедем,
Инде кайда гөрләрем.
Ничә еллар бер урында

Ялгыз утырды башым.
Биш вакыт намаз, тәрәвих
Иде бит минем эшем.
    Бар халыклар җыелканнар,
    Бар да мәсҗед сүтәләр.
    Мәсҗедтәге фәрештәләр
    Бар да тәкбир әйтәләр...
Мәсҗед әйтә, Ходай мине
Бу дөньяда зурлар ул.
Манара кисүчеләрне
Ахирәттә хурлар ул.
    Һавада болыт булмаса,
    Җилләр дә исмәс иде.
    Аллаһдан вакыт җитмәсә,
    Манара кисмәс иде.
Дога кылыйк, әй манара,
Бу көн актык көнемез.
Минем турдан үткән чакта,
Дога кылмый китмәңез.

**История моего рода**

История моего рода необычна и интересна. Мои далекие предки в XIX–XX вв. были людьми известными, и потому до нас дошли их имена. Свою родословную я могу проследить до 8 колена (до 1775 г.). Мои прадедушки были верующими и священнослужителями, распространяли исламскую религию в Сибири, среди барабинских татар.

Наш предок Сулейман-баба жил в ауле Чембилее Нижегородской области. Там он вырастил пятерых сыновей: Арихкула, Яуду (или Явдата), Субханкула, Хасана и Хусаина. Первым на сибирскую сторону ушел Арихкул, нес государственную службу в Иркутске, состоял в охране золотых приисков. Отслужив 25 лет, он остался в Сибири, переселился в барабинские степи, где коренным населением были татары.

После отечественной войны 1812 года в Сибирь отправился Ибрагим, внук Яуды. Ибрагим родился в Чембилее в 1796 году, окончил медресе в городе Касимове. В Сибири он отыскал дядю Арихкула. Полюбилась ему барабинская земля, и он перевез сюда своих родственников из Симбирской губернии.

Ибрагим Яхья улы Карюков стал со временем известным человеком в Барабинской степи. Его звали шейхом. Центральное духовное управление мусульман в Уфе назначило грамотного и деятельного Ибрагима хазратом огромной территории всей Барабинской степи и Тургайской долины, в которую входит ряд областей Казахстана. Для объезда этой территории требовался целый год. Он поселился в ауле Онар (сейчас деревня Тармакуль). Здесь хазрат открыл первую мечеть и медресе для детей татар. Должность миссионера была поначалу нелегкой, местные жители были язычниками и не сразу приняли ислам. Но постепенно он завоевал доверие людей, его уважали и боготворили. Власти, а также князья прислушивались к его мнению. По словам бабушки, он обладал даром ясновидения, лечил людей. Когда он умер, его чапан – верхнюю одежду хазрата – местные жители и паломники разрезали на кусочки и хранили как реликвию и оберег. Умер он в возрасте 85 лет и похоронен на кладбище аула Онар.



*Надмогильный камень Ибрагим хазрата. Кладбище деревни Тармакуль*

Мои прадеды, начиная от Яуды хазрата, были священнослужителями в ауле Кошкуль, где построили мечеть и

медресе. Отличались большим умом и невероятным трудолюбием. Были богатыми людьми, богатырями и долгожителями. А Салимжан дожил до 117 лет, в годы гражданской войны к нему с почтением относились и белые, и красные. От его имени произошла фамилия Салимзяновых. Он жил в ауле Кошкуль.

Прадедушка Гильман в 7 лет поехал учиться в д. Курупкаевка Барабинского района. Учился в медресе на муллу, знал арабский язык. После учебы тоже стал муллой в ауле Кошкуль. У Гильмана было 9 детей, шестеро из них умерли в детстве, троих он воспитал: бабушку, дядю Анаса и дядю Абдрахима. Умер в 96 лет.

Моя бабушка Абдушева (Салимзянова) Гайниамал Гильмановна родилась 12 мая 1928 года. Ее детство и юность пришлись на тяжелые годы войны. Когда началась война, бабушке было 13 лет. В сентябре 1943 года пришла повестка Мустафиной Ганифе и моей бабушке. В повестке было написано: взять продовольствие на двое суток и личные вещи. Куда везут и зачем, им сразу не сказали. Двое суток они задержались в Чанах; так как пассажирские поезда были заняты ранеными. Затем их вместе с другими подростками отправили в товарном поезде в Новосибирск. Оттуда отправили в Кривощеково в ФЗУ. Там накормили и отправили в баню. Затем их переодели в черные юбки и зеленые гимнастерки.

Полгода они учились работать на станках, после этого начали делать гильзы. Работа была тяжелая. Бабушка была невысокого роста, поэтому под ноги она ставила ящик. Затем ей ребята смастерили специальную скамейку. Качество гильз проверяли мастера. Но ребята старались не подводить их, и брака почти не было. Ведь все понимали, что это надо для фронта. У каждого из них кто-нибудь воевал.

В апреле 1944 года бабушка вернулась домой. И сразу начала работать в колхозе. Однажды приехал мастер, который с ними работал на заводе, и хотел ее снова забрать. Но в колхозе тоже были нужны рабочие руки, и бабушку не отпустили.

Сейчас бабушке 80 лет. У нее 7 детей, 13 внуков, 3 правнука. Кровная нить Салимзяновых продолжается. Составить родос-

ловное дерево мне помогли рассказы бабушки, мамы, сведения о нижегородских корнях собрала моя тётя Абсолямова Мунира Анасовна. Она побывала на родине предков Чембилее. Изучать родословную – дело очень интересное и полезное. Я многое узнала о своей семье, родне и горжусь своей родословной.

## Из истории города Куйбышева (Каинска) и его округи. Татарская община

Наш город и район – многонациональный: русские, украинцы, белорусы, татары, поляки.

Татары занимают особое место: часть из них – коренные жители Барабинских степей, называли их бараба, часть – приезжие, из приволожных, а все сейчас называют татары, по вероисповеданию – мусульмане. Город наш назывался до 1935 г. Каинск. Каин – это татарское название березы. А сколько татарских названий сохранилось: река Омь и аул Омь, аул Бергуль, аул Шагиры, деревня Кульча, Иткуль, реки Тара, Ича, Тартас, озеро Чаны, Сартлан. Названий татарских очень много.

О сибирских барабинских татарах упоминается с XIII–XIV веков. А Казанские, Оренбургские татары появились вместе с русскими переселенцами. Земли в Сибири было много, в озерах рыбы, в лесах зверей. Селились кто где хотел, поближе к воде. Селились и отдельными деревнями и рядом с сибирскими татарами. От сибирских татар научились ловить рыбу, охотничать. А сибирские научились сеять хлеб, возделывать огороды, косить сено. Перенимали друг у друга обычаи, культуру. Пошли смешанные браки, язык, песни, пляски. Стала у всех одна вера – ислам. В трех деревнях были построены мечети.

В нашей Сибири все народы живут дружно, сообща трудятся на предприятиях, на полях. Называют себя сибиряками, вместе и в радости, и в горе. Вместе шли защищать Родину от врага. В числе 5 тыс. погибших в ВОВ более 120 татар. Их имена запечатлены на пилонах мемориала памятника. Многие оставшиеся в живых вернулись домой. Началась мирная жизнь. Кто начал работать, учиться. Никто не опозорил имя фронтовика.

1. Уздимов Нургали Ахмедович, защищал г. Москву, участник первого парада победителей. Умер 2/II – 2004;
2. Якупов Ахмад-Гали Хубаевич. Инвалид войны по ранению. В 1940г. был призван в армию, служил в Ленинграде, войну встретил там. В 1944г. был тяжело ранен (потерял ногу и часть черепа). Был демобилизован. Вырастил четырех детей. В свои 89 лет сохранил организационные способности. Его хорошо знают татары города и района, к его советам прислушиваются.
3. Писарева Сакиня Гильмитдиновна, участница войны с Японией. После войны работала мед. сестрой в инфекционном отделении. Была очень доброй, уважаемой, отзывчивой жительницей нашего города. 2 сына. Умерла 22/ II – 2004г.
4. Шафиков Мугалим Зарифович. Участник войны с Японией. Уважаемый, глубоко верующий мусульманин. Вырастил 5 сыновей. Сейчас воспитывает внуков.
5. Азиханов Сайфутдин Динмухамедович. Участник войны с Японией. Всю свою трудовую жизнь проработал шофером. Вырастил троих детей.
6. Аюпов Абрахман Каюмович. Воевал на ленинградском фронте. Умер 5/XII – 2002г.
7. Сунаров Сабир Назретинович. Был и репрессирован и на фронте воевал. Много наград. Был в числе передовых работников АЗЧ на доске Почета. Хороший отец, уважаемый сосед. Умер в 1974г.
8. Гизатулин Ахмет-Хабиб Зарифович. На фронте рядовой, наводчик, автоматчик. Награжден орденом Красной звезды. Награда нашла его в 1974г. Был большой слет комсомольцев и бывших первых комсомольцев г. Каинска. Это было 29 октября 1979 г. в ДК им. Куйбышева и 65-летнему А.-Х. Зарифовичу вручили заслуженную награду.
9. Большим почетом и уважением пользовались 2 брата фронтовика Гайфула и Гайеса Мухаметдинычи Гизатулины, прекрасные семьянины..

10. Все мы помним нашего муллу Губайдуллина Ахуньяна Рахматулловича, был добрейшим, порядочным и отзывчивым человеком. Перед войной умерла жена и семерых детей поместили в детский дом, ушел воевать. Воевал, был в плену. Вернулся с войны, собрал детей, создал семью. Находил добрые слова для людей, посещал больных, старых.
11. Нигматулин Ахмет Хисмович. Фронтовик, отец большого семейства, шоферил всю жизнь. Умер в 1993г.
12. Хамидулин Гиннилтум Найбулович. Воевал, ранен, остался без ноги. Вернулся, работал. Воспитал сына, мастера спорта. Умер в 1983г.
13. Вернулись два брата Вахрутдиновых, 2 брата Алямишных, 2 Темиргалиевых. Абдулла Хамидулович Туганаев был в плену, за что был осужден. Гали Чуханов не долго трудился после возвращения с войны, умер в 1956 г. В живых осталось в городе 3 фронтовика, умерли в городе Куйбышеве и похоронены на татарском кладбище.

В городе до ВОВ проживало 15 – 20 семей, из них местных татар 4 – 5 семей. Муллы и мечети в городе не было. Мужчина, знающий Коран и молитвы, обряды, читающий по-арабски, становился муллой.

Мои дедушка и бабушка приехали из Оренбургской губернии на строительство железной дороги. Сначала приехали в Новониколаевск, а потом в 1893 их направили в г. Куйбышев на постройку ветки Каинск – Барабинск, ехали на лошадях, с ними ехали моя прабабушка и шестеро детей. А всего было у них 12 детей. Жили они в своем доме по ул. Вокзальная. Это в районе Первомайского сквера, где 10 квартал, дом 13. Улица была односторонняя, смотрела на юг, впереди большая базарная площадь, там проходили знаменитые ярмарки, цирковые представления. В 1917 г. была построена ветка. Два сына дедушки работали на строительстве железной дороги. Оба участники русско-японской войны, были в окружении, блуждали по дебрям, но вернулись домой живые, но больные. Дед коновалил. Мама родилась в 1897г.

девятая. Работал дед и у Купчихи Шкроевой. Очень была она доброй, сердобольной, а когда в 1906г. открыла церковно-приходскую школу, то упрашивала дедушку отдать детей учиться, хоть бы парней. По воспоминаниям соседки Матвеевой дети были здоровые, красивые, но очень бедные. Вечно у них останавливались проезжие татары. Бабушка с дедушкой еще воспитывали брошенных голодных детей. Я помню двух сестер башкирок, одну цыганочку. В городе в начале XX века было 5–6 семей татар. Девушки выходили за приезжих солдат. В городе был купец Султанов, жила русская, лавочка была в полуподвальном помещении, рядом с домом Курниковых, напротив Соборной мечети. В 1918 году была страшная эпидемия тифа (сыпного и брюшного), умирало много городских, хоронили на кладбище, а приезжих и из округи сжигали в печах и ямах Кир. завода. За одну неделю схоронили Абдикашевы 4 мужчин: 3 сына, а дед был сбит лошадью, когда занимался похоронами. Умирали и взрослые, и дети. Остались в живых сын Карим, 3 дочери и кое-кто из малышей. Мама моя вышла замуж в 1922 г. за солдата. Отец – казанский татарин воевал против Колчака, оставлен был в городе для охраны. Мама родила: 5 дочерей и сына. В городе в то время было очень много евреев и поляков. Город называли еврейским. Но распрей не было, жили дружно. Я родилась в 1923 г. и помню татар с малолетства. Все праздники и посты, свадьбы справляли вместе. Это Вахрутдиновы, Хамитовы, Рахимовы, Хамзины, Абдикашевы, потом Бахрачевы, Хамидулины, Мухамедзяновы, Азаковы, Даутовы, Темиргалеевы. Особенно культурной была семья Мухометшиных, жили в четырех комнатах, приглашали нас детей в гости.

Много для татарской диаспоры сделали Хамзины, Азаковы, Темиргалеевы, Рахимовы. Они были грамотны и по-русски, и по-татарски, читали и писали по-арабски, знали Коран, молитвы, ритуалы. Собирали татар, молодежь, пели песни, читали стихи.

Азаков Гариф Сулейманович, его жена Зайнап апа, он умер в 1985г. Эта семья до сих пор в памяти не только татар, но и русских.

До самой смерти был как бы старостой. Жил в старом доме по Коммунистической улице напротив Кометы. К нему за советом, за помощью шли городские и из района, даже из Барабинского; самовар не сходил со стола. Следил и за состоянием татарского кладбища, сообщал о посте, праздниках. Первый день праздников собирал татар у себя, вел учет татар в городе, держал связь с муфтиатом Уфы. Очень был тактичен, не навязчив. Читал молитвы, учил татарским обрядам. Руководил похоронами. Под его руководством нарезали новое татарское кладбище вместе с Хамитовым, Якутовым, Бахрачевым. Но муллой себя не провозглашал.

В 1935 году в город и район приехало много казахов из северного Казахстана. Поселились они в основном по ул. Степной, Пугачева. Одна семья по ул. Некрасова сначала жила в землянке. Огородов не было, держали коров, овец, пасли скот, в одной семье был верблюд. Быстро подружились с татарами, соседями, жили дружно, честно. Постепенно казахи обжились, построили жилье, работали на производстве, дети учились в школе и неплохо. Много мужчин воевали, из них 9 погибло. В данное время проживают 3–4 семьи. Один казах Таубельдинов награжден орденом Трудового Красного Знамени. После войны переехало много татар из деревень, особенно из Убинского района, в городе требовались рабочие руки. Это – Гизатулины, Якуповы, Нигматулины. Много стало смешанных браков: татар и русских.

Приезжие татары строили себе добротное жилье. Мужчины многие работали шоферами, большая часть строилась в Мошнино. Семьи были и у старожилов, и у приезжих большие. О каждой семье можно писать книги.

1) Семья Хамитовых. Жили они до гражданской войны здесь. В семье было 3 то ли 9, то ли 10 детей. 3 раза он строился, т.к. семья разрасталась, и еще жили с ними старики. Во время войны сын и дочь воевали. Сам Хамитов был всю жизнь как староста татарской общины. Следил за состоянием сначала старого, а потом в 1955 нового кладбища, организовывал засыпку дороги, очищение рва. Купил металлический гараж для хранения инвентаря. Был очень добрым, общительным. На данное время живет в городе. Дочь Зайтунэ Сафина.

2) До войны жили семьи Хамзиных. У Карима было 4 детей. 2 сына и дочь. Воевали. Рашид погиб на фронте, Мурат и Муртида были на фронте как врачи. Последняя тоже врач, живет в Омске.

3) Большая семья была Темиргалеевых. Дочь и три сына были на фронте. Фаим погиб. Семья была очень дружная, грамотная и гостеприимная.

4) Бабушку Халиму Рахимову помнят хорошо татары, знала арабское письмо, все татарские ритуалы, обычаи и обучала молодежь, она – родная сестра Азакова.

5) Вахрутдиновых. Хамидулиных. Два брата Вахрутдиновых – Камалитдин и Имамишдин воевали. Жена Имамишдина Минсурур почти всю трудовую жизнь проработала на АЗЧ в литейном цехе. Ее ценили за добросовестный труд. Была часто на Доске почета.

6) Таубельдинов Маман Айтмагатаевич, 1929 г. (казах). Ветеран труда. В 1931г. семья из Павлодара приехала сюда. Работал во время войны в откормочном, потом на водоканале до пенсии слесарем. Стаж 45 лет. Награжден орденом трудового Красного Знамени, многократно победитель соцсоревнований, много грамот и других наград. Жена Нагима, 5 детей.

7) Юнусова Насиха Лизхаматьяровна. Родила шестерых детей. Мать – героиня. Награждена орденом Трудового Красного Знамени за добросовестный труд на птицеводе, ударник коммун труда. Бронзовая медаль от ВДЫХ. Ветеран тыла. Множество наград и поощрений. Осталась вдовой в 1975г. Вырастила детей одна. Старший сын Хисматулла был 2 раза на Чернобыле по ликвидации аварии. Ахмадулла служил на флоте. Одна дочь работала на швейной фабрике, другая на предприятии. Внуков 5, внучка одна. Остальные все работали. Дети и внуки не оставляют ее без внимания.

8) Вахитовы Насибулла Хамидуллович и Рагина Сабировна женаты уже 50 лет. Уезжали жить в Казань. Прожили там 37 лет и вернулись на родину. Уезжали молодыми, а вернулись уже в возрасте. В Казани Рагину за свой труд связистки наградили орденом

Трудового Красного Знамени. А Насибулла – ветеран тыла. Очень дружная, обаятельная пара.

9) Абдрахмановы Галима и Хамза. Галима Гарифовна 4 года работает учителем начальных классов в школе №6. Учитель высшей категории. Очень уважаема и в коллективе, и среди родителей. Талантлива, порядочна. Словом учитель от бога.

Хамза Бареевич скончался летом 2005 г. Мастер спорта окончил с/техникум. Служил в армии, увлекался спортом. Стал мастером спорта по лыжам. Был физруком в с/техникуме, а потом инструктором по лыжам в спортивной школе. Много наград и поощрений.

10) Азиханова Марзия Абударовна, 1938г. рождения. В наш город она попала грудным ребенком, отца репрессировали, мать с ребенком уехала в Сибирь. Жить было негде. Мать со старшей дочерью своими руками слепила землянку на степной улице, рядом жили казахи, а после войны так же «построились» на Достоевского. Очень тяжело было жить: голод, холод, далеко от школы. Марзия упорно училась, работала, вышла замуж, приобрела специальность. Почти вся трудовая жизнь прошла в управлении Сибирской дорогой. Построили свой дом. Муж шоферил. Воспитывала сына. Рано осталась вдовой, сын то же шофер. 2 внучки, внук и три правнука. Вела большую общественную работу, наград и поощрений много.

Прекрасно знает татарский язык, поет, читает стихи, знает и соблюдает татарские традиции. Член правления татарского культурного центра. Двери ее дома всегда открыты и для друзей, соседей.

Почетный донор, не теряет связь с любимым предприятием. В 2002 г. на фестивале в Новосибирске (татарское искусство) стала дипломантом, получила благодарственное письмо и ценный подарок за исполнение народных татарских песен.

11) Династия Якуповых. Асма-апу знают не только татары, но и соседи, жители города. Ей далеко за 80, но бодрая, гостеприимная, память хорошая. Асма-апа – это глава рода Якуповых. Муж ее Самигулла был муллой, его уважали и дома, и соседи, и на ра-

боте. Семья Якуповых была большая, вырастили 4-х дочерей и 3 (?) сыновей. Асма-апа – мать-героиня. 2 сына умерли. Камиль работал шофером. С женой Альфиёй вырастили дочь и 4-х сыновей. 20 сентября 2003 г. Камиля на общем собрании татарских общин единогласно избрали имамом. Асма-апа знает арабскую грамоту, читает Коран, знает много молитв, ритуалы. Научила этому внука Ильяса. Жена Галипа (ныне покойного) много лет работает директором магазина «Мелодия». Флюра Зиннуровна пользуется авторитетом. В магазине хороший сплоченный коллектив. Часто помогает материально клубам и другим мероприятиям. Дочке и сыну дала образование. Хорошая хозяйка. Любит готовить и угощать. Часто наведает и помогает свекрови.

12) Нигматулины Ахман Заки и Гатия-апа. Сам Нигматулин участник ВОВ. Умер в 1993г. Похоронен на татарском кладбище. Родом из Кочемки. После войны с семьей переехал в Куйбышев, работал шофером, один из лучших работников автохозяйства. Жена Гатия-апа работала и на ж/дороге и техничкой в МСЧ КХЗ. Медики и больные ее обожали. Трое детей, да еще совместно родили семерых, Гатия-апа – мать-героиня. Оба они были глубоковерующими. Воспитывали у детей доброту. Веровали. Трудолюбивые, один из сыновей до пенсии работал в Новосибирске в милиции (Талип). Шамиль окончив институт, работал много лет в хлебопечном предприятии директором. Дочь Асия сейчас директор СПТУ-88. Сын Муршид шоферит.

13) Многочисленным были 2 семьи Хамидулиных. В семье Найдулы было 2 сына, 5 (6?) дочерей. Сам глава воевал в I мировой войне. Имел тяжелое ранение. Работал частным извозом, а жена лечила пиявками. Сын их Гиниатула участвовал в ВОВ, потерял ногу. Работал в утильсырье. Воспитывал сына, мастера спорта Хамидулина Гафура, в честь которого (он умер в 1983г.) проводятся спортивные соревнования. Он был гордостью педколледжа.

14) Гизатулины Гайфула Мухаметдинович и Ркия-апа. Их дом на Кутузова № 62. Г.М. – участник ВОВ. Они жители Северного района, потом семья переехала в Куйбышев, до самой пенсии работал зав. складом кожсырья. Ркия-апа начала работать до войны.

Во время войны работала и рабочим, и бригадиром по заготовке сырья стратегического значения. Мать-героиня, 7 детей: 2 сына и 5 детей. Ркия-апа знала арабскую грамоту, читала и переводила. Обучила и двух дочерей. Была верующей, доброй, справедливой, гостеприимной. Гизатулин Г.М. умер в 1986г., Ркия-апа в 2003г. Детям они дали образование. Сама Ркия-апа писала стихи. Дочь Наиля, ныне покойная, была журналистом много лет в газете Трудовая жизнь. Статьи ее были правдивы, интересны. Писала хорошие стихи. Ее ценили работники редакции. Несмотря на изнурительную болезнь, была оптимистична, трудолюбива. Аклима прекрасно рисует. Галлия тоже талантливый художник-оформитель, умеет читать по-арабски. Нажия – прекрасная, с удивительным вкусом рукодельница, кулинар, читает по-арабски.

Смерть Ркии-апы лишило татарскую общину глубоко-верующей, выдержанной, здравомыслящей мусульманки.

15) Гизатулины Гайса Мухатинович и его жена Раиса-апа. Гайса Мухатинович – участник ВОВ, умер в 1996 г. Похоронен на татарском кладбище. Остался вдовцом, остались без матери 7 детей. Раиса-апа не побоялась, вышла за него замуж. Еще родила 2 детей. Семья была трудолюбивая, воспитанная.

16) Гизатулин Махмуд Зарифович. Приехал в город в 1956 г. Шоферил. В семье было 5 детей. Ныне живут здесь. Дочери Муслима, Холида и сын Хасин.

17) Семья Нигматулиных – Шафиковых. Это - четыре семьи в одной семье. Все они живут близко друг от друга. Во главе этой семьи Мугалим Зарифович Шафиков, участник ВОВ. У него умерла жена, остались 5 детей в школьном возрасте. А у Макзумы Нигматулиной умер муж. Тоже трое детей, три дочери. Вот соединили свои судьбы Макзума и Мугалим. Все дети уже обрели свои семьи, есть внуки. Наиля, Мойра и Галия имеют образование. Галия нынче (2005г.) окончила ФНГПУ по специальности психологом, что очень нужно по ее работе. Она работает в соцзащите. Сыну Салавату 10 лет, занимается в спортшколе, поет, читает стихи на татарском языке. У Наили сын Марат, учится в школе. У Майры старшая дочь окончила с отличием педуниверситет,

работает в Новосибирске, вторая с медалью закончила, учится в педуниверситете. Ведут все общее хозяйство, корову, кур. Гостеприимны. Хорошо знают татарский язык. А дед читает молитвы, учит этому и внуков. Ленивых в этом роду нет, честны, порядочны.

18) Аптрашитовы. Муж – Салих Абдулович. Жена – Раиса Галиакпаровна. Пятеро детей. 2 дочери и 3 сына. Глава семьи работает в энергомонтаже. Раиса временами работает на разных работах. Старший сын Альдар служил в Чечне. Работает охранником в Новосибирске. Салим учится в политехникуме. Саяр учится в 9 классе школы № 2. Оба спортсмены, активные участники в состязаниях и школы и труда. Зайжуня закончила медучилище. Работает медсестрой в больнице. Зухра закончила 11 классов. Учится и работает в Новосибирске. Это скромная, дружная семья. Дом не большой, средств маловато, но родители не стесняют детей. Девушки – активные участницы, татарские самодеятельницы, рукодельницы.

19) Семья Тимгановых. Глава семьи Темирбулат трагически погиб. Мама Танзиля работает почтальоном. Четверо детей: 3 сына и дочь. Живут в своем доме.

Темирбулат был очень талантливым: и рисовал, и конструировал, писал, учил иностранные языки, играл на гармошке. Участвовал в создании музея аул Бергуль. Написал книгу о г. Куйбышеве, сам фотографировал. Сделал макет мечети и другие поделки. Это был удивительный человек. Танзиля Исатуловна неунывающая женщина, везде успевает: и дома, и на работе, шьет, вяжет, варит, печет. Хорошо танцует, участвует во всех наших мероприятиях.

Дети хорошие. Старший сын 2 раза был в Чечне, второй тоже был, сын и дочь кончили ГПТУ-8. Как художники-оформители, оба талантливы. Дочь хорошо поет, у неё умелые руки.

20) Семья Абдрахмановых. Глава семьи Чагафар Хисатович. Хозяйка Каусар Халиуловна. Оба работают. Он – дежурный слесарь «Олимпа». Она – нянечка в садике «Звездочка». Очень дружная семья. Детей трое. Дочь Дина окончила школу № 9

с медалью, педуниверситет, факультет иностранных языков с отличием. Работает в Новосибирске. Сын Закир закончил школу с медалью, потом селькохозяйственную академию. Играл в духовом оркестре. Младший Зиннур учится в 11 классе (хорошо), учится в музыкальной школе (Кларнет), играет в духовом оркестре, поет. Одаренные дисциплинированные дети. Родни у Абдрахмановых много и в Сибири, и в Казахстане. Живут в двухкомнатной квартире, но гости все время. Каусар хорошо готовит, рукодельница, любить петь (хороший голос). Зиннур на фестивалях татарской самодеятельности в Новосибирске был лауреатом.

На каждое мероприятие приходили большие группы из училищ, школ, техникумов на встречи ветеранов войны и тыла. Каждому вручен подарок, а того кто не ходячий, отвезли домой. Не забыты были и матери-героини.

Очень хорошо прошел день Татарской кулинарии. Участвовало 14 женщин, приготовлено 24 разнообразных блюда. Сначала было 2 группы Кулинарного училища, а потом пришли дети-сироты (30 учащихся из интерната). Было им чаепитие. Участвовали и работники администрации и спонсоры.

На спортивное мероприятие пришли студенты-татары из физкультурного отделения педколледжа (30 уч.). Принесли фотографии, вырезки из газет. Все было красиво оформлено. Выступала о своем муже, мастере спорта Хамзе Абрахманове Галима Г., о мастере спорта Хамидулине Г.Г. Ирена Заикина.

Очень интересно провел встречу бывший работник газеты «Трудовая жизнь» Быков И.И. Подобрал большой материал для сборника стихов и воспоминаний о ныне покойном Наиме Гизатулине, читал стихи, звучала музыка. Об этой удивительной семье Гизатулиных мать тоже писала стихи на татарском языке. Хорошо стихи прочел свои Н. Вахитов, А.М. Азиханова пела и читала стихи Тукая, Джажиля.

26 октября было посвещено удивительному человеку (ныне покойному) Темирбулату Тимганову (тетрадь с записями его жена отдала в музей). Для студентов было откровением узнать о таком

талантливом краеведе, художнике, мастере на все руки, самостоятельно изучившим арабский, испанский.

31 октября было закрытие. Всем было жалко закрывать выставку и расставаться с музеем.

Всем участникам выставки вручены благодарственные письма. На выставке побывало очень много народу.

*Численность татар в г. Каинске по переписям*[107]:

1897г. Всего населения в городе 5884. Из них татар 29 человек:14 мужчин,15 женщин. Это 3-4 семьи. Семья Абдикашевых – семья моего деда – состояла из 15 человек, 12 детей.

К 1913г. Мусульман 35 человек. Мужчин – 27, женщин – 8. Всего населения 5882.

К 1959г. Всего населения 30 380 человек. Татар – 574 человек. Это 1,89% от всего населения.

До 1970г. Количество жителей в городе 40 116. Татар 719 человек. Это 1,79% от всего населения.

К 1979г. Население 47 011, татар 904 человека.

К 1989г. Более 50 тысяч татар 968. 1,93% к общему числу населения.

На данное время (2005) около 1000 человек. В деревнях:

Аул Омь ~ 635 человек;

Аул Бергуль ~ 650 человек;

Аул Шагири ~ 350 человек;

деревня Кульча ~ 50 человек.

## Искәрмәләр

**Нурмөхәммәд Ибраһимов сәяхәте.** Бу сәяхәтнамә тумышы белән Новосибирск өлкәсе Арамсаз авылы кешесе Нурмөхәммәд Сибгатулла улы Ибраһимов (? – 1978) тарафыннан 1959 елда язылган. «Нурмөхәммәд Ибраһимов сәяхәте» дигән исем безнең тарафтан бирелде. Әлеге сәяхәтнамә һәм башка язмалар урын

[107] Демографические данные приведены из книги: Бурматов А.А. Демографическая история Каинска-Куйбышева и его округи. – Новосибирск, 1997. – 160 с.

алган кулъязма бүген Нурмөхәммәд Ибраһимовның кызы, Новосибирск өлкәсе Бараба районы Бакчагөл (Новокурупкаевка) авылында яшәүче Бибинур апа кулында саклана.

**Бараба җиренә күчкәндә.** Шигырь Новосибирск өлкәсенең Чаны районы Кошкүл авылы Мәдәният йортында сакланачы кулъязмадан күчереп алынды.

**Кулларыма алдым...** Шигырь Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Омаул (Осинцево) авылында гомер сөргән Хәмидә Габденнәфыйк кызы тарафыннан язылган кулъязмадан күчерелде. Гади дәфтәр битләренә язылган бу кулъязмада аерым бер догалар, Коръән сүрәләре, шигъри текстлар һәм 1987 елда туганнарына адресланган бер хат урын алган.

**Хәмдениса бәете.** Бәет Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Омаул (Осинцево) авылында гомер сөргән Хәмидә Габденнәфыйк кызы тарафыннан язылган кулъязмадан күчерелде.

**Манара мөнәҗәте.** Мөнәҗәтнең авторы – Новосибирск өлкәсе Арамсаз авылы кешесе Нурмөхәммәд Сибгатулла улы Ибраһимов. Текст Нурмөхәммәд Ибраһимовның кызы, Новосибирск өлкәсе Бараба районы Бакчакүл (Новокурупкаевка) авылында яшәүче Бибинур апа кулында сакланучы кулъязмадан күчерелде.

**История моего рода.** Автор текста – ученик Аулкошкульской основной общеобразовательной школы Чановского района Новосибирской области Ибрагимова Алия Рашидовна. Текст был записан 2008 году.

**Из истории города Куйбышева (Каинска) и его округи.** Воспоминания Дубровской (Зариповой) Галины Гарифовны о татарской общине города Куйбышева (Каинска). Текст любезно предоставлен директором МКУК «Музейный комплекс» города Куйбышева Новосибирской области Павловой Натальей Иннокентьевной.

*Текстларны басмага Илһам Гомәров әзерләде*

## «АК КҮБЕК» дастаны

*Илсөяр Закирова*

Иҗат ителүе белән Алтын Урда чорына нисбәт ителгән «Ак Күбек» дастанының фәнгә өч варианты (тубыл, бараба, алтай) һәм хакас (абакан татарлары) вариантының өзеге билгеле. Алар барысы да академик В.В. Радловның «Образцы народной литературы тюркских племен» исемле ун-томлыгында дөнья күргән. Дастанда бәян ителгәнгә якын вакыйгалар атаклы гарәп сәяхәтчесе Ибне Халдун (1332–1406) китабында[1], Мисырда яшәгән Ән-Нувәйри (1279–1333) энциклопедиясендә дә бәян ителә.

Ак Күбек турындагы вакыйга Ән-Нувәйри энциклопедиясендә Алтын Урда дәверендә чынбарлыкта булган хәл, тарихи вакыйга буларак тасвирлана. Бу хезмәттә Ән-Нувәйри кыпчакларның унбер кабиләсен искә ала. Аларны Чыңгыз хан гаскәре яулап ала, әмма 616 елда монгол гаскәре киткәч, бу кабиләләр яңадан элеккечә тынычлап яши башлыйлар. Бу 626 елга кадәр шулай дәвам итә. Бервакыт дурут кабиләсеннән Көтән улы Мангуш ауга чыга. Анда токсоба кабиләсеннән Аккүбел белән очраша. Ике кабилә арасында күптән килгән дошманлык сәбәпле, Аккүбел Мангушны әсирлеккә ала һәм үтерә. Әтисе, Мангуштан хәбәр булмаганга борчылып, Ќамгарь (яки Ќалангар) дигән кешесен җибәрә. Ул кеше, кире кайтып, Мангушның үтерелүе хакында сөйли. Мангушның әтисе, гаскәр җыеп, Аккүбелгә каршы яу белән килә. Ике кабилә арасында бәрелештә Аккүбел яралана, сугышчылар тарала. Аккүбел абыйсы Ансарны (Унсарны) Чыңгызханның улы Душиханга ярдәм сорарга җибәрә. Абыйсы үзләренә дурут кабиләсе һөҗүм итүен сөйли, әгәр дә хәзер Душихан аларга яу белән килсә, дурутлардан башка беркем дә каршы тормаячагын әйтә. Душихан, гаскәре белән килеп, дурутларны тар-мар итә. Күпчелеген әсирлеккә ала[2].

---

[1] Тизенгаузен В. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. т.I. СПб., 1884. С. 641.

[2] Шунда ук. С. 641.

Ән-Нувәйри 1279 елның апрелендә Мысырда туа. 1333 елда Каирда үлә. Гомеренең күпчелек өлешен фәнгә багышлый. 30 томлык энциклопедия төзи. Хезмәтнең тарихка багышланган өлешендә Алтын Урда һәм мәмлүкләр солтаннары тарихы буенча да мәгълүмат бирелә.[3] В.Тизенгаузен Ак Күбек турындагы хикәятнең Ибне Халдун хезмәтендә дә булуын әйтә. Мангуш анда Манкыш Китмир улы дип, Аккүбек – Акакибәк, Ансар – Аксар дип бирелгән. Дурутларның кыпчак, ә токсобаларның татар булуы аңлашыла.[4] Ибне Халдун галим, өлкән кади була, XIV–XV гасырда яши. Алтын Урда турында да мәгълүматлар тупланган тарихи хезмәтен 1406 елда яза.[5] Ән-Нувәйри энциклопедиясендә бәян ителгән вакыйгада кабиләара ызгышлар тасвирлана. Кыпчак кабиләләренең үзара дус-тату яшәмәве аларның монголлар тарафыннан җиңелүенә китерелүе күрсәтелә. Ибне Халдун хезмәтендә исә кыпчаклар белән татарлар арасындагы конфликт тасвирлана.

«Ак Күбек» дастанының В.В. Радлов тарафыннан бараба, тубыл татарларыннан һәм алтайлылардан язып алган вариантларының нигезендә шушы ук геройлар турында сүз бара. Әсәрнең һәр вариантында аның борынгылыгын күрсәтүче шигъри өлешләр күп сакланган. Аларның кайберләре бер варианттан икенчесенә кергән, икенчеләре исә һәр вариант өчен үзгәләр. Дастанның сюжетында традицион мотивлар барысы да диярлек очрый — геройның могҗизалы тууы, исем алуы, ат сайлавы, корал барлавы, дошманнар белән көрәше.

Дастанда ыру-ара ызгыш-талашларның яхшылыкка китермәве күрсәтелә, бердәмлек идеясе күтәрелә. Ән-Нувәйри һәм Ибне Халдун вариантларында төрле кабиләләрнең монгол тарафыннан яулап алынуының, тар-мар ителүенең сәбәбе итеп аларның үзара дошманлыгы күрсәтелә.

Әсәрдә халыкның гореф-гадәтләре, ышанулары белән бәйле күп кенә эпизодлар бар. Себер татарлары ислам динен XIV гасыр

[3] Тизенгаузен В. Сборник материалов. С.129.

[4] Шунда ук. С.541.

[5] Шунда ук. С.365.

ахырында кабул итәләр. Ә бараба татарларына ислам XVIII гасыр урталарында гына керә. Әсәрдә исламга кадәр чорны чагылдырган күренешләр, мәсәлән, җада (дьада), камчы белән дәвалау, терелтү мотивлары саклана.

Әсәрнең игътибарыгызга тәкъдим ителә торган варианты академик В.В. Радлов тарафыннан хәзерге вакытта Новосибирск өлкәсенең Каргат районына карый торган Тәрәнә авылында язып алынган. Әсәрнең теле, бараба татарларының сөйләм үзенчәлеген саклаган хәлдә, барлык укучыларга аңлаешлы итү максатыннан, беркадәр әдәби телгә яраклаштырылды. Шулай да гаҗәеп аһәңле бу сөйләшкә караган сүзләрне сүзлек белән биреп барырга омтылдык.

## АК КӨБЕК
### *(бараба варианты)*

Инәсенең карнында Ак Көбек йөрде, туар вакытына җитте. Җиңгәләре килде инәсенә, урнына инәен урнаштырдылар. Ак Көбек инәсеннән тумады, таң калдылар. Инәсенең карнында Ак Көбек сүләшеп торды: «Мин тумаймын бу юлыңнан, карынның бер ягыннан җыртып чыгармын!» – диде. Җиңгәләре әйтте:

Алтын бишеккә бер салып
Биләр идек Көбәйне,
Көмеш бишеккә бер салып
Биләр идек Көбәйне.

Инәсе әйтте баласына: «Балам, син Ходайның яраткан юлыннан чыкмасаң, минем ризалыгым юк». Ак Көбек аннан соң Ходай яраткан юл белән туды. Торды, атасының кылычын толымына бәйләде, ялангач күлгә аулап, балык тотарга китте. Бер үзәнгә барып төште, бер амыцка үзәннең янында балык тотарга ята. Ак Көбек аңа килде.

Кара әле, кара әле, таз-ай!
Сулар төбен күргән таз-ай!
Бер балык тоткан таз-ай!
Инәм инәмгә изүлек-ай!
Инәм инәмгә изүлек-ай!

Бер чабак сорады. Амыцка орышып җибәрде аны: «Фу, кит бу җирдән, сиңа бирергә һич нәрсә балыгым юк», – диде. Ак Көбек үзән белән йөреп китте, анда барды, тагы бер балык тотучы амыцкага җитте. Ул амыцканың янында бер цортанак ятадыр. Ак Көбек аңа килде, әйтте:

Кара әле, кара әле, таз-ай!
Сулар төбен күргән таз-ай!
Бер балык тоткан таз-ай!
Инәм инәмгә изүлек-ай!
Инәм инәмгә изүлек-ай!

Карт әйтте: «И балам, ал бу балыкны ялгыз булса да». Бала бу балыкны алды, капчыгына салды, кайтты кире. Көз вакыт иде, су тонган икән, бер сулыкка Ак Көбек карап күрде, кыдыс кыдысны куып йөри, чуртан чуртанны куып йөри, аны күрде Көбек. Аны күреп, Көбек әйтте: «Суда балык яу кубара», – диде: «Мин монда тудым, адәм булып мин дә яу күтәрим», – диде.

Аннан кайтып йөреп барса, үзәннән кырга чыккан җирдә, Көден хан алты аяклы аргамакка менеп саклап тора. Бая ялангач суга йөргән баланы күреп, Көден хан әйтте бу балага: «Атың кем?» – диде. Бу бала әйтте: «Ак Көбек кеше, синең атың кем?» – диде. Көден хан әйтте: «Атым минем Көден хан». Ак Көбек әйтте аңа:

Көден, көден дәшәрләр-ай,
Атта күрәмен көденне-ай,
Атта күрәмен көденне-ай.
Көденге диеп аталган-ай,
Син дә бер кеше булыпсың-ай.

Ак Көбек әйтте: «Минем атым Ак Көбек», анда Көден хан әйтеп ятты Ак Көбеккә:

Күбек, күбек (дип) дәшәрләр-ай
Күлдә күрәмен күбекне-ай,
Сөттә күрәмен күбекне-ай.
Күбек диеп аталган-ай,
Син дә бер кеше булыпсың-ай!

Ак Көбек атасының кылычын алды, алты аяклы аргамакның бер аягын кисеп алды, Көден хан нәмә белми өенә кайтып китте. Ак Көбек тә өенә кайтып барды, килде инәсенә. Инәсенә Көден хан аргамагының алты аягыннан кисеп алган бер аягын бирде, чуртанны да бирде. Инәсе аларны казанга салып кайнатты. Ашадылар, җыйдылар. Ак Көбек әйтте инәсенә: «Мин менәр ат бармы, инә?» – диде. Инәсе әйтте: «Син минем карнымда йөргән вакытта, бер бия җиленләде унике ай, ул бия инде колынлаган булмак», – диде. – «Аның туган колыны син менәр ат ул булыр». Ак Көбек йөгән бау алды, Ак Көбек үргә китте. Барды. Биядән Кызыл Ор туган. Кызыл Ор биянең биле өстеннән ашыра муйным салып, ар ягыннан имчәген авызына алып имеп тора.

Килде Ак Көбек, Кызыл Орны колактан тотты, йөгәнләде, өенә алып барды, кайтып өендә иярләде, тун-шайларын киде, бер шәһәргә чыкты. Анда алтмыш алты балта урлап алды; бер башка авылга барды, җитмеш җиде балта урлап алды.

Аннан чыгып килеп Кытай җиренә китте, кылыч суга торган оста кешене эзләп йөрде. Анда барып, бер Күцемец атлы остаНы тапты. Балталарны Күцемецнең алдына куйды.

Алтмыш алты балтаны сызгыртып,
Саф булатны калдыргыл!
Җитмеш җиде балтаны сызгыртып,
Саф булатны калдыргыл!
Күцемец оста булсаң,
Ул булаттан кылыч суккыл!

Күцемец оста бер көн, бер төн сукты, кылычны бетерде, Күцемец алты балтаны җуеп яшерде, кылычны алып китерде, Көбеккә бирде. Көбек кылычны кулына алып салмаклады.

Алтмыш алты балтаның ай
Алтысы кайда, Күцемец-ай?
Алтысын ялгап сукмасаң-ай
Башыңны кисәрмен, Күцемец-ай.

Җитмеш җиде балтаның-ай
Җидесе кайда, Күцемец-ай?

Җидесен ялгап сукмасаң-ай,
Башыңны кисәрмен, Күцемец-ай.

Күцемец кайтты, курыкты, алты балтаны кагып кушты, җиде балтаны янә кагып кушты, өч көн суккач, бетереп кылычны алып килде Көбеккә, кылычны кулына тоттырды. Ак Көбек кылычны башыннан тотып салмаклап әйләндерде, көнгә тотты, кояш туклап багып күренде. Ак Көбек бу кылыч(ны) яхшы дип сөенде. Күцемец Көбеккә әйтте: «Кылычны ярар дисәң, инде ял бирмәк кирәк». Ак Көбек торды, Күцемецне мактады:

Сугышына чыдамый,
Сум палгалар[6] уалды,
Басуына чыдамый,
Кап күрекләр ярылды,
Андый минем Күцемец-ай!
Мондый минем Күцемец-ай!

Торга[7] булсын бу җирдән-әй!
Камга[8] булсын бу җирдән-әй!
Ишегеңнән тәк[9] иңсен-әй!
Төнлегеңнән тәк төшсен-ай!
Атың-елкың бай булсын!
Баеп-череп үлерсең!

Бу мактаганнан башка ял бирмәде, кайтты аннан соң Ак Көбек өенә. Дәрья якасына барып, Ак Көбек бер таз тайга менде, бер киез такыяны[10] киде, бер киез тунын киде, малын багып ятты. Анда багып йөргән чагында Самыр Казан Алып Ак Көбеккә килде. Ул Ак Көбекнең карт бабасы иде. Самыр Казан әйтте: «Бу кемнең малын багып торасың, таз кол!» – диде. Ак Көбек әйтте Самыр Казанга: «Ак Көбекнең малын багып ятам», – диде. Самыр Казан алып әйтте: «Ак Көбек үзе кайда киткән?» Ак Көбек әйтте:

---

[6] Палга – чүкеч.
[7] Торга – ефәк тукыма төре.
[8] Камга – ефәк тукыма тере.
[9] Төк – байлык.
[10] Такыя – баш киеме.

«Ак Көбек ялангач бу күлгә кышлагалы[11] китте». Самыр Казан әйтте: «Кичәге көн туып, бүгенге көн минем белән бәхәсләште, минем диңгеземне ул поклап[12] яткан тора», – диде.

Самыр Казан дәрьяның уртасына барып суга утырды, дәрьядан башы гына чыгып калды. Ак Көбек шайларын[13] алды, яхшы туннарын киде, кылычын баглады, атка менде, көн җадалады[14].

Яхшы көндә бер әйтсәм-ай
Көн төшер, Ак Көбек-ай
Яман көндә бер әйтсәм-ай
Көн ярәшер, Ак Көбек-ай.

Бер җиде көн җадалады, җиде карыш боз туңдырды; җиде көн җадалагач, Кызыл Орына менде, кылычын кулына алды, дәрьяның уртасында утырган Самыр Казан алыпка барды, башын кисәргә килде. Самыр Казан аны өргән иде, тау башына ат белән чыгып китте. Янә Ак Көбек Самыр Казанга кире кайтып килде, үтермәкче касланды[15]. Самыр Казан тагы өреп тау башына чыгарды. Өченче кире тагы килде. Самыр Казан әйтте: «Ак Көбек, син алдар хәйләкәрсең, инде мине бу кылыч белән үтерә алмассың. Кире кайтып бар! Кырда кылычым ятыр. Син бу кылычымны ал! Ул минем башымны кисәр». Аннан барып кылычын алып Самыр Казанның башын кисеп китте. Самыр Казан Алып тубулады[16], җиде карыш боз туздырды, боздан Ак Көбекнең малы егылды, кырылды, Ак Көбек үзе тере калды.

Маңгуш алып, Көден ханның улы, үз җирендә төскә[17] чыккан иде, төсләп[18] йөрде, бер ак киекне үтерде. Анда йоклап яткач,

[11] Кышлагалы – кышларга.
[12] Поклау – пычрату.
[13] Шай – корал.
[14] Җадалау – магия ярдәмендә һава торышына тәэсир итү.
[15] Каслану – нәфрәтләнү, үчләнү.
[16] Тубулады – бәргәләнде, тыпырчынды (?)
[17] Төс – урман.
[18] Төсләп китү – ауга китү.

Маңгушның колы киекнең итен пешерер иде. Самыр Казанны үтергәндә боз шаулаганын уктулар[19].

Маңгушның колы әйтте:
Көзгедә бозлар гүләшер-ай,
Ул ни иде, Маңгушым-ай?
Язгыда бозлар шаулашыр-ай,
Ул ни иде, Маңгушым-ай?
Маңгуш уянып башын күтәреп әйтте:
Көзгедә бозлар гүләшер-ай,
Куяклар савыт[20] булмасмы әцәй[21]?
Язгыда бозлар шаулашыр-ай,
Кылычлар белән булмасмы әцәй?

Ак Көбек юыртып килә аларга, Кызыл Орына менеп, мылтыгын салып иңенә, саудагын[22] бәйләп, кылычын тагып, йыдасын[23] турылап сөңгесенең, һәрбер шай белән киләдер, Маңгушның колы Ак Көбекне күрде.

Уң ягында орайган-ай[24],
Су ягында сурайган-ай[25],
Ул ни үзе Көбекнең-ай?
Кызыл Орның пазыгы-ай[26]
Элекке пазыгы әбәс тур-ай [27],
Ак Көбекнең күзләре-ай
Элекке күзләр әбәс тур-ай.

Маңгуш торды, Ак Көбекнең килә ятканын күрде, Маңгуш әйтте:

---

[19] Укту – ишетү.

[20] Куяк савыт – көбә күлмәк. Биредә яу кораллары, көбәләр шавы күз алдында тотыла.

[21] Әцәй – икән.

[22] Саудак – ук савыты.

[23] Йыда – сөңге очы.

[24] Ораю – төз, туры тору.

[25] Сураю – кырын тору, кыегаю.

[26] Пазыгы – басуы, йөреше.

[27] Әбәс тур-ай – имәс, түгел.

Уң ягында турайган-ай
Йыдалар-мылтык булмас микән?
Сул ягында сурайган-ай
Уклар-саудак булмас микән?
Кызыл Орынны пазыгы-ай
Аркасына камчы тигәндер-ай.
Ак Көбекнең күзләренәй
Аракы буза чыккандыр-ай.

Ак Көбек юыртып җитеп киләдер. Маңгуш ягысын[28] керешен салдырырга баскан чакта, ул сынып китте. Ак Көбекнең алдына чыгып утырды. Ак Көбек чабып килде, Маңгушның колы ак киекнең пешкән ботын алып аткан иде, Ак Көбекне җиргә төшермәде, кулы белән тотты, ат өстендә ашады. Килде Маңгушның одауына[29] Көбек. «Аш җыешкан яулашмас, диде, дус булаек! Минем йортыма бараек!» – диде. Чакырып китте. Маңгушның колы өенә кайтты, Маңгуш үзе Ак Көбек белән барды; йортына алып барды, сыйлады арацан-корацан[30] белән, куйлар, үгезләр суеп ашатып ятты аны.

Маңгуш әйтте Ак Көбеккә: «Син миңа кушлугыңны[31] сылагыл[32]». Ак Көбек әйтте: «Юк, җизнә, кушлугымның бәясе кыйммәт».

Кактан[33] какка чабар кушлугым,
Казларның башын чабар кушлугым,
Күлдән күлгә чабар кушлугым,
Үрдәкләрнең башын чабар кушлыгым.

Маңгуш әйтте: «И Көбегем, бу кушлугыңның һөнәре яман икән». Көбек әйтте: «И Маңгуш, син бөркет кошыңны сылагыл миңа!» Маңгуш әйтте: «Юк, җизнә, бу бөркет кошымны сыламаймын, бу кошымның бәясе кыйммәт икән», – диде.

[28] Ягы – җәя.
[29] Одау – шалаш.
[30] Арацан-корацан – сөттән ясалган аракы.
[31] Кушлук – ау эте, кошлар аулаучы эт.
[32] Сылагыл – бир.
[33] Как – күл, сазлык эчендәге утраучык.

Цөдерер[34] яхшы цөдерер-ай,
Кырык бер марал цөдерер-ай,
Цөдерер белмәгән ул яман-ай,
Атыңнын башын цөдерер-ай,
Үзеңнең башын цөдерер-ай.

Көбек әйтте: «И Маңгуш, синең бөркет кошыңның һөнәре яман икән, миңа кошың кирәк түгел, калсын синдә». Аннан соң Маңгуш әйтте: «Кушлугың яман торыр, Кызыл Орыңны сылагыл миңа!» Көбек әйтте: «Кызыл Орымны сыламаймын, аның бәясе кыйммәт тора», – диде.

Кызыл Орым холыклы,
Койган камыш колаклы,
Тустагандай тояклы,
Сарымсактай азулы[35],
Бәясен җиткерсәң алырсың,
Бәясен син җиткермәсәң,
Кызыл Орым калыр үземә.

Аннан куйдылар, аш җыйдылар, арацан-корацан эчтеләр, исерек булдылар. Кичкә төн булды. Маңгуш исереп егылды, Ак Көбек әйтте үзе үзенә: «Бу Маңгушны үтерергә кирәк», – диде. Бау белән баулады. Маңгушны бәйләсә дә, бау өзелде. Бау өзелгәндә, алты яшьле үгезләрнең тиресеннән ясаган каеш арканнар белән бәйләде. Шул ук заманда бәйләгән каешы өзелеп китте, түзәлмәде. Каеш өзелгәнгә Ак Көбек тимердәй богау салды. Маңгуш кыймылдап бирсә, тимер дә сынып китә. Аннан Ак Көбек урамга чыкты бау эзләп. Урамның ул читендә бер ак сакаллы карт кеше килә иде. Амыцка килде Ак Көбекнең катына. Ак Көбек әйтте амыцкага: «Ирне бәйләргә нәрсәнең тиресе чыдам булыр?» – диде. Амыцка әйтте: «Ир бәйләргә ир тиресе яхшы булыр», – диде. Ак Көбек әйтте: «И амыцка, сүзең чын булса, ир тиресе яхшы булса, син тиреңне миңа бир! Ашыңны ашагансың, яшеңне яшәгәнсең». Ак Көбек амыцканың маңгаена чиертте,

[34] Цөдерер – ау кошының табышны тибеп алуы.
[35] Азулы – тешле (азу теш).

үтерде, артыннан телде тиресен, аягыннан телде тиресен, кулыннан телде тиресен. Картның сөяген уалады, пилгеп цыргады[36], тиресе калды. Алып калды бу картның тиресен, Маңгушның кулын кеше тиресе белән бәйләде. Ташлап китте Маңгушны. Кунып йоклап калды, кулы-аягы бәйләгән көйгә кунды. Иртән исерегe сәректе[37], уянды. Үзе бауда ятыр, аны күрде. Ак Көбекнең апасы бар иде, ул кыз Маңгушның янында утырды. Ул кыз күптән Маңгуш белән уйнаш иде, бу кызның аты Көн Сылу иде. Көн Сылу Маңгушны күреп әйтте:

Алтын аякка бал коеп-ай,
Исермәдең, Маңгышым-ай;
Көмеш аякка бал коеп-ай
Исермәдең, Маңгушым-ай.
Маңгуш әйтте кызга:
Алтын аякка бал коеп-ай
Атаңа кыя[38] аш чәчкел-ай!
Көмеш аякка бал коеп-ай
Иңәңә кыя аш түккел-ай!

Тулунуп[39] иелеп типте Маңгуш, җиленә Көн Сылуның бер күзе чыгыр булды. Инде Ак Көбек килде атын иярләп. Маңгушның акбүз атын иярләп китереп, ул үзенең атына аркан җигеп Маңгушны өйдән сөйрәтеп алып китте. Кабыргасына таш тигәндә ут чыкты. Ак Көбек әйтте:

Кабыргасыннан ут чыккан
Атасы күрсен бу кыен-ай[40]!
Күкрәкләреннән ут чыккан
Инәсе күрсен бу кыен-ай!

---

[36] Пилгеп цыргау – ыргыту, атып бәрү.
[37] Сәрегү – бетү.
[38] Кыя – гына (только).
[39] Тулуну – ачулану.
[40] Кыен.

Ак Көбек Маңгушны Күрләк[41] дигән җиргә алып барды, алып барганда, Ак Көбек әйтте: «Йә, Маңгуш, әҗәлең монда булсынмы?» Маңгуш җирдә ятып әйтте:

Күрләк дигән олы су-ай
Күр[42] адәмнең йорты иде-ләй,
Күрлөк[43] бичә бер алып-ай
Салып киткән[44] йорты иде-ләй.

Аннан тагын сөйрәтеп алып китте, аны алып киткәч Шарлак[45] дигән үзәнгә барды. Ак Көбек әйтте: «Йә, Маңгуш, монда әҗәлең булсынмы?» – диде. Маңгуш җирдә ятып әйтте аңа:

Шарлак тигән олы су-ай
Шәр[46] адәмнең йорты иде-ләй,
Шаргы[47] бичә бер алып-ай
Салып киткән йорты иде-ләй.

Аннан тагы аны сөйрәтеп алып китте, кабыргасына таш тигәндә ут чыга иде, күкрәгенә таш тигәндә очкын чыга иде. Ак Көбек, аны күреп, тагы әйтте:

Күкрәкләреннән ут чыккан-ай
Атасы күрсен: бу кыен-ай!
Кабыргасыннан ут чыккан-ай
Инәсе күрсен: бу кыен-ай!

Манар тау башына алып чыкты. Көбек әйтте: «Йә, Маңгуш, әҗәлең монда булсынмы?» – диде. Маңгуш әйтте: «Йә, булсын минем әҗәлем монда», – диде. «Инде мине үтер! Кылыч белән башымны кисәрсең! Ул, минем башымны үзеңнең башыңа тот! Миндәй алып булырсың», – диде. – «Йөрәгемне чокып алып йөрәгеңә тот!» – диде. Миндәй алып батыр булырсың», – диде, «Эчәгемне алып чорнал! Миндәй алып батыр булырсың». Ак

---

[41] Күрләк – гөрләп, чылтырап аккан.
[42] Күр – сукыр (?).
[43] Күрлөк – әшәке, яраксыз.
[44] Салып китү – ташлап китү.
[45] Шарлак – шарлап аккан.
[46] Шәр – бай, дәрәҗәле кеше, кенәз кебек титул.
[47] Шаргы – усал, әшәке.

Көбек Маңгышны башын кисеп үтерде, башын кисеп башына тотарга теләде. Бер җирдән бер ак сакаллы кеше килде, әйтте: «Ак Көбек, ни кылып торасың?» Ак Көбек әйтте: «Маңгушны үтердем, башын алып башыма тотарга телим», – диде. Ак сакаллы кеше әйтте: «И Ак Көбек, башыңа башын тотма! Бу башын сүри[48] тауга ташла!» Тау башына башын ташлады, таш җимерелеп төште. Ак сакаллы кеше әйтте: «Йөрәген алып оймат[49] күлгә ташла!» – диде. Йөрәген аңа ташлады, ул тирән күлнең суы кайнап бетте. Ак сакаллы кеше янә әйтте: «Эчәген алып, бу бай тирәкнең башына ташла!» – диде. Эчәген алып бай тирәкнең башына ташлады, бай тирәк башыннан көеп, тамыры белән көеп китте. Ул карт әйтте Ак Көбеккә: «Мин булмасам, син үләр идең».

Аннан кайтты Ак Көбек йортына. Көденнең халкы Маңгушны Ак Көбек Манар тау башында үтергәнен укты. Маңгушның атасына әйтергә кирәк. Йортында Маңгушның улы унике яшәр бала булды. Картлар аны өйрәттеләр: «Атаңны Ак Көбек Манар тау башында үтергән; аны карт атаңа – Көден ханга әйт!» – диделәр. Бала барды карт атасына өйрәткән сүзне әйтергә:

Маңгуш бием мартлап[50] тор-ай,
Манар тау башында йортлап тор-ай,
Сәлам бирсәм дә алар юк-ай,
Сакалдан капсам да угар[51] юк-ай.

Көден хан аны угуп алды. «Бу бала ни-ни сөйлидер?» – дип әйтте. Көден ханга халык әйтте: «Маңгушны Ак Көбек Манар тау башында үтереп киткән». Коден хан улының үлгәнен угуп кайгылы булды, сыктады. Инде җиде йөз чирү шайлап[52] Көден хан: «Ак Көбекне яуларга кирәк», – диде. Җиде йөз чирү белән шайланып чыкты. Ак Көбекнең йортына китте, яу белән. Төнлә бардылар, урта юлга җиттеләр. Анда Ак Көбек белде: «Көден хан җиде йөз

---

[48] Сүри – кыя.
[49] Оймат – тирән.
[50] Мартлау – йоклау.
[51] Угу – ишетү, сизү.
[52] Шайлау – кораллану.

чирү белән миңа яулашырга киләдер», – диде. «Алай булса, мин дә шайлап удура[53] чыгыйм!» – диде. Ак Көбек күп кеше алмады.

Талым Коцаның[54] таз улы,
Сүән төбе[55] Сүп Сүрү,
Казан төбе Кап Кара,
Солым – Ак Көбекнең агасы,

Биш кенә кеше удура чыкты. Ак Көбек агасына үр айгырын мендерергә алды. Киттеләр каршы. Анда, барганда әйридә[56] йөзгән алабуга балыклар канатларын судан чыгарып кыдырайтып[57] йөриләр. Кырда йөргән Солым балыкларның күрсәткән канатларын күрәдер, әйтте:

Кыдырайганга кыдырай,
Миңа ни өчен кыдыраясың?
Көдерәйгәнгә көдерәй,
Миңа нәрсә көдерәясең?

Көден ханга барды Ак Көбек кешеләр белән. Көден ханның халкы әйтте Көбекнең кешеләренә:

Талым Коцаның таз улы
Талган[58] сугарга килгәнме?
Сүөн төбе Сүп Сүрү
Сүөн басарга килгәнме?

Аннан Ак Көбек үзе Көден ханның халкына керде, аларны кылыч белән кырып бетерде. Ак Көбек белән Көден хан икесе очраштылар, найза[59] белән чәнчештеләр. Көден хан Ак Көбекне йыда[60] белән үтәли чәнечте. Ак Көбек әйтте:

Чәнчүең дә бар икән-ай,
Күтәрүең дә юк икән-ай.

---

[53] Удура, утура – каршы.

[54] Коца, куца – ата яки ананың бертуган энесе, дядя.

[55] Сүән – туганнан туган, двоюродный, сүән төбе – иң соңгы туган.

[56] Әйри – елга.

[57] Кыдырайту – башны чыгарып карау, бу очракта судан чыгарып, күрсәтеп йөрү.

[58] Талга – корбан.

[59] Найза – сөңге төр.

[60] Йыда – сөңге төр.

Көден хан Ак Көбекне йыда белән күтәрде, үз өстендә тотты. Йыданың очында әйтте Ак Көбек:

Күтәрүең да бар икән-ай,
Селтәвең дә юк икән-ай.

Көден хан йыдасын селтәгәч, Ак Көбек йыданың сабына каклыгып[61] елбышып[62] төшеп киләдер. Ул төшкәч кылычын сузды, Көден ханның башын кисеп ташлады. Көден хан әйтте: «Бүрегем йыгылды», – диде. Ак Көбек йыданы чыгарып ташлады. Кызыл Орына менде, өенә кайтты, Көден ханның кешеләре бер агач алды, муенның сөягенә тыгып куйдылар, ул агачка Көден ханның кискән башын пәкләделәр[63]. Көден хан тере булды, кайтты үз йортына. Көден ханның чирүенең тереләре кайтты, үлгәннәре калдылар.

Көбек ялгыз кайтты. Ак Көбек алтмыш алты яра белән чыкты, көн ярыгы[64] яраларга төшсә, топла[65] күренер иде, андай да булса үлмәде. Кызыл Ор аты җитмеш яра белән чыкты. Ак Көбек төрле яхшы һөнәрле кеше иде; яралы булганга, ядыганын[66] бер агачка элеп салды, чиртергә көче юк иде.

Каен агачлар ботагы-лай
Сыгылса да сынмас булгай лай,
Исән булсам да килермен-ай,
Төгәл[67] торсам да алырмын-ай.

Аннан китте, камчы сабы белән иярнең кашына таянып, түшенә таянып, чак кына кайтып барадыр; бер җирдә имән агачка килде, аның ботагына кыцагын[68] элеп куйды:

Имәннәр агач ботагы-лай
Иелсә дә сынмас булгай-лай,

---

[61] Каклыгу – ябышу.
[62] Елбышу – шуу.
[63] Пәкләү – ныгыту.
[64] Көн ярыгы – кояш нуры.
[65] Топла – үтәли.
[66] Ядыган – чиртеп уйный торган кыллы музыка коралы.
[67] Төгәл – исән-сау.
[68] Кыцак – скрипка.

Исән булсам да килгәймен-ай
Төгәл торсам да алгаймын-ай.

Аннан китте, барып-барып бер җиргә килде, бер уалган[69] арба анда ятыр, аның алдына килеп торды Ак Көбек.

Алтмыш алты кәгәйле[70]-ай
Бу арба нидән уалган-ай?
Җитмеш җиде кәгәйле-ай
Бу арба нидән уалган?
Алтмыш алты яралы-ай
Ак Көбек нидән үлмәгән-ай?
Җитмеш җиде яралы-ай
Кызыл Ор нидән үлмәгән-ай?

Аннан камчысын алды, сукты, арба йөреп китте. Ак Көбек юлы белән китте, барып утырса, бер җирдә бер аккош үлгән, аның канат-йоннары җирдә ята, Ак Көбек аны күреп әйтте:

Алтмыш алты кавырсынлы-ай
Бу аккош нидән үлгәндер-ай?
Җитмеш җиде кавырсынлы-ай
Бу аккош нидән үлгәндер-ай?
Алтмыш алты яралы-ай
Бу Ак Көбек нидән үлмәгән-ай?
Җитмеш җиде яралы-ай
Кызыл Ор нидән үлмәгән-ай?

Аккошның йонына камчы белән сукты, ул аккош очып китте. Аннан Ак Көбек йортына кайтып китте. Үзенең шәһәренең юлына төште, шәһәренә якынлашты; юл кырында бер күл бар иде, анда кызлар, хатыннар йегән[71] тартып яталар. Ак Көбек йыдасын алды, йыда белән ул хатыннарның, кызларның күлмәген, ыштанын ертып тартып алды; үзенең алтмыш алты ярасына, атының җитмеш җиде ярасына тутырды, җил тимәсен дип. Хатыннар, кызлар ялангач сыкташып калдылар. Ак Көбек юл белән акрын-

[69] Уалу – ватылу.
[70] Кәгәй – спица, киги.
[71] Йегән – камышның бер төре, аннан чыпта сукканнар.

лап юыртып барыр иде. Хатыннар, кызлар аны күрде, Ак Көбеккә әйттеләр:

Алтмыш алты яралы-ай
Акылын куймас Ак Көбек-ай;
Җитмеш җиде яралы-ай
Холыгын куймас Ак Көбек-ай,
Яхшы җирем капцуг-ай[72],
Яман җирем япцугу[73]-ай.
Анда салсаң Ак Көбек-ай,
Анда салсаң Ак Көбек-ай.

Ак Көбек укмады, ыштанын-күлмәген салмады, барып китте. Йортына барды, шәһәрнең читендә күп кеше гүр ясадылар. Ак Көбек ул кешеләргә килде. «Бу кемнең гүрен казып ятсыннар?» – диде. Ул кешеләр әйттеләр: «Ак Көбек яралы килә, аның гүрен казып ятабыз», – диделәр. Ак Көбек әйтте: «Инде мин үләменме? Бу җирдә ятармынмы?» Ак Көбек саудагын гүргә төшерде, әйтте: «Чынлап та үләр булсам, төбенә төш! Терелсәм, тола төш». Саудагын салгач, куягын[74] да салды, түбәндә ятты саудагы-куягы. Инде Ак Көбек аты белән гүргә керде, ятты, кешеләр аны күмделәр. Борын куркак агасы Солым яудан качып кайткан иде. Гүрнең янында торган Солым агасына Ак Көбек әйтте: «Көден хан йортында янә җиде йөз чирү җыеп, җиде йөз чирү белән тагын килер. Җиде йөз чирү белән Көден хан килгәндә, миңа тавыш бирерсең!» – диде. – «Анда мин торып чыгармын».

Инде күмеп ташладылар. Ак Көбек ике кунды, өч кунды күмгәч. Өч кунганда Ак Көбек гүрендә, Солым агасы аракы эчте, буза эчте, исерек булды. Солым агасы: «Ак Көбек үлгән булыр», – диде: «Үлгән кеше гүрдән чыгалмас», – диде, терелүенә ышанмады. «Үлгән кеше терелмәс кой», – диде. «Мин аңа барып, аны камчы белән сугаем!» – диде. Солым агасы бер атка менде, камчы алып гүргә китте, гүрнең катына барды. «Ак Көбек тор!» – диде. «Ни эшләп ятасың?» – диде. Гүренә камчы белән сукты. Һәр шай-

[72] Капцук – дошман.

[73] Япцук – яхшы.

[74] Куяк – көбә күлмәк.

ларын алып, атына менеп, гүрне ертып, Ак Көбек аты белән чыгып килде. Өч кабат чабып әйләнде чүлне, Көден ханның чирүен эзләп, һич кешене күрмәде. Кайтып килде Солым агасына. Ак Көбек әйтте: «Көден ханның явы кайда? Ни күренми?» – диде. Солым агасы әйтте: «Көден хан чирү белән килмәгән, мин, үлгән кеше терелмәс дип, сынамакка суктым иде», – диде. Ак Көбек әйтте: «Инде миннән соң үлгәннәр терелмәсен! Инде мин үләмен, минем яраларым сөгүлде[75], җиде кунарга толдырмадың[76]», – диде. Аннан гүренә аты белән кереп китте, үлеп калды.

[75] Сөгүлү – ачылу.

[76] Толдыру – тутыру.

## Кузы Курпы мән Паян-Сылу

*Хәмит Ярми*

Ике кан пулган. Персе аның Ак кан, персе Кара кан пулган. Пыларның катынлары корсаклы пулганнар. Ак кан пылан Кара кан үсара сыргалаштылар: синең улың пулса, минең кысым пулса – коталашабыс тиләр, сүз куйдылар.

Көннәрдән бер көнне пы ике кан ахутага цыгып киттеләр. Ахутага киткәндә, пылар әйттеләр усләренең цәмагәтләренә: «Без осак калып, пала тапсагыз, пескә сөенцегә пер үвәсирне ебәрең», – типтеләр. Пылар ахутада бик осак йөрептеләр. Пылар кайтканцы, цәмәгәтләре пала таптылар. Пер увәсирне сөенцегә ебәрделәр. Үвәсир пы ике канга парып әйтте: «Цәмәгәтләрегес ир пала пелән кыс пала тапты, тип. Ну пылар сөенәләр, сөенешеп тиз кенә атка менеп цабалар. Аңа-моңа карамай цабып парганта Кара кан егыла атыннан. Атыннан егылып төшеп, Кара канның аягы сынды. Осак ятматы Кара кан, өйлде. Өйлгән суң, Кара канны күмтеләр. Кара кан кайтмый калды шул өйлгән ерендә.

Кара канның катыны, ятим калып, паласын көйтәреп парды Ак канга. Акканның курасына керде. Яй көне булган игән. Ак канның ялцылары эрегән сөт алып цыгып тәпшегә[1] коялар, канның эт балаларын туйдырыр өцен. Канның көцекләре тәпше янына килеп эрегән сөтне эцә башлатылар. Шул уакытта Кара канның катыны үсенең паласын ергә ебәргән игән. Кара канның паласы елышып парып әлеге тәпшедәге эрегән сөтне кулы пелән алып ашай башлайты, көцекләр пылән пергә.

Кара кан паласының этләр мән ашауын Ак канның катыны карап торыпты. «Әй, типте, пы караканның паласы эт пылән пергә ашай», – тигән, «Пы якшы кеше пулмас, моңа кызны бирмәү гәрәк», – типте. Аннан суң Ак канның катыны үсенең күргәннәрен Ак канга әйтепте: «Мин шантай-шантай кәл күрдем», – дип. «Кысыбызны эт палалары пылән бергә ашаган кешегә бирмәек, пы Кузы Көрпә монда калсын, пес башка

[1] Тәпше – агач савыт.

шәһәргә, башка ергә күцеп китәек, Кузы Көрпе монда калсын», – тип әйтепте Ак канның цәмәгәте. «Пы пала монда калсын, үссә берәр йиңә алыр үсенә», – типте.

Ак каннар пы ерләртән күцеп китепте, Кузы Көрпәләрне калдырып.

Кузы Курпы 7–8 яшьләргә етепте. Урамта яшь малайлар мән уйнап йөри пашлайты. Пы Кузы Көрпә яшьтән ук бик көцле, пәлван пулган игән тите. Малайлар мән уйнаган цакта, пы ике малайның кулын цыгарыпты, тагын пер малайның кулын-аягын цыгарыпты. Яман көцле игән пы Кузы Көрпә. Кешеләр пы Кузы Көрпәне орыша башлайтылар.

Көннәрдән пер көнне малайлар мән уйнап йөргәндә, пы Кузы Көрпә янә пер баланың кулын цыгарыпты. Пы бала елай-сыктай Кузы Көрпәне орыша-сүгә башлапты: «Син, типте, көцеңә таянып, көцең мән мактанып, юкка куатланып йөргәнце, үсеңне ташлап киткән катыныңны парып алыр итең», – типте.

Кузы Көрпә пы сүсне эшеткәц, күңелсесләнеп, елткәсен тәбән салып[2], өенә кайтып китепте. Юлда кайтып парганда «Минем катыным пулган микәнни» тәп уйлап кайтыпты пы.

Өенә кайтып парганта, Кузы Көрпәгә оцырапты, ти, пер корткаяк. Пы корткаяк, Кузы Көрпәнең елткәсен тәбән салып кайтып килүен күреп, моннан сорапты: «Ник пылай башыңны тәбән салып кайтып киләсең?» тәп. Кузы Көрпә моңа: «Мәнем катыным пултымени?», – типде.

Корткаяк әйтепте пы палага: «Сәнең катының Ак канның кысы Паян-сылу, – типте. Ак канның кысы Паян-сылу мән сәне сыргалаштырганнар әте, – типте. – Ак канның кысы Паян-сылуны (кайбер урында бабай «Баянсылу» дип тә әйтә. – *Х.Я.*) сәңа бирмәен кацырып алып кәтте, – типте (кайбер урында «типте», «тите» ди, ә кайбер урында «тете» дип тә җибәрә бабай. – *Х.Я.*) – Син мыны өеңә кайтып инәңнән сура, инәң сөйләр, сөйләмәсә син аны кәйләмән сөйләт, көцләп сөйләт, – тиде. Син өеңә кайт

[2] Елткәсен тәбән салып – җилкәсен түбән салып, кайгырып.

та «Инәм, син миңә кауыргыц[3] куырып бир, минем куырган кауыргыц ашагым киләте, – тиген. Инәң синә кауыргыцны куырып бирер. Куырылган эссе кауыргацны ул сәңа кугац[4] мән сосып пирер. Син әйт: «Инәм, син мәңа куыргацны кугац мән сосып бирмә, кулың пылән алып пир, тип әйт. Ул сәңа куырганңны кулымән сосып алып бирер. Куыргацны кулына алу мән син аның кулын кысып ошла, аннан суң «минем катыным пулдыма, ницек булды», – теп сора. Кулы пешкәнгә цытай алмай ул сәңа сүләп бирер», – тигән. Шулай тигән тә корткаяк атлап киткән.

Кузы Көрпә, өенә кайтып, инәсенә:

– Миңә кауыргац куырып пир, минең куыргац ашагым киләте, – типте. Инәсе куыргац куырып биреп, куыргацны кугац менән салып (кугацка салып. – *Х.Я.*) пирепте. Шуннан Кузы Көрпә әйтепте: «Инәм син мәңа куыргацны кугацка салып бирмә, кугацка салып бирсәң, мәнем юлым, кыйгац пулыр, син аны мәңа кулыңмын алып бир, – типте. Инәсе куыргацны кулына алу мән, Кузы Көрпә алың кулын кысып ошлапты. «Я, инәм, син миңа әйтеп, сөйләп бир, минем катыным кем пулацак ите, – типте.

Кузы Көрпә инәсенең кулын ебәрмәй пылца тотыпты, ошлапты. Кузы Көрпәнең инәсе алай порылыпты, пылай порылыпты, сөйләмәс итә дә кауырганң эссе пулгац кулы пеште, сөйләмәй пулмайты. Шаннан суң Кузы Курпәнең инәсе әйтеп пирте моңа пулган кәлләрне парсын та. Парсын та сөйләп пөтергәц, Кузы Кұрпә инәсенең кулын ебәрте, пушатты инте моның кулын. Инәсе әйтте:

– Я, палам, инде куйматың, сөйләп бир титең, менә мин сәңа пулганын сөйләп, әйтеп бирдем, тиде. Тик син инте, палам, алар янына парасы пулма, анта барсаң, алар сәне үлтереп куярлар, – тиде. – Алар сәне яратмадылар, – тиде, – атаң кан исән пулмагац, – тите. Инәсе янә әйтте Кузы Көрпәгә: Улым, тиде, аның юлы та бик авыр, асаплы юл пулыр ул, тиде. Аның юлынта алты ай туңмас тәрья бар, тие, ул тәрьяны уткәц цыцкан үтмәс орман пар, ти. Тәрьяга еткәц, тәрья алдында алты ай ятарсын, аны ницек

[3] Кауыргыц – куырылган арпа.

[4] Кугац – туздан тегеп ясалган, чүмеч кебек әйбер.

үтәрсең, – тиде. Аннан Кузының инәсе пыларның барын сарын пелән әйтеп пирде. (Сарынын оныттым, ди Хәсән бабай, исенә төшерә алмады. – *Х.Я.*).

Кузы Көрпә торып әйтте: «Мин, – тиде, – алты ай туңмаган тәрьяны алты көндә туңдырып кицәрмен, – тиде.

Инәсе янә сарынмән әйтте, Кузы Көрпәне ебәрмәскә теләп.

Кузы Көрпә: «Юлга цыгам, кысны эстәп китәм», – дигәч, инәсе янә әйтте сарын беләң. «Әнә атаңнан калган цыбырткы, аннан калган кылыц пар, юлга цыгар булсаң, аларны ал, – тиде. Ул цыбырткы мән барсаң, тәрья алдына еткәц сарын әйтеп шул цыбырткы мән суксаң, алты ел туңмаган тәрья алты көндә туңар, кылыц мән цыцкан утмәс цытырманны кисеп цыгарсың юл ясап. Аннан сауыскан үтмәс кара цүлгә чыгарсың, кара цулне уйтәрсең, кара цулне уйткц, Ак канның пәстугенә оцырарсың. Ул пәстук барырсың, улым, – тиде. – Ол пәстук сәңа юлын курсәтер кайдан парырга тиде.

Ну, пы Кузы Көрпә юлга кәзерләнә. Атасыннан калган цыбырткыны, кылыцны алды. Юлга цыгып сур тәрьяны, цыцкан үтмәс кара орманны ярып үтте. Барып, барып елгы пәстугенә барып етте. Елгы пәстугенә бара, керешә моның пылан исәнлек сорап. Елгы пәстуге кунак итә моны: өц ел колынламаган бер ту бияне суеп ашатты моңа, Кузы Көрпәгә.

Аннан пы пәстук әйтте:

– Менә пы юл пылап барырсың, сыер пәстугенә, – ди. А-а-а-на алыста тугел сыер пәстуге булыр, – ди, пес пер-перепестән алыс түгел, – ди.

Кузы Көрпә бара-бара сыер пәстугенә барып етте. Сәләм бирешеп исәнләштеләр, сөйләштеләр. Сыер пәстуге янә моңа өц ел пысауламаган пер сыерны суеп, Кузыны кунак итте. Аннан соң ул Кузыны куй пәстугенә ебәрде.

Кузы куй пәстуге янына барып етте, исәнләштеләр, сөйләштеләр. Ул, янә пер симес куй суеп, Кузы Көрпәне кунак итте, ашатты.

Кузы Көрпә моннан сураша: «Инте, ди, ницек итеп Паян-сылуны табарга, ди, Паян-сылу кайта булыр, ди, аны ницек итеп табарга, – тәте.

Пәстүк әйтте: «Пылай барсаң, сәне үтерерләр, тәте, сән мәнем киеменме ки, үс киемеңне мәңа калтыр тәде.

Аннан юлны өйрәтте: «Ә-әнә, тәте, куйларны елгага цаклы апарыр- сың, елгага еткәц куйларга:

Кицерел, куем, кицерел, куем,

Кицередмәсәң, тора кал, куем, – тәп әйтерсен тәте.

Кузы Көрпә куйларны елгага цаклы алып барып еткәц, ни тип сарын әйтергә онытып ебәрде. Шул арада Паян-сылу килеп цыгып: «Син көндә әйтеп йөргән сүсеңне онытасың. Кицерел, куем, кицерел, куем, кицерелмәсәң, тора кал, куем!», – тип кыцкырсаң, алар цыга бирәте, тәте. Кузы Көрпә куйларга: «Кицерел, куем, кицерел, куем! – тәп кыцкырды. Куйлар елганы кицеп цыгып китте.

Шаннан суң пәстүк аңа өйрәткән инте: – Менә минем ята торган испушкәм пулыр, тигән, шунда кереп ятарсың, тигән. Аннан әйткән: «Аш-суны Паян-Сылуның кысмәткәрләре пешереп куярлар, тигән, аны пәлән кумнатка парып ашарсың, цай эчәрсең», – тәгән.

Ярар, пы Кузы Көрпә кайтты Паян-Сылу янына. Аш кумнатларына керде. Цай эцкале утырган суң Паян-сылу мыны ошатты үсенең элекке егетенә. Утыралар. Кыс күңелсез, еңәләремән сыер саварга цыкматы, пәстүк янында осагырак калты пы. Еңәсе дә сирәк кеше пулган. «Нишләп осак цыкмый тордың?» – тип сорады Паян-Сылудан. «Әнә, ти, Паян-сылу әйтә, пы пәстүк порын күтәреп песнең цайны яратмайты, аның янынта осагырак пулдым», – тиде. Паян-Сылу пылан Кузы Көрпә шал еңкәләре цыгып киткән арада кәпләшеп алтылар.

Аннан киц пола. Пылар киц тә оцырашып сөйләштеләр, таныштылар.

Паян-сылу шал төнне осагырак йоклап кала, иртәмән сыер сауарга цыкмай калаты. Иртә пылан кинәт ижеген төбертәтә еңәсе сарын әйтеп:

Торсана, Паян-сылу,

Торсана, тышта коцкацаклар сайрашаты.

Паян-Сылу цавап бирде:

Ац пүреләргә ем булсын

Коцкацакларың, ти.

Ац пүреләргә ем булсын,

Куйларың, ти.

(Аннан тагы сарыннары пар иде, онытылган, ди бабай. – *Х.Я*).

Аннан соң еңәләре кәбәр итәләр Паян-Сылуның аталарына, инәләренә. Алар та пы эшне пеләтеләр, сизәтеләр. Инәләре Паян-Сылуга әйтәделәр: пы Кузы Көрпәдән матур егет әллә илтә юкмы, илгә цыксак, илгә цыксак антайны кырыкны табарбыз, – ти. (Инәсе сарын әйтә, мин оныттым, ди бабай.

Паян-сылу: «Миңа Кузы Көрпәдән пүтән кеше кәрәкмәйте», – тип әйтепте. Аннан соң пылар, Паян-Сылуны алдап:

– Ярар, Сине Кузы Көрпәгә бирәбез, тип әйтептеләр, алтаптыдар Паян-сылуны. Узара Кузы Көрпәне үлтергәле тип киңәш итептеләр. Пылар, усара кәпләшеп, арцан-курцанны әзерләп куептылар. Шаннан пер увәсирне Кузы Көрпәне кунакка цакыргалы ебәрептеләр. Паян-Сылу пыларның ни өцен цакыртканнарын пелеп әйтепте Кузы Көрпәгә:

– Парсаң, сакланып эц, вуп эцмә, исермә! – тип.

Беренце цакыруда Кузы Көрпә бармайты. Үвәсир кайтып әйтте: «Кузы Көрпә килмәйте» тип. Кан тагы кайта, ебәрте ике үвәсирне. Кузы Көрпә алар цакыруына та парматы. Үвәсирләр кайтып әйттеләр. Өценце рәт кан ебәрте өц үвәсирен. Өц үвәсир цакыра килгәц, Паян-Сылу: «Инте пар, тите, ебәрте Кузы Көрпәне. Юлга цыкканта әйтте Паян-сылу: «Пар, тиде, саклан, кән эцмә*, исермә»,– тиде.

Кузы Көрпә барты кунакка, әцеп исереп китте, арцан-корцан исертте мыны.

Канның караулцылары арасында Паян-сылуның тус кыслары пулаты. Алар кәбәр иттеләр Паян-сылуга: «Кузы Көрпәне алдатылар, изерттеләр», – тип.

Паян-Сылу аталарына килде, Кузы Көрпәне өйзенең пүлмәсенә алып цыгып китте. Паян-Сылу Кузы Көрпәгә әйтте: «Ник

эцтең, ник аларның сөйзен тыңладың?» – тип. Моңа Кузы Көрпә әйтте: «Иртән, ти, син мине озат, ти, мин кайтам өйз өемә», – тиде. Паян-сылу әйтте: «Мин синнән калмаем, мин синең мән китәм», – тиде. Кузы Көрпә: «Син кәзергә кал, мин сине алгалы яңатан килерем, – тиде, мин сине күцереп китәрмен», –тиде.

Иртән торып Кузы Көрпә атына атланып китә, Паян-Сылу мыны осатып калды.

Пер авылга парып етәте Кузы Көрпә. Шал ауылның цитендә пер күпер пулган игән. Кузы Көрпә күпергә килеп етү мән күпер астыннан пер кеше килеп цыкты. Пы кеше әйткән Кузы Көрпәгә: «Син миңа езнә юлы[5] пир», – тигән. Кузы Көрпә моңа езнә юлы пирмәгәц, кеше әйткән: «Әгәр син езнә юлы бирмәсәң, бер тумыгыңны ацып куй, мин шаңа атаем типте. Кузы Көрпә пы кешенең огы әллә ни ауыртмас тип уйлап: «Мә, типте, атып пак, типте, тумыгын ацып куепты. Әлеге кеше укмән атып мының тумыгын ярты. Кузы Көрпә баягы кешене камцысымән сугып екты, ярты: «Атам та ауырттырганы юк, инәм та ауырттырганы юк, син мине яралатың», – тиде, әлеге кешене тагы ярты камчысымен.

Инте китте Кузы Көрпә. Пара-пара моның аяк шешше. Паралматы, атыннан төште. Пер пайтирәк пар ите, Кузы Көрпә шал пайтирәк төбенә килеп ятты.

Кузы Көрпәдән кәбәр килмәгәц, Паян-Сылу мыңа кацкацакны ебәргәле пулты. Ебәрте кацкацакны: «Пелеп кил, теремә, үлеме Кузы Көр пә, шаны пелеп кил», – тип. Кацкацак китте. Кацкацак пик күп ерләр, пик күп цүлләр үтеп парып етте пайтирәк янына. Караты, Кузы Көрпә үләр тәрәцәгә йеткән. Кацкацак мыны пелеп, оцып кайтып китте.

Пы кацкацак оцып кәбәр алып кайтып йеткән вагытта, Баян-Сылуның инәсе аның пажын карап ята тигән. Паян-сылу инәсе алдында ятып йоклап китепте. Шал арада мының йоклап китүеннән пайталанып еңәсе кацкацакные тотып алып, аннан сорапты: «Үлеме, тереме?» – тип. Кацкацак мыңа пер сүс әйтмәйте. Шаннан йеңәсе пы кацкацакның йөнен йолгып алыпты, «әйт!» тип. Кацкацак пыларга сүс әйтмәде. Кәбәрен әйтмәгәц, кацкацак-

[5] Езнә юлы – җизни бүләге.

ны үтергәле пултышар, аны утка салтылар. Утка салгац кына кацкацак әйтте: «Кузы Күрпә палән цүлтә, пәлән-пәлән пайтирәкнең төбендә ятаты, аның кале петкән», – тип. Пы сүзне Паян-Сылу ишетерлек итеп кыцкырып әйтте, Паян-Сылуның колагына әйтте.

Паян-Сылу пы кәбәрне эшетеп бик кайгырды, пы өйтән ницек цы- гып китү юлын эстәй башлаты.

Инәсенә әйтте: «Мин кысларым пылан сәелгә цыгам» – тиде. Энце, якут, мәрцәннәрен алып, кырык кысны иярткеп цыгып китте. Юлта парганда Паян-сылу энце, мәрцәннәрне ергә цацып ебәрә, кыслар моңа алтанып, энце, мәрцәннәрне цүпләп калатылар. Паян-Сылу пылартан кацып китә. Пылар куып килеп етү пылан тагы энце, мәрцәннәр, якутларын цацып ебәрәте. Кыслар тагы аны еып калатылар. Паян-Сылу Кузы Көрпәне эстәп пара бирде. Пара-пара пы әлегецүлгә парып етте. Анда пайтирәкне тапты, – пайтирәк янында Кузы Көрпә үлеп ята тигән. Аннан Паян-Сылу әйтте: «Кайтсам, мине парыбер пүтән перәүгә бирерләр, мин кайтмаен, мин мынта үләен», тиде. Паян-Сылу: «Үлсәк, пергә үләек» тип пыцагын күкрәгенә катап, Кузы Көрпәне коцаклап өйлә.

Пылар икесе тә өйлгәннәр инте.

Паян-Сылуның пайтирәк янына китүен пер кыс пелгән. Пы кыс мының үлүен инәләренә кәбәр итте.

Моның артыннан киткәннәр куып, Ак кан үсе тә вәсирләр мән пергә куып килә, кысын эстәп. Куып килеп етсәләр, пылар икесе дә коцаклашып өйлгәннәр. Ак кан әйтте: «Пыларның икесен пергә күммәйпес, ти, персе елганың пы ягына, пөерсе менә пы ягына күмелсен», – ти.

Күмәләр – персен елганың пер ягына, ә персен рицканың икенце ягына.

Ну инте Ак канның кияүе пулган игән, әлеге Кузы Көрпәнең тумыгын атып ярган пер сәүтәгәр. Ул үлгән кайгырып. Ак кан әйткән: «Паян-Сылуның яраткан кияүе менә пы кеше ите, тигән, аны тигән, Паян-Сылуның янына күмегес», – тигән. Күмгәннәр.

Пылар күмелгәц, әлеге пайтирәк Кузы Көрпәнең дә, Паян-Сылуның та кәбере өстенә өйсеп цыккан. Сатуцының кәбере өстенә пер тал өйсеп цыккан. Паян-сылу мән Кузы Көрпә

нәсерләре өстенә өйсеп цыккан пайтирәкләр пер-персенә якын килеп, ишелеп өйскәннәр. Сәүтәгәр кәбере өстенә цыккан тал өйсенә-өйсеп, суцьннан тыршаеп корып калган.

Паян-Сылу мән Кузы Көрпә пер – пересен яратканнар, ә сатуцыны Паян-сылу яратмаган, аңа кысны көцләп пирмәк пулган Ак кан.

Бу дастанны 1940 елның 22–23 маенда Новосибирск өлкәсе, Каргат районы, Муса авылы Советы, Тәрәнә авылында (Яйләү авыл – *Җәйләү* сүзеннән, аларда бу тирәдә Кышлау авылы да бар. Димәк, җәй көннәрен Җәйләүдә, кыш көннәрен Кышлауда торганнар) Хәсән бабай Кәримовтан язып алдым. Ул 1863 елда туган, аңа хәзер 77 яшь.

Тәрәнә авылында хәзер колхоз бар, аның исеме «Ирек». Хәсән бабайны төп Себер кешесе дип әйтергә була. Аның этисе монда, Себердә үзе монда туган. Ә бабасы элекке Казан губернасының Тәтеш ягыннан килгән, имеш. «Безнең бабайлар, солдат бирмәс өчен бараба татарлары исеменә язылып, торыр өчен монда килгәннәр», – ди ул. Хәсән бабай үзе дә бараба кызына өйләнгән. Колхозда – 1930 елдан.

Бу дастанны яшьрәк чакта шушы авылда ишеткән булган. Ул аны бик җиңел сөйләде. Сүзгә оста карт. Бер язып чыктым, аннан яңадан сөйләтеп төзәтеп язып чыктым. Бабай сүзләрне нигездә бараба татарлары шивәсендә сөйли. Ләкин кайбер сүзләрне төрлечә әйтә, искечә грамоталы, ул үзе гарәп хәрефләре белән китаплар да укыган булса кирәк. Ләкин: «Мин грамотасыз», – ди.

Мин Хәсән бабайдан бараба татарлары шивәсендә булган кайбер сүзләрне язып алдым. / Бараба татарлары да «ц» белән сөйлиләр, аларда «ч» юк диярлек.

Шәбалә – кашык /түмән татарларында шабала/.

Цацнау – чүмеч /түмән – цүмец/.

Табак – тарелка /түмән – тәрилкә/.

Латка – чугун /түмән – цуйгун/.

Цыны – чынаяк /түмән – цынаяк/.

Тумөк – тубык /түмән – тубык/.

Кос – күмер /янган/ /түмән – кус/.

Сампар – самовар /түмән – самавар/.

Корас – әтәч /түмән – курас/.

Көркә – күркә /түмән – күркә/.

Кармакцай – сыерчык /түмән – бакцар/.

Мунцак – бусы /түмән – мун/й/цак/.

Пыцак – пычак /түмән – пыцак/.

Күнәк – чиләк /түмән – циләк/.

Кацау – өтерге /түмән – кацау/.

Колца – кыр суганы /түмән – юуа/.

Пыяс – суган /түмән – пыяс/.

Йомак – әкият /түмән – йомак/.

Моннан башка мин бараба татарларының үзара сөйләшкән вакытларында кулланыла торган шивәләрен язып алдым. Алар арасында шундый сүзләр һәм җөмләләр бар:

Ога калган всятакай /шулай да отып, аңлап алган.

Өйзеңнеңке нождаң өйзеңкә йеткән. /Үз нужаң үзеңә җиткән.

Ул нимәне пелсен /ул нәрсә белсен.

Нәцем карт пар итте, алар пулса пелер итте /Нәҗми карт бар иде, ул белер иде.

Картлар өйлеп пөткән /картлар үлеп беткән.

Кәрим тәган карт полган /Кәрим дигән карт булган.

Кызын какырып тәте /кызын качырып диде.

Пер цөлгә цыккан /бер чүлгә чыккан.

Өйлцәп цыккалы тәте /үлчәп чыгарга ди.

Одырылап цыга /каршы чыга.

Өйзенеке /үзенең.

Сарнаган /җырлаган, көйләгән.

Ницә сәгатьтә килгәле, минем сәгать юк. /Ничә сәгатьтә килергә, минем сәгать юк.

Мәгаләй /бияләй.

Нимәсе цыксын /нәрсәсе чыксын.

Бу сүзләр Хәсән бабайдан һәм башка иптәшләрдән язылды.

1940 ел, 22 май, Яйләү-Тәрәнә авылы.

1870 елларда шушы Тәрәнә авылында В.В. Радлов булып киткән. «Авылда күп кенә карт кешеләр бар», – дигәч, мин бу авылның иң карт кешеләрен җыйнап, Радлов турында сораштым. Чөнки мине Радловның нинди кеше булуы, бу ерак Себердәге татар авылларында аның ничек эшләп йөрүләре, халык иҗатын ничек һәм кемнәрдән язып алулары бик нык кызыксындыра. Минем уемча, Радлов, бу авылларда бик аз тукталып үтеп китүенә карамастан, халыкның тел үзенчәлеген бик яхшы тотып ала белгән һәм әкият-дастаннарны халыкның үз телендә, үз шивәсендә бик матур итеп язып алган. Аның (В.В.Радловның) әйтүенә караганда, дин әһелләре аның фольклор язып йөрүенә бик нык каршылык күрсәткәннәр, ләкин ул, шулай булуга карамастан, күп эш эшли алган.

Минем үтенүем буенча, җыелышка,чакырган җиргә, түбәндәге картлар килде:

Хәсән карт Кәримов – 77 яшь

Фазулла карт – 85 яшь

Габдулла карт – 90 яшь

Габбас карт – 92 яшь

Гыймран карт – 70яшь

Бу картлар белән бик озак сөйләшеп, гәпләшеп утырдым. Мин аларга Казан хәлләрен сөйләдем, ә үзем шушы ерак Себер җирләрендәге борынгы тормыш хәлләрен тыңлап, мәс килеп утырдым. Кайбер материалларын язып алдым. Картлардан бары 92 яшендәге Габбас карт кына В.В. Радлов килүен хәтерли. «Мин яшь идем. Безнең авылга озын гына, башына кара эшләпә кигән бер кеше килгән иде. Ул картларны чакырып сөйләшкәнен хәтерлим. Ни язгандыр, ни сорагандыр, анысы белән мин кызыксынмадым. Ул вакытта без бернәрсә белән кызыксынмадык. Аның янында бер яшь кеше дә бар иде сыман. Алар бездә берничә көн торып киттеләр», – ди. (В.В.Радловның архивын, көндәлекләрен табасы иде, анда сәяхәте турында бардыр дип уйлыйм.)

*1940 ел, 22–23 май.*
*Тәрәнә авылы*

## Кыз озату җыры – «Яр-яр»

*Һәнүз Мәхмүтов*

Борынгы бараба татарларының «Яр-яр» җырын кыз озатканда җырлаганнар. Кыз белән яшь киленне толымнарына карап аера торган булганнар. Кызлар толымнарын бердән үрә, ә киленнеке икегә аерылып үреләә икән. Шуңа күрә чәчне икегә аерып үрү ритуалы кыз озаткандагы иң изге, иң җаваплы йолаларның берсе саналган.

Кияү булачак бисәсен алырга килгәч, кызның йеңгәләре, чыбылдык эчендә зур тарак белән кызның чәчен икегә аерып үрә-үрә, шушы «Яр-яр»ны – кызның туган йорт белән, ата-анасы, туганнары белән саубуллашу җырын сыктый-сыктый җырлый торган булганнар. Шушы җыр куплетларында кызның кайгысын, шатлыгын, әнисенә, әтисенә, йеңгәләренә, киявенә, кияү егетләренә – нүгәрләргә, әбисенә һәм бабасына, кайнешләренә һ.б.га әйтәсе сүзләрен, теләкләрен, курку һәм шикләнүләрен белдергәннәр.

Новосибирск өлкәсенең Кыштау, Венгеров, Куйбышев районнарына кергән Усманка, Альменево (Тарлар), Арамсаз (Улуцк), Шагыр һәм Яргүл авылларындагы төп барабадан килгән 60–70 яшьлек карчыклар әле үзләре яшь чакта кызларны «Яр-яр» җырлап озатуларын искә төшереп сөйлиләр. Ул җырның махсус көе бар. Куйбышев районының Шагыр авылында ул магнитофонга Мәргу әби Хәйдәровадан язып алынды. Җыр шактый озын булган булса кирәк. Ләкин аның кайбер кисәкләре онытылган. Мәргу әбидә җитмәгән кисәкләрен Кыштау районының Усманка авылында яшәүче Гөлсәгыйдә әби Абдулова (70 яшьтә), шул ук авылдан Асия әби Нәбиуллина (81 яшьтә), Венгеров районы Мангыт авылында торучы Гыйльмиямал әби Мөхәммәдьярова (56 яшьтә, пенсиядәге колхозчы), шушы ук райондагы Улуцк (Арамсаз) авылының Мәгъруф бабай Вахитов (62 яшь, Чаны районының Тармакүл авылыннан килгән) тулыландырдылар.

Мәргу әби Хәйдәровага 68 яшь. Яшь чагында колхозда эшләгән.

## Яр-яр

*Йеңгәләр җырлый:*

Челтер-челтер камышка
Сыргам төште, яр-яр.
Сыналмаган чит җиргә
Сеңлем төште, яр-яр.

Ак чүпрәккә түгәле
Алтын микән, яр-яр.
Күк чүпрәккә түгәле
Көмеш микән, яр-яр.

*Кыз әнкәсенә җырлый:*

Дүрт поцмаклы өемдә
Урыным калды, яр-яр,
Дүрт колаклы казанда
Өлешем калды, яр-яр.

Тарак теше сынганда
Талгый торган әникәм,
Тарак сылу мин киттем,
Инде тынгыл, әникәм.

Үнә күзе сынганга
Тылгый торган әникәм,
Үнә сылу мин киттем,
Инде тынгыл, әникәм!

Цыбылтыгым эценә
Цыбын инәр, яр-яр.
Цыбыртак буйлы яшь егет
Йылып инәр, яр-яр.

*Йеңгәләр кияүгә җырлый:*

Цыбылтыгың цацагы
Биснә микән, яр-яр.
Пескә төшкән кияүләр
Мулла микән, яр-яр.

*Кызны алып киткәндә, иптәш кызлары кияү егетләренә – нүкәрләргә җырлыйлар:*

Алтын балдак киштәдә
Түгәрәкләнә бишкә дә.
Сеснең кебек нүгәрләр
Керми песнең төшкә дә.

Йеңгәләр кодаларга җырлый:
Кара сыер мөгезен
Каермагыз, яр-яр;
Яхшы атаның баласын
Аермагыз, яр-яр.

*Әнкәсе кызына җырлый:*

Килер-китер юлыңа
Киндер чәчтем, яр-яр;
Киндер китән булганчы
Килгел, бутам, яр-яр.

Басыр-барыр йереңә
Бодай цацтым, яр-яр;
Бодай башы пешкәнче
Кайтып килгел, ботам.

*Усал йеңгәне яратмасалар, кияү ягыннан җырлыйлар:*

Өебезнең түбәсе
Кысыл балчык, яр-яр.
Кысыгысның йеңгәсе –
Кысыл канчык, яр-яр.

**Авторлар турында кыскача белешмә**

*Миңнуллин Ким Мөгаллим улы,* филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры.

*Бәдретдинова Алсу Әнис кызы,* ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге кече фәнни хезмәткәре.

*Гомәров Илһам Госман улы,* филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире.

*Дмитриева Людмила Василий кызы,* филология фәннәре кандидаты, диалектолог (1997 елда вафат).

*Закирова Илсөяр Гамил кызы,* филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

*Йосыпов Фәрит Йосып улы *,* филология фәннәре докторы, профессор, ТР Мәдәният министрлыгының традицион мәдәниятне үстерү үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

*Кадыйров Илгиз Шәфикъ улы,* халык музыкасы белгече.

*Кокоулин Владислав Геннадий улы*,* тарих фәннәре докторы, Новосибирск дәүләт фәнни-тикшеренү университетының Россия тарихы кафедрасы профессоры, РФ Хәрби фәннәр Академиясе профессоры.

*Мәхмүтов Һәнүз Котдус улы,* әдәбият һәм сәнгатъ белгече (1996 елда вафат ).

*Нургаянова Наилә Хәбибулла кызы,* педагогика фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һә музыка бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

---

* Мәгълүматлар китапның беренче басмасы әзерләнгән вакытка бирелде.

*Рахматуллина Әлфия Рафик кызы,* Россия ислам тарихы буенча белгеч.

*Рыжикова Татьяна Рәис кызы*,* филология фәннәре кандидаты, Россия Фәннәр академиясенең Себер бүлекчәсе Себер халыклары телләре секторы өлкән фәнни хезмәткәре.

*Тумашева Диләрә Гариф кызы,* филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе академигы (2006 елда вафат).

*Уртегешев Николай Сергей улы*,* филология фәннәре кандидаты, Россия Фәннәр академиясенең Себер бүлекчәсе Себер халыклары телләре секторы өлкән фәнни хезмәткәре.

*Фаткуллина Роза Дамир кызы*,* ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге аспиранты.

*Хисамов Олег Ришат улы,* филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фән эшләре буенча директор урынбасары.

*Ярмөхәммәтов Хәмит Хөснетдин улы* (Хәмит Ярми), филология фәннәре докторы, Тукай бүләге иясе (1981 елда вафат).

## ЭЧТӘЛЕК=СОДЕРЖАНИЕ

КЕРЕШ=ВВЕДЕНИЕ
*Ким Миңнуллин*
6
БАРАБИНСКИЕ ТАТАРЫ: ИСТОРИЯ И ТОПОНИМИКА
*Олег Хисамов*
*26*
БАРАБИНСКИЕ ТАТАРЫ В КОНТЕКСТЕ
ЭТНОСОЦИАЛЬНЫХ ПРОЦЕССОВ В ЗАПАДНОЙ СИБИРИ
*Фарит Юсупов*
*79*
ОБСКИЕ ЧАТЫ
*Олег Хисамов*
*153*
НОВОСИБИРСК ӨЛКӘСЕ ТАТАРЛАРЫ
*Олег Хисамов, Илсөяр Закирова*
*180*
МУСУЛЬМАНСКИЕ ОБЩИНЫ НОВОСИБИРСКОЙ
ОБЛАСТИ: СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ
*Владислав Кокоулин, Альфия Рахматуллина*
*205*
ГУБНО-ГУБНЫЕ СОГЛАСНЫЕ ЯЗЫКА ЧАТОВ И
БАРАБИНСКИХ ТАТАР: СОПОСТАВЛЕНИЕ
*Николай Уртегешев, Татьяна Рыжикова*
*224*
БАРАБА ҺӘМ ЧАТ ТАТАРЛАРЫНА БАРГАННАН СОҢ
(ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ТУРЫНДА)
*Алсу Бәдртдинова*
*241*
ЯЗЫК БАРАБИНСКИХ ТАТАР: КРАТКИЙ ГРАММАТИЧЕСКИЙ
ОЧЕРК (МОРФОЛОГИЯ И СИНТАКСИС)
*Людмила Дмитриева*
*263*
ГРАММАТИКА ЯЗЫКА ЧАТСКИХ ТАТАР
(МОРФОЛОГИЯ, СЛОВООБРАЗОВАНИЕ И СИНТАКСИС)
*Диляра Тумашева*
*280*

ИСТОРИЯ ИЗУЧЕНИЯ И СОВРЕМЕННОЕ СОСТОЯНИЕ БАРАБИНСКОГО ДИАЛЕКТА ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА
*Олег Хисамов*
*293*
НОВОСИБИРСК ТАТАРЛАРЫ ХАЛЫК ИҖАТЫ
*Илсөяр Закирова, Алсу Бәдртдинова*
*301*
ӘЙТҮКӘ БЕЛӘН БАТЫШ ТУРЫНДА КЫЙССА
*Илсөяр Закирова*
*346*
ДЕКОРАТИВНО-ПРИКЛАДНОЕ ИСКУССТВО ТАТАР НОВОСИБИРСКОЙ ОБЛАСТИ
*Роза Фаткуллова*
*364*
СЕБЕР ТАТАРЛАРЫ МУЗЫКАСЫ
*Илгиз Кадыйров*
*396*
ӘЙТҮКӘ
*Илгиз Кадыйров*
*435*
ЭТНОМУЗЫКАЛЬНЫЕ ТРАДИЦИИ ТАТАР 427
НОВОСИБИРСКОЙ ОБЛАСТИ 427
*Неля Нургаянова*
*442*
ЕРАК ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ
*484*
Бараба иле
*484*
«Ак күбек» дастаны
*Илсөяр Закирова*
*535*
Кузы Курпы мән Паян-Сылу
*Хәмит Ярми*
*553*
Кыз озату җыры – «Яр-яр»
*Һәнүз Мәхмүтов*
*564*

Научно-популярное издание
*Серия «Из сокровищницы научных экспедиций»*

**Национально-культурное наследие**
**ТАТАРЫ НОВОСИБИРСКОЙ ОБЛАСТИ**
2-е издание

Фәнни-популяр басма
*«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе*

**Милли-мәдәни мирасыбыз**
**НОВОСИБИРСК ӨЛКӘСЕ ТАТАРЛАРЫ**
2 нче басма

Редакторлар: *А.А. Дәүләтова, Д.Р. Галиуллина*
Компьютерда биткә салучы *Д.Р. Галиуллина*

Китапта *О.Р. Хисамов, И.Г. Закирова, Р.Д. Фаткуллина, И.Г. Гомәров* фоторәсемнәре файдаланылды

Басарга кул куелды 20.01.2021
Форматы 60×84 $^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе. Times New Roman гарнитурасы.
Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 26. Шартлы басма табагы 33,2.
Тиражы 500 д. Заказ

Оригинал-макет
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде
420111, Казан, К. Маркс ур., 12

Для заметок